Безнен мирас
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
4
апрель 2021
ISSN:2500-011X
КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Тукайга киемне кемнәр теккән?
22 бит

Блокноттагы истәлекләр
32 бит

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдеманд

Безнең МИРАС

12 +

4
(328)
апрель 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.



Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Жамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битка салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

____

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Рәшит Әхмәтҗанов

ТАРИХИ МИРАС

4 Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. *Руи Гонсалес де Клавихо*
10 Адниш хафизга бәйле табышмак. *Р.Мәрданов*
12 Тукай һәм «Сөембикә». *Л.Мортазина*
18 Нократ татарларына разведка. *М.Госманов*
22 Тукайга киемне кемнәр теккән? *Х.Габидуллина*
28 Зәйтүнә Мәүлүдова мирасы – музейларда. *Г.Төхвәтова*
32 Блокноттагы истәлекләр. *И.Мөстәкыймов*
34 Теләкләрем тормышка ашты. *Ф.Кутлу*
39 «Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы...». *Г.Хаҗиева*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

42 Тукай Әстерханда. *А.Дубин*
45 Тукай «Идел» газеты редакциясендә. *Г.Утабалиев*
46 Фатыйма ханым. *Г.Мырзагалиева*
52 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*

ТАТАР ГАМЕ

56 Нурлы шәхес. *М.Шәймиев*
59 Чирек гасыр бергә. *А.Горшкова*
61 Тукай «таныштырды». *С.Сәлимшина-Шаһимәрданова*
62 «Безнең мирас» котлый!
63 Остазым Рәдиф Гаташ турында. *Ч.Зарипова-Четин*

ДИНИ МИРАС

64 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

70 «Котадгу белек» – бәхетле итүче белем. *Ф.Фәтхелисламов*
73 «Тарихын белгән халык – теп-тере бер милләттер». *Х.Миңнегулов*
80 Тукай мәңгегә халык күңелендә. *И.Таһиров*
86 «Ялкын»лы ялкынлы еллар хатирәсе
88 «Гомернең дулкыннары» турында. *Т.Галиуллин*

СӘНГАТИ МИРАС

91 Алманиягә сәфәр. *К.Саттаров*
96 Чал тарихка бер караш. *М.Хәбибуллин*
100 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
102 «Әллүки» җыры

ХӘТЕР САНДЫГЫ

104 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
106 Истә, һаман да истә!
108 Меңләгән кешенең әңгәмәдәше һәм сердәше. *Ф.Бәхтияри*
112 Рәшит Ваһапов белән очрашулар. *Н.Камалиева*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Апрель*

Заказ №Е-882. Тираж – 2763 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 29.03.2021. Чыгу көне: 03.04.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов.

Терелячәк телем. Үз уллары
Коткарачак аны үлемнән.

Рәшит Әхмәтҗанов

Габделхәй Сабитов һәм Рәшит Әхмәтҗанов. Казан. 1971 ел, июль

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ
(14.04.1941-5.01.1995)

АНТ
Фатих Кәрим истәлегенә

Әткәм-әнкәм теле! Балаларың
Җир җимертеп эшли – тик ятмыйлар, –
Бер-берсеннән уздырышып, хәзер
Мая туплый күпләр, мал саклыйлар.

Керфек какмый мал саклаган чакта
Балаларның «кемдер» телен кискән.
Тукай туганнарын таркаталган
Рухи юлбасарлар һаман исән.

Милли нигилистлар өммәтенә
Берләшкәннәр хәтер караклары, –
Таһирларны суга агызганда,
Сандыкларын шулар кадаклады.

Яшәмәүне дәвам итсеннәрме,
Яшәүнеме әллә дәвам итик?!
Телдән төшкән сүзләр, уяныгыз,
Тукай дошманнарын таптап китик!

Телне саткан көмеш тиеннәргә,
Алган киемнәргә төренгәнне –
Чишендереп шәрә калдырыйк бер,
Үзе булыр – күзгә күренгәне.

Яндыр, телем, җаным тынычлыгын
Каплап торганнарның күләгәсен!
Имансызлар хәзер ярты сүз дә
Безнең исемнәрдән сөйләмәсен.

Онытканның, телем, төшенә кер,
Хәтәр чорны бергә узыйк, хәтер!
Шулай булса гына, яшәүләрнең
Киләчәккә кеше серен әйтер.

Дошманнарның, телем, канына кер,
Йөрәгенә кадал, йөзенә яз...
«Китмибез»не кабат укысыннар –
Кемнәр әлифбаны таный аз-маз.

Улларыңны уят, и туган тел!
Хәтәр чорны бергә узыйк, хәтер!
Шулай булса гына, яшәүләрнең
Киләчәккә кеше серен әйттер.

Читлекләргә яптырсаң да мине,
Мылтыклардан аттырсаң да мине,
Бүген менә Фатих Кәрим кебек,
Атакага мин күтәрәм сине!

Синең өчен, туган илем өчен,
Балам өчен бүген утка керәм.
Ышан, телем, һәрбер авазыңны
Азат итәчәкбез берәм-берәм!

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1403-1406) көндәлеге

Руи Гонсалес де Клавихо

Илчеләр килгәндә, мәҗлес башланган иде инде. Шәрабны Ханзадәгә һәм башка хатын-кызларга тәкъдим итү тәртибе болайрак: туганнары арасыннан өлкән ир һәм угланнар кулында кечкенә генә ак сөлге була. Аякчы шәрабны кечкенә генә алтын касәгә бүлә, аны алтын тәлинкәгә куя. Бүлүче, шәраблы савытны тотып, арттан, шәрабны хатын-кызларга тәкъдим итүчеләр алдан бара. Ярты юлны үткәч, бер урында уң тезгә өч мәртәбә төшеп-күтәрелеп алалар. Аннары шәраблы касәләрне алдагылар алып, Ханзадә һәм башка хатын-кызлар каршына килеп тезләнәләр дә касәне, кулны тигермичә, ак тастымал белән тәлинкәсеннән аерып алып, сөлге өстенә куялар. Хатын-кызлар касәне үрелеп

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

алуга, хезмәтче малайлар, тәлинкәләрен тоткан килеш тезләнгән җирдән күтәрелеп, арка белән борылмыйча гына чигенәләр. Аз гына ара киткәч, уң тезгә төшеп, көтеп утыралар. Хатын-кызлар шәрабны татып куйса, алар тагын якын киләләр, касә алар тотып торган тәлинкәгә куела, аннан соң гына хезмәтче малай, артка борылмыйча, чигенеп китә. Бу мәрәкә алай тиз эшләнми, бик озакка сузыла. Мондый мәлдә ризык китерелми. Хатын-кызлар хезмәтченең үзен дә эчәргә кыстасалар инде, читкәрәк китеп тезләнәләр дә төбенә кадәр эчеп куялар, касәне әйләндереп каплап, тамчысы да калмаганын күрсәтәләр. Әле шул арада тормышта үзләре күргән берәр мәзәк тә сөйләп, көлдереп алалар.

Бу бәйрәмгә Тимербәкнең өлкән хатыны Биби ханым да килде. Буза, шәраб эчү озакка сузылгач, ул, илчеләрне үз янына чакыртып, кунак итәргә кереште. Руи Гонсалесны эчертергә шактый озак кыстады, аның беркайчан да шәраб татып карамаганына һич тә ышана алмады. [...]

Шәрабтан соң кыздырылган, парда пешерелгән елкы һәм сарык итләре, пылау чыгарылды. Шау-гөр килеп сөйләшеп, бер-берсенең ит кисәген алган булып кыланышып, ашау-эчү үзе бер тамашага әйләнде.

Гыймраншаһ морзаның хатыны Ханзадә иренең Тимербәк белән арасын боздырган. Ханнар нәселеннән булганга, Тимербәк аңа аерым бер хөрмәт белән карый икән. Гыймраншаһ белән Ханзадәнең егерме яшьлек Хәлил Солтан исемле уллары да мәҗлестә катнашты.

9 сентябрьдә, атнакич, бәкнең бер оныгының туй мәҗлесе булды. Монда илчеләр дә чакырылган иде. Мәҗлес бик күп тирмәләр, чатырлар корылган гаҗәеп матур итеп бизәлгән дивар эчендә оештырылган иде. Бу тантанада бәкнең өлкән хатыны Биби ханым, аксөяк хатын-кызлар, затлы ирләр бик күп иде. Табынга, гадәттәгечә, елкы һәм сарык итен ташып кына тордылар, шәраб бик күп эчелде. Бәйрәм тагын да күңеллерәк үтсен өчен, Тимербәк бөтен Сәмәрканд сәүдәгәрләренә – тукыма, чүпрәк-чапрак, асылташ сатучыларга, пешекчеләргә, итчеләргә, читек-кәвеш тегүчеләргә, һәртөрле һөнәр ияләренә бәйрәм үтәсе ыстан янына җыелырга, тирмәләр, чатырлар корып, сату эшен монда җәелдереп җибәрергә боерган. Һәр һөнәр иясе, һәрбер сәүдәгәр, үзенә билгеләнгән урында чатыр корып, урам-урам бүленеп, сату эшен көйләп җибәрде. Җитмәсә әле, шул ук сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, үз төркемнәренә бүленеп, ыстан буйлап күңелле тамаша да күрсәтеп йөрделәр. Базар мәйданында дар агачлары да куелган иде. Тимербәкнең әйтүенчә, берәүләргә мәрхәмәт күрсәтүен, икенчеләргә җәза бирүен халык күреп калсын.

Бәкнең беренче җәзасы вәзиргә арналган иде. Тимербәк алты ел да унбер ай элек яуга китеп баргач, бөтен Сәмәрканд иленең түрәсе булып калган вәзир, нәфесен чикләмичә, шактый иркенлек кылган икән. Тимербәк кайтып төшү белән аны үзенә чакырта, бөтен мөлкәтен тартып алып, вәзирне кулга алырга боера. Үзенең таянычы булган шундый дәрәҗәле кешегә карата чыгарылган хөкем карары бөтен халыкны куркуга төшерә. Вәзирне аклавын сорап килгәннәрне дә бәк җәзага тарттыра. Яраннары арасыннан Бүретай исемлесе, вәзирне коткару өчен, бәккә дүрт мең көмеш тәңкә тәкъдим итә. Тимербәк башта ризалаша, акчаны алгач инде, тагын-тагын өстәргә боерып, аны җәзага тарта, бөтенләй түләрлек рәте калмагач, аягыннан астырып куйдыра.

Яу сәфәренә чыгар алдыннан Тимербәк билгеле бер кешесенә, тәрбиядә тотсын өчен, өч мең аргамак биреп калдырган була. Кайткач белә: атлар юк. Өч мең урынына алты мең итеп бирәм, бераз көтегез, дип карый теге, әмма

Тимербәкнең әмере катгый: асарга боера.

Төрле эшләрне тикшереп, бәк әнә шулай хөкем карары чыгарта. Үзе югында арттырып, кыйммәткәрәк ит саткан кибетчеләрне хөкемгә тарта. Кайбер читек-кәвеш тегүчеләрдән, башка һөнәргә караган осталардан, үз тауарларын кыйммәтрәк бәягә саткан өчен, артык акчаны киредән түләттерә. Бәк безне монда – шәһәрдән урдага – бөлгенлеккә төшерер өчен чакырткан икән, дип, күпләр ризасызлык күрсәткән, диделәр.

Монда тәртип шундый: югары катлау кешесе гаепләнә икән, аны – асу, түбән катлау кешесенең башын кисү җәзасы каралган.

Алдагы дүшәмбедә, 13 октябрь көнне, Тимербәк илчеләрне тагын мәҗлескә чакыртып алды. Гадәттә, бәйрәм тантанасы үтә торган зур павильон янында бик мәһабәт яңа тирмәләр, чатырлар торгызылган иде. Берсе ак атлас тукымадан эшләнгән, икенчесе алтын җеп кушып тукылган кызыл төстәге келәмнән корылган; ихата эчендәге тирмәләр моңа кадәр күрелгәннәрдән зуррак та, зиннәтлерәк тә, биегрәк тә күренә. Керә торган капкасы гөмбәзләп эшләнгән, өстә шулай ук алтынлап чигелгән келәмнән манарасы бар.

Ул көнне илчеләрне зур павильоннан читтәрәк күтәрмә астына утырттылар. Кырга бер-берсеннән таш атып тигерер ераклыкта шәраб мичкәләре куелган иде. Зур павильонга шул мичкәләр рәтен үтеп берәү дә якын килә алмый, ул турыда баштанаяк коралланган атлы сакчылар йөреп тора. Кем дә кем әлеге мичкәләр арасыннан үтә икән, сакчылар ук аталар яисә чукмар белән кизәнәләр, кайберәүләрне, сөйрәп, капканың аръягына чыгарып ыргыталар. Кырда халык күп, бар да бәкнең чыкканын көтә. Павильон янәшәсендә күтәрмәләр корылган, һәммәсендә алагаем зур мичкә тора, бер-берсенә унбишәр чиләк шәраб сыешлы.

Шактый вакыт үткәннән соң, илчеләрне бәкнең оныгын сәламләргә дип алып киттеләр. Ул кичә генә Кече Һиндстаннан кайтып төшкән, анда ул солтан тәхетен биләп тора икән.

Тимербәк җиде ел буена күрешмәгән оныгына хәбәр салган булган. Хәзер инде мәрхүм булган олы улы Җиһангирны яраткан кебек үк, оныгы Пир Мөхәммәдне дә бәк бик ярата икән.

Илчеләрне аның кызыл келәмнән эшләнгән тирмәсенә алып килделәр. Тирмә янына килеп җитүгә, яраннары арасыннан ике егет чыгып, илчеләрнең кулыннан тотып, тезләндерделәр. Торып берничә адым атлауга, тагын тезләндерделәр. Тирмәгә кергәч инде илчеләр, солтанны уң аякка тезләнеп, кулларын күкрәккә кушырып, баш иеп сәламләделәр. Аннары теге егетләр, кулларыннан тотып, илчеләрне читкәрәк алып киттеләр дә тирмәдән алып чыктылар.

Тимербәкнең оныгы бик затлы киемнән иде: зәңгәр атлас күлмәгенең аркасына, түшенә, җиңнәренә алтын җеп белән берәр түгәрәк чигелгән. Баш киеме энҗе, асылташлар белән бизәлгән, түбәсендә бик зур якут таш балкып тора. Халык өчен дә аны сәламләү олы бер тантана иде. Уртада ике көрәшче пәйда булды, җиңсез күн җилән кигәннәр. Алар бер-берсен ега алмыйча шактый көч түкте. Пир Мөхәммәд әмере шундый: аркасы белән төшкән көрәшчене шактый вакыт җиргә кысып торырга кирәк, күтәрелә икән, җиңүгә саналмый.

Ул көнне төрле иллрдән килгән илчеләр барысы да егерме ике яшьлек Пир Мөхәммәдне сәламләде. Ул кояшта янган чырайлы, сакал-мыексыз иде. Үзен Кече Һиндстанның патшасы итеп саный, имеш.

Һиндстанның башкаласы Дәһли янында Тимербәк белән Һинд солтаны ара-

сында сугыш була. Һиндстан ягыннан күпсанлы гаскәр, иллеләп сугышчан фил яуга керә. Шул филләр аркасында Тимербәк чигенергә мәҗбүр була. Икенче көнне тагын һөҗүмгә күчәләр. Тимербәк бик күп дөяләр китертә, сыртларына кипкән салам көлтәсе бәйләтеп, филләргә каршы куя. Орыш башлануга, дөя сыртындагы саламга ут төртергә боера. Филләр утка чолганган дөяләрне күрүгә борылып кача башлыйлар. Күзләре бәләкәй булу сәбәпле, филләр уттан бик куркалар икән. Шулай итеп, бу сугышта Тимербәк җиңеп чыга, Һиндстанның Сәмәрканд белән чиктәш иңкү җирләрен басып ала. Индусларның күп җирләре тау-тарлавыклардан тора, анда зур калалар күп, кырлары уңдырышлы икән. Һиндстан солтаны җиңелгәннән соң, тауларга китеп, яңа гаскәр туплый, әмма яңадан Тимербәк белән сугышырга теләми. Бәкнең оныгы Пир Мөхәммәд әнә шул Ормуз шәһәренә кадәр җәелгән бай, уңдырышлы, уйсу җирләрдә хакимлек итә. Әлеге сугыш моннан унбер еллар элек булган, диләр, бәлки, соңрак, бәлки, иртәрәктер, әмма шунысы хак: шул чордан бирле Тимербәк тә, оныгы Пир Мөхәммәд тә Һиндстанга яу сәфәре кузгатуга талпыныш ясамаган. Һиндстан халкының күбесе христиан динендә, солтаны да, индуслар да греклар мәзһәбендә. Арада чыраена ут белән тамга салынган икенче төрле христианнар да бар, әмма өстенлек беренчеләрендә, болар арасында маврлар, иудейлар да бар, ләкин барысы да христианнарга бәйлелектә.

Ул көнне төрле уеннар, кызыклы тамашалар күрсәттеләр. Филләрне кызылга, сарыга, яшелгә буяганнар. Фил сыртына сәкеләр куеп, шунда тамаша ясыйлар. Мәйдан шау-шу, уен-көлке, барабан кагулардан тетрәп торды. Төш вакытында илчеләрне Тимербәк утырган павильонга чакырдылар. Монда күп музыкантлар җыелган иде, өч йөзләп шәраблы чүлмәк тора, өчаяк итеп эшләнгән кызыл төстәге казыкларга каймак, буза салынган корчыннар (күн савытлар) куелган. Хезмәтчеләр, шикәр кисәге салып, таяк белән бузаны болгатып торалар.

Бөтенесе дә урнашып, утырышып беткәч, янәшәдәге тирмә ихатасыннан чыгып килүче Тимербәкнең өлкән бикәсе – Биби ханым күренде. Алтын белән чигелгән кызыл ефәк күлмәктән. Җиңе дә, кулларны чыгарырга уемы да юк шикелле киң күлмәк, җирдән сузылып килгән озын итәген унбишләп кыз күтәргән. Йөзе шулкадәр куе итеп акшарланган, кәгазьдән ясалган сыман. Җәйге эсседә кояштан, кышын салкыннан саклану өчен аксөяк хатын-кызлар шулай битләрен акшарлыйлар икән. Биби ханымның чырае өрфия кебек бик юка ак тукыма белән капланган иде. Башында – рыцарьлар турнирда ярышканда кия торган шлемга охшаган кызыл башлык, ул, арттан бөкләнеп, иңгә төшеп тора. Башлык шундый биек, аңа бик матур итеп каймалап эшләнгән энҗе-мәрҗән, фирүзә, якут ташлар тезелгән. Иңгә төшеп торган яулыгы алтын белән чигелгән, өстән асылташлар белән зиннәтләнгән алтын такыя киеп куйган. Такыяның таҗы ике бармак калынлыгындагы, гаҗәеп матур нурлар чәчеп торган өч якут таш белән төгәлләнә. Болардан да өстә, терсәк биеклегендә булыр, кош каурыйлары тезелгән солтан, каурыйлар алтын җеп белән бәйләнгән, очы асылташлар белән бизәлгән ак каурый учмасы. Биби ханым хәрәкәтләнгән чакта кош каурыйлары як-якка җилпенеп бара. Иңенә таратып салган чәче чем-кара. Монда хатын-кызларның чәче гел карадан, кайберләре хәтта карага буяталар да икән. Биби ханымның баш киемен аксөяк хатын-кызлар тотып килә. Аның тирәсендә хатын-кызлар шактый, өч йөзләп булыр. Ә берәү аның баш очында сөңге кебек итеп кулчатыр тоткан. Ул ак ефәктән тирмә түбәсе кебек түгәрәк итеп, агач киергегә тарттырып, кояш нурыннан саклану өчен эшләнгән. Биби

ханым һәм аның аксөяк ахирәтләре алдыннан да, арттан да бик күп чибәр егетләр – аларны саклаучы евнухлар атлый. Павильонга килеп җиткәч, Биби ханым бәк кырыена калку урынга килеп утырды, аны озатучы дәрәҗәле ханымнар артка китеп утырдылар. Авып төшмәсен өчен, өч кыз Биби ханымның баш киемен тотып торды. Ул килеп утырырга, икенче яктан бәкнең Кече хатыны нәкъ шундый затлы киемдә, шундый ук купшы башлыктан, шулай ук аксөяк ханымнар, евнухлар даирәсендә килеп, Биби ханымнан әз генә түбәнрәк урынга утырды. Чираттагы дивар эчендәге тирмәдән Тимербәкнең өченче хатыны чыгып, нәкъ шул тәртиптә килде дә Кече ханымнан түбәндәрәк урын алды. Шулай итеп, бер үк төсле киемдә, бер үк төсле бизәнгән тугыз ханым, һәммәсе үз тирмәсеннән чыгып, тантаналы рәвештә килеп, үз урынын биләде. Боларның сигезе Тимербәк хатыны булса, берсе оныгы Пир Мөхәммәднеке иде.

Биби ханым – Сәмәрканд, Фарсы һәм Дәмәшекънең элекке хакиме Казан хан кызы, бәкнең өлкән хатыны, ханәкә яисә башбикә санала. Иң яшь хатынына Тимербәк узган август аенда гына өйләнгән булган. [...]

Тимербәк ул көнне илчеләргә үз катына килергә кушты, рухани магистр Руи Гонсалесның эчмәгәнлеген белсә дә, аңа шәраблы касә сузды. Бәк кулыннан касә алучылар барысы да әүвәле баш иеп, уң аягына тезләнделәр, аннары тагын да якынрак килеп, ике аякка да тезләнеп, касәне алгач, күтәрелеп арткарак чигенделәр (бәккә арка белән борылу һич тә ярамый!), аннары тезләнеп, соңгы тамчысынача эчеп куйдылар. Төбенә кадәр эчкәч, торып, кулны маңгайга куеп алдылар. Бу тантана вакытында һәр илчене ике яктан терсәгеннән тотып икешәр егет озата килде.

Үзәк павильон янәшәсендә Тимербәк катына килгән төрле илчеләр өчен бик күп чатырлар, күтәрмәләр корылган иде. Һәр чатырга шәраблы мичкә куелган, күпме сыя, шулчаклы эчәргә мөмкин. Ә инде үз янындарак утырган испан илчеләренә бәк үз алдындагы ике чүлмәк шәрабны бирергә кушты.

Бәк каршында баулы баганалар куелган, аңа елгыр егетләр менеп, төрле тамаша күрсәттеләр. Бәк карамагындагы ундүрт фил шундый итеп бизәлгән: сыртына ефәк тукыма белән төрелгән, очына сары, яшел әләмчекләр эленгән агач манара куелган, анда биш-алты кеше утыра. Кара төстәге филләрнең тәнендә йон юк, дөянеке кебек койрык очында гына бер толыкман күренә. Гәүдәләре алагаем зур, дүрт-биш үгез кадәрле; бернинди ыспайлыгы юк, әйбер тутырылган капчык шикелле тупас рәвешле. Аяк табаннары буйволныкы кебек икегә аерылган, кешенеке сыман биш бармаклы, тырнаклары гына кара. Колаклары галәмәт зур, дулкынланып тора, күзләре бик кечкенә. Шул колаклар артында ук җайдак утыра, тимерчыбык белән селтәнеп, ул филне үз әмеренә буйсындырып йөртә.

Филләрне кешеләр яисә атлар артыннан чаптыру бик кызык булды. Бөтен фил бергә чапканда җир тетрәгән кебек була. Боларга бер хайван да тиңләшә алмый. Бер филнең мең гаскәригә торганын шунда аңлыйсың. Яуда ул, уңлысуллы селтәнеп, кешеләрне чөеп ыргыта, таптый; яраланган булса, аны тыям димә, күзе тонып чаба, казык теше белән өстән чәнчи. Аның мөгезгә охшаган бу тешләрен кыскарак калдырып кисеп, аңа кылыч беркетеп куялар. Филләр берничә көн ач торып та яу кырында ару-талуны белмиләр икән.

Ул көнне Тимербәк үзенең хатыннары, кунаклары белән төне буе күңел ачты. [...]

17 октябрьдә, җомга көнне, Биби ханым зур бәйрәм үткәрде. Анда илчеләр

дә чакырылган иде. Бик күп тирмәләрне уратып алган сарыпәрдә ак һәм төсле ефәктән төрле бизәкләр, билгеләр чигеп эшләнгән. Капкага килеп җитүгә, бәкнең якыннары – берничә егет – илчеләрне якындагы тирмәгә алып килеп урнаштырдылар. Тирмә тыштан да, эчтән дә җете кызыл келәмнән урыны-урыны белән ак келәм белән аралаштырып эшләнгән. Илчеләр утырышкач, алга күп итеп ит ризыклары, шәраб куелды. Ашап-эчкәч, шушы ихата эченә урнашкан тирмәләрен күрсәтергә дип, Биби ханым аларны үзенә дәштерде. Бик бай тирмәләр арасында берсе – иң зуры, иң биеге – ап-ак ефәк белән капланган, көмешкә алтын йөгертелгән каптырмалар белән өстән аска кадәр бизәлгән иде. Тыштан да, эчтән дә искиткеч матур чигелгән. Ишеге ике катлы. Беренче ишек нәзек камыш чыбыктан үрелгән, тыштан алсу төстәге әрфия ефәк белән капланган, һава кереп тора, эчтәгеләр үзләре күренмичә дә тыштагыны үтәли күреп торырлык. Тышкы ишек шулкадәр биек, атлы җайдак сыеп керерлек, алтын йөгертелгән көмештән, зәңгәрсу эмальгә алтын батырып эшләнгән. Гаҗәеп нечкәлек белән ясалган мондый ишекләр бу җирдә дә, христиан җирендә дә бүтән юктыр, мөгаен. Икегә ачыла торган әлеге ишекнең берсенә – изге Петр, икенчесенә китап тоткан изге Павел алтыннан сурәтләнгән. Әйтүләренә караганда, төрек казнасын талаганда, Тимербәк аны Бурсадан табып алып кайткан.

Ишек турылап тирмәнең уртасында биеклеге күкрәк турысына җитмәле шкаф тора. Алтын бизәкле, эмаль йөгертеп, чуарлап эшләнгән. Кыр-кырлары яшел, зәңгәр эмальдән сырлап ясалган. Шкаф асылташлар белән бизәлгән, ачылмалы кечкенә ишекле, эчкә көмеш савыт-саба куелган. Өстендә энҗе, асылташлар белән бизәкләнгән алты алтын чүлмәк, шулай ук энҗе, асылташлар белән бизәкләнгән алты түгәрәк касә тора. Шкаф кырыенда алтын өстәл, биеклеге ике карыш булыр, шулай ук асылташлар белән бизәлгән. Өстәл өсте балкып торган зөбәрҗәт таштан эшләнгән. Бу өстәл каршында савыт янында алтын агач куагы тора. Кәүсәсе кеше аягы калынлыгында, як-якка җәелгән ботаклы, яфраклары имәннекенә охшаган. Кеше биеклегендәге бу агачның яфраклары – алтыннан, җимешләре мул итеп якут, фирүзә, кызыл якут, зәңгәр якут, балкып торган зур энҗе бөртекләреннән ясалган. Ботакларда эмаль йөгертеп ясалган алтын кошчыклар утыра, кайсы очып китәргә җыенган кебек канатларын җәйгән, кайсы егылып төшә язган кебек, кайсылары асылташлардан томшыгына җим капкан.

Нәкъ шушы агач куагы турысында стена буенда көмешкә алтын кушып каплатылган агач өстәл тора, аның каршында ял итү урыны, имән яфраклары, төрле чәчәк сурәтләре чигелгән ефәк җәймә өстенә чигүле мендәрләр куелган. Тирмәнең икенче ягында да шундый ук өстәл һәм искиткеч матур чигелгән мендәрләр.

Бу тирмәне тамаша кылып чыккач, илчеләрне икенче, алтынлап бизәкләнгән кызыл келәмнән эшләнгән тирмәгә алып керделәр; анда Тимербәк үзенең яраннары белән, кичәге кебек үк, шәраб эчеп утыра иде. Бу сарыпәрдә эчендә ярәшелгән оныкларының да чатыры бар иде. [...]

Урысчадан ***Марсель Галиев*** *тәрҗемәсе* ■

Адниш хафизга бәйле табышмак

Раиф Мәрданов

Әдәбиятыбыз тарихында «Сираҗел-колүб» исемле әсәрнең авторы Адниш хафиз булган дигән фикер бар. Әмма моңа дәлилләр җитеп бетми. Башта гарәп теленнән фарсычага тәрҗемә ителгән бу әсәрнең татарча вариантын тюрколог галим Әмир Нәҗип үткән гасыр уртасында Мәскәүдәге дәүләт архивында табып, беренче буларак өйрәнгән[1]. Ул тасвирланмаган һәм фәнгә билгесез кульязманың Мәскәүдә 1554 елда тотык булып торган вакытта Адниш хафиз тарафыннан күчерелгәнен белдергән һәм шул ук зат үзеннән дә өстәп язгандыр дип билгеләп үткән.

Башка галимнәр «Сираҗел-колүб»не Адниш хафиз иҗат иткән дип язалар[2]. Әлеге әсәр текстының башында беренче зат исеменнән язылган гыйбарәләр шундый карашка нигез булгандыр. Галимнәр бу әсәрнең кульязма күчермәләре табылып торуын һәм XIX гасыр уртасыннан алып XX гасыр башына кадәр дистәгә якын басмасы дөнья күргәнлеген әйтеп: *«Авторлык фәкать Мәскәүдә саклана торган автографлы кульязмада гына бар. Казан басмаларында да язучының исеме куелмаган»*[3], – диләр.

Әгәр дә «Сираҗел-колүб»не Адниш хафиз Мәскәүдә тотык булып торган чагында 1554 елда иҗат иткән булса, ул татар халкы арасында ничек итеп башка күчермәләрдә таралыш алган икән соң дигән мантыйкый һәм урынлы сорау туа. Югыйсә, Адниш хафиз белән бергә Мәскәү «тоткынлыгында» калып, «кымшанмыйча» диярлек яткан һәм тасвирланмаган (димәк, нәрсә икәнлеге дә билгесез) хәлдәге кульязманы Ә.Нәҗип XX гасыр уртасында гына тапкан бит. Мәскәү архивында табылган кульязманы, кайбер белгечләр фикеренчә, әсәрнең автор каләменнән чыккан төп нөсхәсе дип исәпләсәк, аңлаешсыз табышмак хасил була лабаса.

Кызганыч ки, әлеге табышмакка галимнәрнең мәкаләләрендә җавап юк. Тик, шуңа карамастан, бу әсәр *«бик күп тапкырлар күчереп языла һәм басыла... Күп буыннар аны укып тәрбияләнгән. Әднәш Хафиздан соң иҗат иткән язучылар һәм шагыйрьләр дә үз әсәрләрен аныкына охшатып, аның идеяләрен кулланып һәм тулыландырып иҗат иткәннәр»,* – дип яза алар[4]. Бу өзектән күренгәнчә, биредә Адниш хафизның исеме дә үзгәртелгән. 1554 елгы кульязмада ул үзен «Адниш хафиз ибне Мөхәммәдаднаш хафиз» дип күрсәткән. Монда ике мәртәбә кабатланган «хафиз» дигән сүз «мулла» мәгънәсендә, әтисенең исеме ике өлештән – Мөхәммәд һәм Аднаш исемнәреннән торган кушма исем. «Сираҗел-колүб» авторы дип фаразланучы, ни сәбәптәндер, «Татар әдәбияты тарихы» басмасында «Әднәш Хафиз» дип бирелгән. Беренчедән, үз исеме урынына әтисенең исеме (ул да йомшартылып) һәм, икенчедән, рухани титул булган «хафиз» сүзе кеше исеме булып киткән[5]. Ә Мәсгудь Гайнетдинов текстында әлеге исем дөрес итеп «Адниш бин Аднаш» дип язылган[6].

---

[1] Наджип Э. Датированная тюркоязычная рукопись XVI в. «Сираҗел-колүб» // Труды Двадцать пятого Международного конгресса востоковедов (Москва, 9-16 августа 1960). Т.3: заседания секций X, XI, XIII. – М.: изд-во Вост. лит., 1963. – С.323-329.

[2] Гайнетдинов М. «Сирадж ал-кулюб» (Светоч сердец) // Средневековая татарская литература: VIII-XVIII вв. – Казань: Фэн, 1999. – С.141-147; Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов А. Әднәш хафиз. «Сираҗел-колүб» // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т.2: XV-XVIII гасырлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б.149-157.

[3] Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов А. Әднәш хафиз. «Сираҗел-колүб» // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т.2: XV-XVIII гасырлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б.150.

[4] Шунда ук. – Б.157.

[5] Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т.2: XV-XVIII гасырлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б.9, 25, 149-157, 461.

[6] Гайнетдинов М. «Сирадж ал-кулюб» (Светоч сердец) // Средневековая татарская литература: VIII-XVIII вв. – Казань: Фэн, 1999. – С.141-147.

«Сиражел-колуб»нең башка кульязма күчермәләренә килсәк, безнең исәпләү буенча, хәзерге вакытта Казандагы төрле китапханәләрдә һәм музейларда аның XVII-XIX гасырларга нисбәтле, тулы һәм фрагмент хәлендәге уннан артык күчермәсе бар. Тик тасвирларда һәм каталогларда бөтенесенең дә исемнәре күрсәтелмәгән. Текстларының Адниш хафиз күчермәсеннән аермалары бик аз. XIX гасырда Вятка губернасының төньягында сөргендә вакытта Әхмәди исемле мулла күчереп язган нөсхәсе дә шундыйлардан. Ул да, кульязмачылык традициясенә хас булганча: *«Ошбу китап язылды 1879 нчы сәнәдә... Яздым бән – Әхмәди Гыйззәтулла мәрхүм угылы»,* – дип, исемен теркәгән[7]. Ягъни, «Сиражел-колуб»нең бу күчермәсендәге «яздым» дигән сүз һич тә авторлыкны белдермәгән кебек үк, Мәскәүдә сакланган кульязмадагы «Адниш хафиз язды» дигән сүзләр дә авторлыкка ишарә итми.

Адниш хафиз кульязмасы

Кызганыч ки, галимнәребез кульязма ядкярләрне күчергән кешеләрне автор дип билгеләгән очраклар тагын бар. Бигрәк тә элекке чыганакларда «язучы» сүзенең «китап күчерүче» мәгънәсендә кулланылган булуы зур ялгышлыкка китерә. Ягъни, «моны яздым мин», «бу китапны язучы» (борынгырак текстларда – «битедем, «битүче») кебек, татарча яисә гарәп телендәге «кятиб», «кәтәбәһә» һ.б. гыйбарәләрне хәрефкә-хәреф кабул итеп, авторы дип бутаучылар бар. Мәшһүр галим Ризаэддин Фәхреддиннең хезмәтләрендә һәм мәкаләләрендәге кульязма әсәрләрне дә (шул исәптән, Коръәнне) күчергән кешеләргә карата «язучы» гыйбарәсе кулланылган булуга карап, автор дип хаталанган фән әһелләребез дә булды. Әүвәлге текстларда (XX гасыр башына кадәр) әсәрнең авторы мәгънәсендә «язучы» сүзе түгел, ә «мөәллиф», «мөхәррир», «мосанниф», «сахиб» кебек гарәп сүзләре кулланылган.

1554 елгы «Сиражел-колуб» кульязмасының фоторәсемен «Татар китабы» альбомында бастырганда, әйтелгән сәбәпләрне истә тотып, без Адниш хафизны кульязманы күчерүче дип атаган идек[8]. (Шуны да искәртик: аңарчы бу кульязма истәлекнең фотосы матбугатта чыкканы булмады.)

Күргәнебезчә, асылы гарәп телендә иҗат ителеп, аннан фарсычага, фарсычадан исә татарчага тәрҗемә ителгән «Сиражел-колуб» китабының авторлык мәсьәләсе нигезле һәм дәлилле рәвештә тикшерүгә мохтаҗ. Урта гасырларга хас булганча, мәгълүм бер китап тәрҗемә итеп назыйрә рәвешендәге оригинал әсәр иҗат ителгән дип каралса, аның асыл нөсхәсенә карата тәңгәллек һәм аерымлык пропорцияләре ничаклы булуын ачыклау зарур. ■

---

[7] Татарстан Республикасының дәүләт музее. «ГОМРТ. 19011-2» шифры белән саклана торган кульязма, 137 б. кәгазь.

[8] Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт. – Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б.94.

Безнең мирас №4 апрель 2021

Тукай һәм «Сөембикә»

Ләлә Мортазина

«Сөембикә» журналының Габдулла Тукай портреты белән чыккан 1914 елгы 11 нче саны

XX гасыр башында Габдулла Тукай шигырьләрен бастырмаган, аның турында язмаган бер генә татар газета-журналы да калмагандыр, мөгаен. Россиядә чыгып килгән рус телле вакытлы матбугатта да Тукайга багышланган мәкаләләр бик күп басыла. «Вакыт», «Кояш», «Йолдыз» кебек татар газеталарының 1913 нче елгы 4 апрель саны шагыйрьгә багышлап чыгарыла. «Волжско-Камская речь», «Оренбургская газета», «Каспий» (Баку), «Олуг Төркестан» (Ташкент), «Тәрҗеман» (Бакчасарай), «Шәркый Рус» (Баку), «Милли байрак» (Мукден), «Ерак Шәрык» (Харбин), «Төрек йорты» (Истанбул) кебек басмалар Тукай шәхесенә аеруча игътибарлы булганнар.

Бу җәһәттән татар ханымнарының гына түгел, гомумән, киң татар җәмәгатьчелегенең иң яраткан басмаларыннан берсе – мәшһүр «Сөембикә» журналы да читтә калмаган. Журналның 1914 елгы 11 нче саны Габдулла Тукайга багышланган. Анда шагыйрьнең фотопортреты (тышлыкта һәм 2 биттә) һәм җеназа мәрасименә кагылышлы ике фотосурәт («Шагыйребез Габдулла Тукаевның җеназасының Печән базарыннан үтеше», «Шагыйрьләребездән Г.Тукаев җеназасының мәйдандагы күренеше») урын алган.

Тукай шигырьләрен бастыру һәрбер татар басмасы өчен олы мәртәбә булган. Ләкин «Сөембикә»дә шагыйрьнең үз әсәрләре күп түгел, чөнки бу басма Г.Тукай вафат булган елда гына чыга башлый. Шуңа да карамастан, Тукайның 1909 елда ук язылган атаклы «Пәйгамбәр» шигыре (1914 елгы 7 нче сан), беренче тапкыр «Яшен»нең 1909 елгы җиденче (2 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган «Хатыннар хөррияте» әсәре (1914 елгы 11 нче сан) әлеге журнал битләрендә дөнья күргән.

Чыгтай: «Ул үзенә-үзе нишан таш утыртты»

Г.Тукайга багышланган махсус санда басылган «Габдулла Гариф улы Тукай» дигән шактый күләмле мәкаләнең авторы Чыгтай (Галиәсгар Гафуров) (1867-1942). Ул шагыйрь иҗатына, аның шәхесенә зур бәя бирә, Тукайның татар милләте өчен генә түгел, гомумән, бөтен төрки дөнья өчен дә әһәмияткә ия булган олуг шәхес булуына басым ясый. *«Аның бөтен халәт вә рухияләре татарныкы иде ки, без Тукаевны татар шагыйре, хәзерге татар-төрек халкының әхваленә тылмач иде дибез. Әйе, Тукай татарның аңлата алмый яткан максудын аңлаткан тылмач иде! Габдулла Тукай 1000 еллык иске торышның хәзерге яңару дәверенә күчүенә гармониялек хезмәтен итте. Шундый тарихи бер үзгәрештә милләтне сынудан саклый торган бер терсәк урынын тотты. Вә ул ике дәверне бергә ялгаган бер маяны безгә бирде, вә ул татар телен вә татар рухын күп гасырларгача күрсәтеп вә әйтеп торган*

кыйммәтле документны безгә тапшырып калдырды. Әйе, Габдулла Тукай үзен-үзе таәбәд итте (мәңгеләштерде), ул үзенә-үзе нишан (билге) таш утыртты». Чыгтайның сүзләре бүген дә заманча яңгырый, Тукай бүген дә милләт күгендә янган иң якты йолдызларның берсе булып кала.

Чыгтайның бу мәкаләсендә «шагыйрьнең әхвалендә хатыннарның нинди катнашы булганлыгын» тикшерү максат итеп куела һәм, әлбәттә, Тукай тормышында иң кадерле, әһәмиятле, иң зур урын тоткан хатын-кыз образы – аның әнисе Мәмдүдә тасвирлана. Ирсез, тол калган яшь хатынның башкага кияүгә чыкканнан соң да баласы өчен кайгыруы, аны сагынуы, йөрәк парәсе өчен җанфәрман тырышуларын сурәтләп, ул: *«Бу ананы мактамаганда, кемне мактыйбыз? Ул бит безнең бүген телгә ала торган каһарманыбыз Габдулланың анасы булган!»* – дип, татар милләтенең Тукай кебек мәшһүр затка ия булуында бөек Ананың ролен ассызыклый. Шагыйрьнең җеназасын күтәреп киткәндә татар халкының ни дәрәҗәдә кайгы кичерүен әнисен ак кәфенгә уратып каберлеккә алып киткәннән соң кар өстендә яланаяк елап басып калган малайның халәте белән чагыштыра.

Тукай һәм хатын-кыз мәсьәләсен яктыртканда, Чыгтай: *«Ул кешене ир вә хатыннарга аерып йөртмәде; ул бер генә җенес халыкны – милләтне генә беләдер иде. Ул әйткән сүзен бөтен милләттәшләренә карап әйтте вә шуның өчен Тукай мәрхүмнең шигырьләрен кыз балалар ир балалардан ким укымыйлар, бәлки, кыз балаларның хәсән вә рухлары тагы нечкәрәк вә сизгеррәк булганга, алар Тукайны тагын да артыграк аңлыйлар»,* – дип яза.

Садри Җәләл: «Бөтенебезне яхшылыкка өнди иде»

Бу санда басылган икенче бер язма – язучы Садри Җәлалның (1891-1943) «Аның сөекле улы» мәкаләсе. Автор данлы үткәне белән горурланучы, зур хәсрәтле, кайгылы чорларны кичергән, һаман да йөрәгеннән кан тамып торган МИЛЛӘТ образын сурәтли. Аның иң сөекле улларыннан берсе булган, «үзенең моңлы җырлары белән бигрәк тә үзенә охшаган», «йөрәге сызланганнан ачынып, әллә нинди зарлы, моңлы көй белән җырлаган» Тукайны сагынып сызлануын тасвирлый, шул рәвешле шагыйрь шәхесен милләт дәрәҗәсенә күтәрә. Бүген Тукайның кабере бик күп татарлар өчен «бөтен нәрсәдән артык тоела», бик күпләр аның турында: *«Үзебезне ярата, безнең белән шатлана, безнең белән көенә, бөтенебезне яхшылыкка өнди иде»*, – дип искә ала, ди.



١١ نچی صان ١ نچی آپریل ١٩١٤ سنه.
١٨ نچی جمادی الاول ١٣٣٢ سنه

اداره خانه‌سی:
قزانده، قابان کولی قارشیسنده
آرخیپف یورطنده کۋارتیر
نومر 1.

Такса на объявленія:
впереди стр. петита 60 к.
позади " " 40 к.
постоянный заказъ по соглашенію.

ژورنالنڭ بهاسی:
بریلغه ٤ صوم
یارطی یلغه ٢ صوم ٥٠ تین
اوچ آیغه ١ صوم ٣٥ تین

مراجعت اوچون آدریس:
Казань, редакція журнала „СЮЕМЪ-БИКА".

سویم‌بیکه
١٣٣١

خاتون-قزلارغه مخصوص ایکی آطنه‌ده بر چغا طورغان ادبی، حقوقی، اقتصادی، اخلاقی، عیالی رسملی ژورنال.

خاتونلار حریتی

– کویه‌م بیرمك اوچون حرلك، آزادلقلار خاتونلارغه،
بتون فکرم، اویم شولدر قارامی کون ونونلرگه.

بو اویدن قایناسم یوقدر، اگر قانلی صوغش بولسه،
خاتونلار ایرکی اوغرنده، اوله‌رمن مین اولش بولسه.

خاتونلار! آتلاگز آلغه! بو یولده شاولا مطبوعات!
خاتونلارنی قصوچیلارغه قارشی آچ صوغش، اوق آت!

ئیل ای خلق دنیا! اورتادن یول بیر خاتونلارغه!
یاشا، ای عالم انثی! وقت، حقلارنی آڭلارغه.

طارالورغه وقت ایندی، چاپان آتلی بولوتلارغه،
چاپانیده، بخاریده آشارغه قالسون اتلرگه!

آلارده ایر کبی شاهلق، حکیملك ناملارن طاقسون!
خاتوندن کوچ ترقی بحرینه کول، کول بولوب آقسون!

اوقو، یاز، بل، طرش سین ای مقدس یارتمز بزنڭ!
کشی بولمق اوچون ایك، ایك برنچی شرطمز بزنڭ!

ع. توقای.

№ 11 1-го Апрѣля 1914 г. 2-й годъ изданія

ЖЕНСКІЙ ЖУРНАЛЪ „СЕЮМЪ-БИКА"

A.T.S.S.R.-T.M.X.K. Mərkəz Qitab həm Publika Kitabxanəse. Научная Публичная Библиотека. Инв. № г. Казань--Qazan.

مرحوم عبدالله توقایف حقنده

کامل مطیعی طرفندن ترتیب ایتلگان «توقای خاطره‌لری» نام کتاب
«عبدالله توقایف‌نڭ رسمی علاوه اولناره‌ق، آپریل باشنده عبدالله
کیلشدیشف نشرنده مطبوعات بازارینه چغاچق»
مرحوم شاعرمز عبدالله افندی توقایف‌نڭ وفاتینه نه‌ق بر یل طولو
مناسبتیله آپریل‌نڭ ٢ نده چغاررغه فرض ایتله! کتابنڭ حقی
١٠ تین پوچطه ایله ١٢ تین».
کوب‌ب آلوچیلارغه ٣٥ پرانسینت اسکیدکه.

آدریس: Казань, Абдулла Кильдишеву.

گیرمانیا اشی تورلی خودوژستوینی آتکریتکه‌لار:

г. Старая-Бухара, №2, С-Б., торговый посреднеку М.-Ф. Ю. Заманову.

معلمه کیره‌ك.

г. Наманганъ А. Г. Аббасову

Казань, Электро-тип. "МААРИФЪ", 1914 г.

Хатыннар хөррияте

– Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатыннарга;
Бөтен фикрем, уем шулдыр, карамый көн вә төннәргә.

Бу уйдан кайтасым юктыр, әгәр канлы сугыш булса,
Хатыннар ирке угърында үләрмен мин, үлеш булса.

Хатыннар! Атлагыз алга! Бу юлда шаула, матбугат!
Хатыннарны кысучыларга каршы ач сугыш, ук ат!

Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга!
Яшә, и галәме өнса! Вакыт хакларны аңларга!

Таралырга вакыт инде чапан атлы болытларга;
Чапаны да, Бохары да ашарга калсын этләргә!

Алар да, ир кеби, шаһлык, хакимлек намнарен таксын!
Хатыннан көч тәрәкъкый бәхренә күл-күл булып аксын!

Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкаддәс яртыбыз безнең!
Кеше булмак өчен иң-иң беренче шартыбыз безнең!

Габдулла Тукай

Сөләймания: «Анасының җылы кочагына туймаган»

Күренекле татар мәгърифәтчесе, мөгаллимә Фәхрелбәнат Сөләйманиянең (1865-1959) «Сөембикә» журналының 1915 елгы 2 нче санында «Бөек фаҗига» дигән мәкаләсе басылып чыга. Ул әти-әнисе йортын ташлап, дөньяга мөстәкыйль адым ясаган татар кызы Гыйффәт туташның мәкаләсенә җавап буларак язылган. Автор, бер яктан кызның мәгърифәткә омтылуын хупласа да, татар гаиләсендә туып-үскән, тәрбия алган бер баланың матбугатта үз хәленнән, гомер бүләк иткән анасыннан зарланып язуын, авырлыклар алдында югалып калуын, бәхетне читтән эзләвен һич кенә дә кабул итә алмавын белдерә, авырлыкларның кешене чыныктыруы турында яза. Мисал итеп, ул кыска гына гомерендә күп мәшәкатьләр, тарлыклар күргән, әмма аңа карап илһамы кимемәгән, киресенчә, арта гына барган Тукайны китерә, аның әнисенә булган мөнәсәбәтен күкләргә күтәрә: *«Аның иң җазибәле (үзенә тарта торган), иң тәэсирле шигырьләре дә шул тарлыкка төшкән вә изелгән вакытында сөйләгән шигырьләре, илһамы килгән вакытлары да шул күңеле сынык, күзе яшьле вакытларыдыр. Ана шәфкатенә, ата тәрбиясенә туймаган мескен, ятим Тукай үзенең шәфкатьле анасын гүзәл, мөәссәр (тәэсирле) шигырьләре берлә милләтенең күзе алдына бер мөкатдәс, очып китәргә торган нурани (нурлы) фәрештә төсле итеп бастырып куя. Ник ул да анасын бер шәфкатьсез гыйфрит кеби итеп күрсәтми? Чөнки ул анасының шәфкатьле, җылы кочагына туймаган, дөньяга килгәннән ахыр гомеренә кадәр бәгъре бирьян (куырылган), күзе гирьян (күз яше түгүче) булып, ач вә ялангач ятлар ишегендә сөйрәлеп, ятимлекнең ачысын татыган».*

Шәһит Әхмәдиев: «Һичбер кайдан ышык таба алмаган»

Язучы һәм сәясәт эшлеклесе Шәһит Әхмәдиевнең (1888-1930) «Шагыйребез Габдулла Тукаевның хатыннарга карашы» дигән мәкаләсендә (1914 елгы 11 нче сан) татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге, тормыштагы авыр хәлләре сурәтләнә. Автор Тукайның «татар хатыннарының күбесе күрә торган ачы тәкъдирне» ни дәрәҗәдә тирән һәм гадел сурәтләвенә соклануын белдерә. Ул аны хатын-кыз психологиясен шактый яхшы чамалаган шагыйрь итеп сурәтли, *«һичбер кайдан ышык таба алмаган»* татар хатынының *«кайгысына, хәсрәтенә шул*

дəрəҗəдə килеп кушылуын, гүя үзе шул татар хатынының көенə-хəленə төшкəн дə, үзе шулай яна, əрни, зəхмəт чигə», дип бəяли. Автор билгелəвенчə, Тукайны чын мəгънəсендə татар хатыннарының хокукы өчен тырышучы милли шагыйребез дип атарга мөмкин, чөнки ул əсəрлəрендə хатыннарның төрлечə зəхмəт чигүлəрен тасвирлый, бу зəхмəтлəрнең сəбəбе аларның хокуксызлыгыннан килə дип саный.

Лотфи Гадел: «Зинданга салынганлыкларын күреп ачына»

Язучы һəм журналист Лотфи Гаделнең (1894-1915) «Хатыннар турында Тукай» мəкалəсендə дə бу тема дəвам иттерелə. Автор: *«Шагыйрь бичара туташларның яшьтəн үк зинданга салынганлыкларын күреп ачына, аларның яшьтəн үк ирек күрми килүлəрен сөйли»,* – ди. Татарлардагы «хан заманасыннан» үк калган гадəтлəр – яшь кызларны көчлəп карт ир-атларга кияүгə бирүне, күп хатынлылыкны ачы тəнкыйть утына алуын хуплый. Һəм, əлбəттə, шагыйрьнең хатыннарга чын мəгънəсе белəн хокук бирдерергə телəвен аклый, мисал итеп «Хатыннар хөррияте» шигырен китерə.

Гариф Батыршин: «Каберенə таш куелмады»

Татар җəмəгатьчелеге Габдулла Тукай исемен күтəрү, аны мəңгелəштерү өчен əлегəчə əллə ни зур эшлəр эшлəнмəвенə борчылуын, татарга бөтенлəй катнашы булмаган кешелəрнең Тукай исеменнəн файдалануына ризасызлыгын белдерə. Тукай вафатыннан соң күп тə үтми, Мəскəүнең «Стулкинд» яһүд фирмасы, шагыйрьнең рəсемен төшереп, «Тукай сабыны» сата башлый, ə Тукайның кабере һаман да ихатасыз, ташсыз. «Сөембикə»дə басылган мəкалəнең авторы мулла Гариф Батыршин да (1871-1930дан соң) бу хəлгə борчылуын җиткерə: *«Милли шагыйремез Габдулла Тукайны сəламəт вакытта кадерли-тəрбияли алмасак та, үлгəч тəрбиялəп күмгəн идек. Тəгъзия (кайгы уртаклашу) телеграмнары да яңгыр кеби яуган иде. Татар миллəте сүздəн эш дəверенə күчеп җитə алмаганмы, яхуд башка сəбəплəрдəнме? Милли шагыйренең намен мəңгегə калдыру хосусында бер төрле җитди тəдбирлəр (эшлəр) кылынганы юк əле. Шагыйрьнең каберенə таш куелмадыгы, каберенең тирəсе тотылмадыгы һəркемгə мəгълүмдер. Бу исə татар миллəтенең мəдəни гөнаһысыдыр»,* – дип яза.

***

Тукай татар өчен мəңгелек моң, мəңгелек зар, мəңгелек рух. Тукай – исеме гасырларга калырлык бөек шəхес, миллəтебезнең югалмас символы. Моның шулай булуы Тукайны югалтканнан соң аеруча ачык күренгəн, еллар үткəн саен без моңа күбрəк ышанабыз. Шуңа күрə, Чыгтай сүзлəре белəн əйткəнчə, *«шəм кебек сүнсə дə, аның наме калды. Яшəсен Габдулла Тукайның наме, бу дөнья шары кояш тирəсенə кушылып янганча яшəсен!»* ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

Нократ татарларына разведка

Миркасыйм Госманов



Миркасыйм Госманов энеләре Әдһәм һәм Гаднан белән. Казан, 1966 ел

Язма VI археографик сәфәр көндәлеге нигезендә әзерләнде. Ул 1966 елның 27-31 август көннәрендә Киров өлкәсенең Слободской районындагы Нократ авылына оештырылган.

Сәфәргә көтмәгән, уйламаган җирдән чыгып киттек. Чөнки Киров өлкәсе – Нократ татарлары арасында йөргән Рафаэль Ник[олаевич] Степановтан (безнең кафедраның ассистенты) хәтәр генә телеграмма килеп төште: *«Нократ татарлары тарихына караган шундый хикмәтле язу табылды, аны уку өчен М.Усмановның килүе шарт!»* Телеграмма 25 августта алынды. Аспирантлык каникулымда йөрүемә карамастан, кафедра мөдире минем барып кайтуымны үтенде, чөнки бу телеграмма аны да «интриговать» итте. Мин тиз-тиз юлга җыена башладым һәм икенче көнне сәфәргә әзер дә идем.

Рафаэль Степановның «татар» археографиясенә чыгып китүе үзенә бер тарих. Кызу гына кабул итү имтиханнары бара иде. Рафаэль – имтиханчыларның берсе. Ә Г.Ф.Шамов (безнең кафедра мөдире) – гомум җитәкче. Менә шунда алар арасында конфликт чыга: яһүдләр аркасында... Яһүд дуслары күп булган Степановны Шамов «юлдан алып торырга» ниятли һәм беркөнне миңа: «Степановка берәр командировка уйлап тап әле, бераз йөреп кайтсын», – диде.

Мин шунда ук Нократ татарларына разведка ясауның кирәклеген белдердем: татарча бернәрсә белмәсә дә, кайбер мәгълүматларны җыя алыр… Конфликттан соң аптыраудан, дөресрәге, «ике ут» уртасында «пешеп» йөргән Рафаэль дә тәкъдимне бик риза булып кабул итеп, ике көннән китеп тә барды… Һәм менә сенсацион телеграмма да килеп төште.

(Гыйбрәт булсын өчен моны тулырак яздым, янәсе очраклылык археография өчен бигрәк тә хас!)

***

27.08.1966. Төш вакытында Казан-Киров поезды белән юлга чыктым. Көн болытлы, яңгырлы иде.

28.08.1966. Поезд иртәнге 9да Киров шәһәренә җитте. Телеграмма буенча, вокзалда Рафаэль көтеп тора иде. Бергә-бергә гостиницага киттек. Малай шактый каңгырып, берничә әһәмиятле генә татар авылын актарып өлгергән икән… Әйтүенә караганда, кызыклы гына, мәгәр, моңа хәтле беркемгә дә мәгълүм булмаган бер кабер ташы тапкан.

Бер-ике сәгать шәһәр буйлап йөрдек, ары-бире кагылдык. Шәһәр болай ярарлык кына кебек, үрле-кырлы җирдә утыра, борынгы агач йортлар да шактый, ләкин үзе чиста гына…

Төштән соң Слободской шәһәрен үтеп, Нократ авылына килдек. Шәһәргә хәтле юл бик яхшы иде, ләкин авылга кадәр бик авыр комлы юлны уздык. Авылга кичке биштә генә җиттек. Рафаэль табып куйган фатирга урнашкач, прогулка итеп, әлеге ташка киттек.

Бу Нократ (Карино) ике өлештән гыйбарәт: Түбәнге Нократ, ул үзәндә, тау төбендә һәм Югары Нократ, монысы тау башында (арасы 1,5 км). Боларның берсе русча Верхнее Карино дип тә атала, икенчерәк – Лель исемле дә икән. Ә Түбән Нократ исә татарча Түбән авыл дип, русча Нижнее Карино дип йөртелә. (Түбән Каринода Абашева Галия дигән кешене күрергә кирәк.)

Рафаэль тапкан әлеге таш Югары Нократ янында икән. Килеп җиттек. Рәшәткә белән әйләндереп алынган ялгыз кабер; өстендә бер куак үсеп утыра. Таш ике кисәккә бүленгән булган да, җир өстендә аның кечерәк югары өлеше калган, ә икенчесе – туфрак астында.

Ачык ятканының биеклеге – 65-70 см, киңлеге – 60 см. Язуы бик начар сакланган, шулай да укып була:

فاتحة

بسم اللة الر

رحمن الر حبهم هو

لا يموت...

Бу формула буенча реставрацияләү проблема түгел. Ә менә аста нәрсә язылган икән? Димәк, ташның җир астындагы өлешен дә казып алырга кирәк. Бу инде иртәгә булыр…

Кайтышлый, авылның яңа зиратын барып карадык. Артык бер әйбер дә юк. Тик бер таштагы символик итеп өзелгән ландышны ясаган рәсем генә шактый матур. Ташны 1916 елны куйганнар. Кайтып ял иттек.

Кичен, кулъязмалар эләктереп булмасмы дип, Әухәт абзый дигән куркак кына бер муллага барып, озак гына әңгәмәләшеп утырдым. Ниятем – бүген аны бераз күндереп кую, аннары кулъязмаларны сорый башлармын.

29.08.1966. Иртән тагы Югары Нократка мендек. Авыл кешеләреннән бер-ике көрәк алып, ташның төбен казый башладык. Ташның (ләүхәнең) җир астындагы өлеше зур таш икәнлеге нигезгә чәнчеп куелган икән. Югары Нократ карты Сафиулла Девятьяровның әйтүенә караганда (аңар 71 яшь), ул белгәннән бирле таш шулай ватык килеш яткан.

Казу дәвам итә. Кызу эшләүдән бармаклар уелып чыкты. Ял иткән арада Сафиулла абзый белән Югары Нократның көньягындагы «Кала тау» дигән түбәчекне барып карадык. Бу түбәчек белән авыл арасында бер ерганак – «Кала»ның бер ягы, табигый яр (тау бите), ә икенче ягы зур таудан махсус үр белән аерылып алынган. Кыскасы, тауның сузылып чыккан борынын кальга ясар өчен файдаланганнар. Койма – вал нигездә, бу сизелеп ята. Түгәрәк крепость булган. Әйләнәсе – 300 м, диаметры – 100 м (адымнар буенча да 95-100 һәм 290-300 адым).

Риваятькә караганда, элек бу җирне сукалаган чакта тимер-томыр чүлмәк ватыклары чыга торган булган. Шулай ук күмер, акбур да очрый, имеш.

Кызыклы, бик кызыклы. Яңадан әлеге каберебезне казый башладык. Ниһаять, ташның аскы өлеше дә, ул утырган нигез дә килеп чыкты. Таш кыеклап кына ватылган булган, язулар да җимерелеп беткәннәр, шулай да түбәндәге сүзләрне укып була:

قابري تورر....

... توغو يوز...

= XVI гасыр

Фундамент шактый капиталь эшләнгән: язулы ташның түбән очын уртадан тишелгән икенче зур ташка чәнчеп куйганнар, рәсеме шулай: [рәсемне карагыз. – ***Ред.***]



Бар тапканыбыз, ачыклаганыбыз менә шулар гына булды.

Кайтышлый, иске зиратларының берсендәге ташларны карадык, анда да шактый борынгы берничә таш бар. Аларны Һ.Йосыпов үз китабында бастырып чыгарган...

Кичке якта Әүхәт абзыйга бардым. Ул биш кульязма бирде. Өмми Кәмал әсәрләре бар, Г.Утыз-Имәни һ.б. китаплар. Димәк, монда кульязмалар табылу ихтималы зур. Ашап-эчеп алгач, кичкә машина белән Слободскойга килдек. Бу төн шунда узды.

30.08.1966. Слободской шәһәрен карап, кайбер вак-төякләрне бетергәч, Кировка кайттык. Анда шактый гына киләп сарып йөрдек. Китап кибетләрен актардык. Берничә кызык кына әйбер бар. Кичке якта поездга утырып, Казан тарафына киттек. Көн болытлы, салкын, ямьсез иде...

31.08.1966. Казанга сау-сәламәт кайтып җиттек. Исәп-хисапны бетердем.

Нәтиҗәләр:

1. Рафаэль шаулаган таштан рәт чыкмады, чөнки текст сакланмаган. Шулай да XVI гасыр ташының ул якларда булуы кызыклы. Һ[арун] Йосыпов бастырган ташның берсе дә шул дәвергә тарта бит. Киләчәктә тагы да борынгыларының табылуы ихтимал...

2. Юл уңаенда табылган кульязмаларның да бер-икесе ярарлык. Габдерәхим Утыз-Имәнинең порнографиясе белән шунда якыннан таныштым. Менә сиңа «мулла»! Өмми Кәмалның «диваны» да кызыклы гына. Димәк, бу якларда өмет бар.

«Халыкның сөйләшүенә караганда, бу тирәдә элек татарлар руслар белән бик дус булып яшәп, Казанны яулаган чакта руслар ягында сугышканнар. Шуның өчен дә рус патшалары аларга җир биргән... Һәрхәлдә, монда археологик планда эшләрлек эшләр бар икән...

3. Археологик яктан «Кала тауны» җентекләп тикшерү бик кызыклы булыр иде. Халыкның сөйләшүенә караганда, бу тирәдә элек татарлар руслар белән бик дус булып яшәп, Казанны яулаган чакта руслар ягында сугышканнар. Шуның өчен дә рус патшалары аларга җир биргән... Һәрхәлдә, монда археологик планда эшләрлек эшләр бар икән...

4. Нократ татарлары тел ягыннан да кызыклы, киң әйтешле «э»нең активлыгы белән аерылып тора: белэн, кэлэлэр (э=и, э=ә). Вокализм системасы бик үзенчәлекле. Лексикада да үзенчәлекләр шактый.

Гореф-гадәттә дә аермалыклар бар. Кыскасы, төрле яклап тикшерергә лаеклы бер төбәк.

Көндәлекне басмага тарих фәннәре докторы
***Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

Тукайга киемне кемнәр теккән?

Халидә Габидуллина*

Габдулла Тукай Гөберчәк авылы остасы Гатиятулла Шәрәфиев тегеп биргән тужуркадан. Җаек шәһәре, 1907 ел

Гатиятулла: «Тукайның өс киемен мин тегеп биргән идем»

Мөхәммәт Мәһдиев «Габдулла Тукай турында замандашлары» исемле мәкаләсендә Гөберчәк авылында туып, шунда яшәгән авылдашларыбызның шагыйрь белән якыннан аралашуы, аңа киемнәр тегеп бирүе хакында яза. Гатиятулла Шәрәфиев – шундый осталарның берсе. Авылда аны, исемен кыскартып, Гатият дип кенә йөрткәннәр. Ятимлектә үсә ул. Аннары бәхет эзләп ерак җирләргә чыгып китә һәм Җаек шәһәренә барып урнаша. Шәһәрнең оста куллы тегүчесе Хәкимҗан аны үзенә сыендыра һәм егетне тегүче һөнәренә өйрәтә. Гатиятулла Шәрәфиев шул елларда Габдулла Тукай белән таныша, аның белән аралаша. Шагыйрь, үзе тукыма алып биреп, остадан киемнәр тектерә.

* Габидуллина Халидә Кыям кызы – Арча районының Гөберчәк авылындагы Мөхәммәт Мәһдиев музее мөдире.

Мөхәммәт Мәһдиев тегүче авылдашыбызның өенә махсус барып, аннан Г.Тукай белән ничек танышуы, аралашуы турында сораша, мәгълүматлар язып ала. Ә сөйләшергә яраткан Гатият абзый язучының сорауларына иркенләп җавап бирә. Кыю йөрәкле, һәрнәрсәне төгәллек белән сөйләргә яраткан тегүчебез танылган артист Габдулла Кариев белән дә аралашуы һәм дус булуы хакында сөйли.

«Ак» тегүче Гатиятулла Шәрәфиев

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәрендә «Җиде аршинлы бүрәнә белән...» дигән бүлек бар. Шунда автор Гөберчәк тегүчеләре хакында яза: *«Безнең авылда алты тегүче булып, болар ак һәм кара тегүчеләргә бүленәләр иде. «Аклар» – пәлтә, бүрек, костюм, мундир, тужурка; «каралар» толып, тун, тире чалбар, бишмәт тегәләр иде. Культурныйлар һәм гади тегүчеләр...»*

Аңлашыла ки, Гатият абзый «ак» тегүчеләр сафына керә. Ул Габдулла Тукайга тужурка тегеп бирә. Гатият олы гәүдәле, кечкенә генә ап-ак сакаллы, көрәк кадәрле зур куллы кеше була. Ул һәрвакыт башына кәләпүш, өстенә үзе теккән күлмәк киеп йөргән. Авылның оста көрәшчесе дә булган әле Гатиятулла. Ул башкалардан юмартлыгы белән дә аерылып торган, урамнан үтеп киткән сабыйларга күчтәнәчләр бирергә яраткан. Гатиятулла күрше-тирәдәгеләрнең чалгыларын янап, кирәк булса, таптап та биргән. Гомумән, кешеләргә бик ярдәм иткән, аларга эшләргә һәрвакыт уңайлы булсын дип тырышкан ак сакаллы карт. Урманнарның чамасыз киселүенә, табигатьнең үзгәрүенә, ярлылануына эче пошкан аның. Гөберчәк авылы элек урманга терәлеп үк торган, вакытлар узу белән, агачларны кисеп, җирен сөргәннәр. Шулай итеп колхоз басуларын зурайтканнар.

Гатиятулла ага бик матур һәм моңлы итеп җырларга да яраткан. Кичләрен, капка төбенә чыгып, тальянында татар халык көйләрен сузган. Төрле такмаклар чыгарырга да оста булган ул. Сәләтле, матур итеп җырларга һәм сөйләргә яраткан, нык хәтерле, ләкин укый-яза белмәгән авылдашыбыз капка төбенә чыгып утырса, аның яныннан кеше өзелмәгән. Ул еш кына Габдулла Тукай һәм Габдулла Кариевлар турында мавыктыргыч истәлекләрен сөйләгән. Бөек шагыйребезнең әсәрләрен ишетсә, йотлыгып тыңлаган. *«Китапларда Габдулла Тукайның бер фотосы бар. Ул анда кулына газета тотып төшкән, ә өс киемен мин тегеп биргән идем»,* – дип искә алырга яраткан Гатиятулла ага.

Гөберчәктә Бөек Ватан сугышына кадәр тегү артеле оеша. Гатиятне шунда эшкә чакыралар, әмма ул риза булмый, колхоз эшенә бара. Күбрәк әвеслектә хезмәт куя, салам кибәннәрен очлау буенча аннан да җитезрәк һәм остарак кеше булмый.

Гатият ага 1962 елда вафат була. М.Мәһдиев: *«Малайлары сугышта үлеп беткәннәр, бер генә оныгы да юк»,* – дип яза. Әмма язучы аның кече улы Гыйлемхан турында искә алмый. 1927 елгы Гыйлемхан Миңкамал белән гаилә кора, уллары Гайнулла дөньяга килә. Гыйлемхан аганың да, улы Гайнулла абыйның да тальянда

өздереп уйнаганнарын мин үзем дә хәтерлим. Гыйлемхан абый минем әтинең өченче буын туганы да иде әле. Алар аралашып, туганлык җепләрен өзмичә яшәде. Элек кунакка йөрешүләр дә еш иде бит. Ул вакытта мин кечкенә кызчык булсам да, әлеге нурлы йөзле кешеләр хәтеремә нык уелып калган. Кызганыч, бу абзыйлар Гатият аганың һөнәрен дәвам итмәгән. Бабаларыннан калган тегү машинасын Гайнулла абый һәм аның хатыны Әнисә апа кадерләп саклаган. Әмма Мөхәммәт Мәһдиев: *«Музейга тапшырам, бу бик тә истәлекле тегү машинасы!»* – дип, аны хуҗаларыннан сорап алган һәм Гөберчәк авылыннан алып киткән. Кыйммәтле ядкяр музейга барып җиткәнме, анда сакланамы – монысы әлегә безгә мәгълүм түгел.

Тукайга кием теккән машина әле дә текелди

Революциягә кадәр Казан байларында тегүче булган авылдашларыбыз Һидиятулла Хәйруллин белән Хәлил Хәбибуллин да Габдулла Тукайны яхшы хәтерләп, бу хакта Мөхәммәт Мәһдиевкә сөйләгәннәр. Киң күңелле, балалар яратучы Һидиятулла агай Гөберчәккә кайтып гаилә кора, балалар үстерә. Зур гәүдәле, сакал-мыеклы, кара кысалы күзлек кигән авылдашыбыз Гөберчәкнең тегү артелендә хезмәт итә. Аның яшь һәм тәҗрибәсез хатын-кызларны тегүчелек һөнәренә өйрәтүе мәгълүм.

Атаклы тегүче
Хәлил Хәбибуллин гаиләсе белән

Габдулла Тукайга кием теккән
тегү машинасы

Гөберчәкнең тегү артеле хезмәткәрләре. Сулда – артельне оештыручы тегүче Рәхимулла Хәнәфиев, икенче рәттә – атаклы тегүче Хәлил Хәбибуллин, алда утырган – Һидиятулла Хәйруллин. 1950 нче еллар

Бер-берсенә охшамаган ике һөнәр иясе: оста тегүче һәм механизатор Мөхәммәтнур Хәлил улы

Сул яктагы бабай – Хәлил, аның килене Тәскирә һәм оныгы Ленар

Тәскирә Хәйбина белән музей җитәкчесе Халидә Габидуллина. 2016 ел

Игътибар итегез: фотолардагы авылдашларымның киемнәре хәзерге замандагы кебек Кытай, Төркия, Вьетнам базарларыннан сатып алынмаган. Аларны Гөберчәк халкы үз куллары белән теккән!

1891 елда туган Хәлил Хәбибуллин, Казан баенда тегүчелек эшенең бар нечкәлекләренә өйрәнеп, үзенә тегү машинасы сатып ала. Габдулла Тукайга костюм, кепка тегеп бирә ул. Байда эшләп, байтак акча туплый һәм авылга җигүле ат белән кайтып төшә. Репрессия елларында Хәлилгә барлык мал-мөлкәтеннән, аеруча яраткан атыннан колак кагарга туры килә. Оста тегүче буларак, хуҗалыгы нык, абзары тулы мал-туары була аның. «Син бай кеше, кулак!» – дип, Хәлил Хәбибуллинның Г.Тукайга кием теккән машинасын, хуҗалыгындагы барлык әйберләрен тартып алалар. Хәлил тегү тегеп эшләп алган акчасына яхшы токымлы Әрмәс кушаматлы ат сатып алган була. Аны да колхозга алалар. Бу атны, бик аз гына вакыт колхозга хезмәт иткәннән соң, суялар. Конфискация вакытында өйдә берданбер әйбер – кайчы кала. Аны да Хәлилнең хатыны Бибиниса бала имезеп утыра торган утыргычның киез астына яшереп кала. Әлбәттә, ялтырап торган, авыр тимердән эшләнгән кайчы Габдулла Тукайга теккән киемнәрнең материясен кискән кайчы була. Бу кайчы Хәйбиннар гаиләсендә 2010 нчы елларга кадәр саклана. Хәлилнең 1930 нчы елларда алып киткән барлык мал-мөлкәтен дә сатып бетерәләр. Тегү машинасын исә Хәлилнең бертуганы булган Зәйнәпнең ире Галимулла сатып ала һәм хуҗасына кайтарып бирә. Ә Хәлил машина өчен бурычны киемнәр тегеп түли.

Кызу холыклы, пөхтәлек һәм төгәллекне үз иткән Хәлил зур бер түрәгә кием тегеп бирә. Бераздан аны «югары»га чакыртып алалар. Репрессия еллары була бу. Шулай итеп, Хәлил гаиләсе белән саубуллашып чыгып китә. НКВД вәкиленә тегелгән

Гөберчәк халкын эшле һәм ашлы иткән тегү артеле хезмәткәрләре. Беренче рәттә утырганнар арасында уң яктагы ир-ат – Хәлил Хәбибуллин, уртада – артель җитәкчесе Рәхимулла Хәнәфиев, сулдагы ир-ат – Һидиятулла Хәйруллин.

Тегүче һәм алдынгы колхозчы Хәйбиннар гаиләсе Сабан туена бара. 1980 нче еллар

киемнең хәтта җөе дә күренмәгән була. Аны әлеге киемне ничек итеп тегүе хакында сорашырга чакырган булганнар икән!

Талантлы авылдашыбыз бер генә минутны да бушка үткәрми, хатыны Бибинисаны да тегәргә өйрәтә. Үзе ял иткән арада тегү машинасында хатыны эшли. Ике бала тәрбияләп үстерә алар. Балаларга да тегү эшенең бар нечкәлеген өйрәтә Хәлил. Авылдагы тегү артелендә озак еллар оста буларак хезмәт итә ул. Артельдәге күпме хатын-кыз аннан тегүчелек һөнәренә өйрәнде икән?! Бакча эшен дә яратып башкара. Хәлил аганың гомере 1975 елда өзелә. Совет чорында да ислам диненә тугры калып, биш вакыт намаз укыган, азан әйткән мөхтәрәм авылдашыбызның урыны җәннәттә булсын!

Кайчандыр Габдулла Тукайга кием теккән Хәлил абзыйның тегү машинасы бүген дә Хәйбиннар гаиләсендә саклана. Саклана гына түгел, ә һаман да элеккечә үк текелдәп тора. Хәлилдән соң улы Мөхәммәтнур тегүчелек белән шөгыльләнсә, бүген аннан оныкһәм оныкчыклары файдалана.

Шунысын да искәртик: Тәскирә Габделкадыйр кызы Хәйбина (1921-2018) – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» романы, «Торналар төшкән җирдә» повестендагы герой Асиянең прототибы. Ә Мөхәммәтнур Хәлил улы Хәйбин (1924-2006) – Бөек Ватан сугышы ветераны, ТАССРның атказанган колхозчысы, М.Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» романы, «Исәнме, Кәшфи абый!» повестендагы төп геройның прототибы. Оста тегүче һәм механизатор, тракторчылар бригадиры Мөхәммәтнур ага хатыны Тәскирә апа белән җиде бала тәрбияләп үстерде. Хәйбиннар Мәһдиевләр гаиләсе белән дустанә яшәгән. Язучы авылга кайткан вакытта аларга кермичә, хатирәләре белән бүлешмичә китмәгән. Хәтта бер кайтуында Г.Тукайның шигырьләр китабын бүләк иткән. Кызганыч, язучы аңа култамга куймаган. Бу китап хәзерге көндә М.Мәһдиев музеенда саклана.

Бөек шагыйрь яшәгән чорның оста тегүчесеннән мирас булып калган тегү машинасының Гөберчәктә әле дә халыкка хезмәт итүе безнең өчен зур горурлык! Мөхәммәт Мәһдиев: *«Гөберчәк авылы – элек-электән һөнәрчеләр авылы»,* – дип язып калдырган. Тегүче авылдашларымның игелекле хезмәтләре моны янә бер мәртәбә раслый. ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

Зәйтүнә Мәүлүдова мирасы – музейларда

Гүзәл Төхвәтова

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.
Габдулла Тукай «Мәхәббәт»

Г.Тукай әдәби музееның яңа экспозициясе – «Шагыйрь мәхәббәте»

Г.Тукай әдәби музеендагы яңа экспозиция – «Шагыйрь мәхәббәте» дип атала. Габдулла Тукайның мәхәббәт турында утызга якын шигыре бар. «Гыйшык бу, йа!» (1906), «Хур кызына» (1906), «...гә («Очраган юлда...») (1907), «Утырышу» (1907), «Мәхәббәт» (1908), «Кызык гыйшык» (1908), «Бер рәсемгә» (1908) һәм башка шигырьләре аның эчке тирән хисләрен һәм мәхәббәтен чагылдыра. Тукайның илһамчысы (бәлки, илһамчыларның берседер) – яшь кыз Зәйтүнә Мәүлүдова. Шагыйрь белән алар «Әлислах» газетасы редакциясендә таныша. Аннан соң берничә тапкыр очрашалар, әмма хисләрен Тукай да, Зәйтүнә дә бер-берсенә белдерми.

З.Мәүлүдова язмышын өйрәнүнең һәм музейда чагылдыруның әһәмияте га-

ять зур. Беренчедән, самими кызның Г.Тукай турындагы истәлекләре аша бөек шагыйребезнең хиссиятен тирәнрәк аңлый алабыз. Икенчедән, XX гасыр башында белем алган һәм соңрак үзе дә бик күп еллар укытучы вазыйфасын башкарганлыктан, З.Мәүлүдованың язмышы мәгариф тарихы өлкәсендәге мәгълүматларны тирәнәйтергә мөмкинлек бирә. Өченчедән, язмаларда аның улы, танылган язучы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Атилла Расихның (1915-1995) тормышы ачыла.

З.Мәүлүдованың документлары һәм шәхси әйберләре (барлыгы 24 предмет) Татарстан Республикасы Милли музеена һәм Г.Тукай әдәби музеена 2002 елда оныгы, язучы Атилла Расихның кызы, шагыйрә Фәридә Рәсүлова тарафыннан тапшырыла. Хәзерге көндә фондта аның белән бәйле предметларны дүрт төркемгә бүлеп карарга мөмкин: 1) шәхси документлар; 2) көндәлекләр; 3) Г.Тукай шигырьләре тупланган блокнотлар һәм бөек шагыйребезгә багышланган истәлекләр; 4) ире Кадыйр Рәсүлов, әтисе Хәйдәр һәм улы Атилла Расих белән бәйле предметлар.

Документлар арасында З.Мәүлүдованың паспорты, Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлау турындагы таныклыгы, Казан Дәүләт педагогика институты дипломы, укытучылык аттестаты, хезмәт кенәгәләре, автобиографиясе һәм ире Кадыйр Рәсүлов белән аерылышу таныклыгы бар.

Зәйтүнәнең автобиографиясе

Зәйтүнә Мәүлүдова

З.Мәүлүдованың 1935 елда язылган, хәзер музейда саклана торган автобиографиясеннән күренгәнчә, ул 1896 елда Чистай шәһәрендәге вак һөнәрче гаиләсендә туа. Башлангыч белемне Чистайда ала. 1907 һәм 1909 нчы елларда Югары Курса авылында укый һәм үзе дә балаларга белем бирә. Шуннан соң бер ел Иж-Буби мәдрәсәсендә укый. 1911-1914 нче елларда Җаек шәһәрендә укытучы булып эшли һәм шунда ук 1914 елда күренекле дин әһеле, ишан Зәйнулла Рәсүловның улы Кадыйр Рәсүловка кияүгә чыга. Яшьләр шул елның июль аенда иренең укый торган җиренә – Төркиянең Истанбул шәһәренә күчеп китәләр. Беренче Бөтендөнья сугышы елларында З.Мәүлүдова Истанбул халык университетында һәм тәрбиячеләр курсында белем ала. 1918-1922 нче елларда Зәйтүнә ханым ире белән берлектә Җаек шәһәрендә укытучы булып эшли, аннан соң, 1929 елда Казанга кайтканчыга кадәр, өйдә хуҗалык эше белән генә шөгыльләнә. Өч ел Питрәч районының Шәле авылы мәктәбендә укытканнан соң, ул Казан шәһәре мәктәпләренә эшкә күчә. Автобиография З.Мәүлүдованың 1932 елда Казан дәүләт педагогика институтына укырга керүе хакындагы мәгълүмат белән тәмамлана.

Мирсәй Гариф: «Ярый әле Зәйтүнә таныклык алырга өлгереп кала»

Алда әйтелгәнчә, З.Мәүлүдова 1909-1910 нчы елларда Иж-Буби мәдрәсәсендә белем ала. 19 нчы йөздә һәм XX гасыр башында Иж-Буби мәдрәсәсе татар дөньясында иң алдынгы уку йортларыннан саналган. Аны тәмамлаган шәкертләр дә үзләренең белемлелеге, гыйлемлелеге, дөньяга киң карашлы булулары белән аерылып торган. Язучы Мирсәй Гариф «Мәңгелек мәхәббәт» китабында түбәндәгеләрне бәян итә: *«Ул [З.Мәүлүдова] Казанга, абыйларыннан укырга җибәрүләрен үтенеп, тәфсилле озын хат яза. Шакир абыйсы аналарына җавабында: «Без барыбер Чистайга кире кайтмабыз инде. Өйне сат та Зәйтүнәне Бубига илтеп куй. Без үзебез дә укый алмадык, ичмаса, Зәйтүнә белемле булсын», – дип яза. Абыйлары, аналарына фатир хакы түләү өчен, Чистайга ай саен акча җибәреп торырга булалар. Әниләре, улларының сүзен тыңлап, өйне сата, Зәйтүнәгә шул акчадан бер сак (пальто), бер пар ботинка, кәлүш ала, әле укулар башланмаган булса да, кызын Бубига үзе илтә китә. Зәйтүнә, бик нык әзерләнеп, сигез сыйныфлы мәдрәсәнең алтынчы сыйныфына имтихан тота. Монда ул ислам дине, Көнчыгыш гыйльме-фәлсәфәсе, дөньяви фәннәр буенча белем ала. (...) Зәйтүнә, үзенең зирәклеге һәм тырышлыгы аркасында өчьеллык программаны бер кышта үзләштереп, таныклык* алуга ирешә һәм аңа мөгаллимә булып эшләргә мөмкинлек туа. Ярый әле Зәйтүнә таныклык алырга өлгереп кала. 1911 елның башында җәдитчелектә гаепләп һәм панисламизм коткысы тараталар дип, мәдрәсә мөгаллимнәрен кулга алалар, ә шәкертләрне куып, уку йортын тараталар».*

Атилла Расих: «Бу аерылышу фактик гамәл түгел иде»

З.Мәүлүдованың тормышында авырлыклар да шактый күп була. Кеше язмышы рәсми автобиография юлларына гына сыеп бетми, әлбәттә. Сәяси-иҗтимагый шартлар Рәсүлов-Мәүлүдова гаиләсенә шактый зур кыенлыклар, чикләүләр, хаксыз изелүләр алып килә. Шул гаделсезлекнең бер мисалы гаиләнең аерылышу турындагы таныклыкта чагылыш таба. А.Расих бу хакта болай искә ала: *«Аннан соң әниемнең әтидән аерылышуы турындагы ЗАГС таныклыгының күчермәсен алдым. Әлбәттә, бу аерылышу фактик гамәл түгел иде. Ничарадан бичара, дигәндәй, әниемә эшкә урнашу мөмкинлеге бирде».*

Г.Тукай әдәби музеенда саклана торган эш кенәгәләре – ачы язмышның тагын бер чагылышы. «Халык дошманы» хатыны саналып, укытучылык эшеннән чыгарсалар да, ул югалып калмый, ничек кенә булса да, авырлыктан котылу чарасын эзли. Атилланы Казанда фатирга урнаштырып, Питрәч районындагы Шәле авылына китеп балалар укыта, аннан Казанда бер мәктәптән икенчесенә күчеп йөрергә мәҗбүр була. Шулай да ул җәмәгать эшләрендә актив катнаша, күңелен төшерми. Укырга, белемгә омтылган яшь хатынга педагогия институтында укырга рөхсәт итмиләр. Соңыннан, укырга мөмкинлек булгач, ул институтның татар теле һәм әдәбияты бүлеген язучы Абдулла Әхмәт, Шәйхи Маннурлар белән бер елда уңышлы тәмамлый һәм аңа татар теле һәм әдәбияты белгечлегенә ия булуы турында диплом бирелә. Әлеге документ та музей фондларында саклана. Шунысын өстәп әйтергә кирәк: башка документлардан аермалы буларак, дипломда З.Мәүлүдованың туу датасы 1897 елның 16 августы дип күрсәтелгән.

---

* Таныклыкны Г.Тукай әдәби музее экспозициясендә күрергә мөмкин.

Р.Зарипова: «Бу гади генә көндәлек түгел»

Зәйтүнә ханымның көндәлек хатирәләре аеруча җанлы тасвирланган. *«Бу гади генә көндәлек түгел, ә билгеле бер дәрәҗәдә үзе яшәгән дәвернең иҗтимагый һәм рухи атмосферасын чагылдыра»*, – дип яза А.Расих иҗатын өйрәнгән галимә Р.С.Зарипова. Күңел дәфтәрләреннән кайбер юлларны укып китик: *«26.09.45. Һавалар шыксыз, көз килүен ачык күрсәтә. Һәркөн берничә мәртәбә яңгыр ява. Кайвакыт кояш та чыккан була. Күп вакыт үткән булса да, Атилла күренми. Кичә күбрәк йөргән идем дә, бүген йөрәк авыртып өйдә генә утырам. Ялгыз утырсам, эч поша, һич чыдар хәл юк. (...) 17.10.45. 13ендә яуган карга өстәлә-өстәлә, җир йөзе ап-ак булып капланган, кичләрен нык катыра, кайсы көнне көндезләрен йомшарта. Эч поша, йөрәк яна, кул бер эшкә дә бармый. Кыш та килеп җитте, ягарга утын юк, пароходлар да туктала. Атилла һаман кайтмый әле, белмим инде нишләргә дә. Барыннан да эч пошуы азаплый. (...)»*.

Тукай һәм Зәйтүнә мөнәсәбәте татар әдәбияты тарихына үзенчәлекле, ялкынлы мәхәббәт тарихы булып кереп калган. Бары тик берничә тапкыр гына күрешкән яшьләрнең бер-берсенә карата булган җылы хисләре, ихтирамы, хөрмәте күпләрне сокландырган. Тукай мәхәббәтен яулаган кызның бөек шагыйребез турындагы истәлекләре, аның шигырьләре тупланган блокнотлар Г.Тукай әдәби музееның кыйммәтле ядкярләре булып тора. *«Кешеләрнең кайсы мине Тукай хәтле Тукай шулай азапланып сөйгәч, Тукайга бармаган, аның мәхәббәтенә каршы мәхәббәт белән җавап бирмәгән, аңгыра, тупас кыз, аңламады, диләр. Кайсылары «үзенең мәхәббәте белән Тукайның йөрәген чарлап, аны матур сүзләр әйтергә мәҗбүр иткән, диләр. Кайсы сүзләр дөрес? Минем бу юлларны укыгач, укучы үзе хөкем чыгарыр...»* – дип башлана Зәйтүнә ханымның Г.Тукай турындагы истәлекләре.

***

ТР Милли музей фондында З.Мәүлүдованың гаиләсе белән бәйле предметлар да саклана. Мәсәлән, «Үрнәк» җир хуҗалыгыннан бирелгән белешмә. Биредә Зәйтүнә ханымның әтисе Хәйдәр Мәүлүдовның пыялачы булуы теркәлгән. Улы – «Ишан оныгы» кебек күренекле әсәрләр авторы, Г.Тукай премиясе лауреаты, дини нәсел дәвамчысы булуда нахакка гаепләнеп, репрессия ачысын татыган, әмма үзенең көчен югалтмаган, рухын сындырмаган Атилла Расихның мандолинасы, пеналы, почта кәгазьләре, каенатасы Зәйнулла Рәсүловның үлеме хакындагы таныклык, Зәйтүнәнең ире Кадыйр Рәсүловның кулъязмасы, пичәтләре бар.

Г.Тукай әдәби музеен­нан бер күренеш

Гомумән, Зәйтүнә Мәүлүдованың музей фондларында урын алган шәхси әйберләрендә һәм документларында XX гасыр татар тарихы чагылыш таба, илдә хөкем сөргән иҗтимагый-сәяси шартларның кеше язмышына тәэсире күренә. Шул ук вакытта аларда Зәйтүнә ханымның самими хисләре, дөньяга карашы, якты өметләре гәүдәләнә. ■

Блокноттагы истәлекләр

Игътибарыгызга Зәйтүнә Мәүлүдованың Казандагы Г.Тукай әдәби музее экспозициясендә саклана торган блокнотларыннан истәлекләр тәкъдим итәбез. Алар беренче тапкыр нәшер ителә.

Зиядә сәүдекем *(нык сөйгәнем)* Зәйтүнә апакаем!

Инсанның инсан улмакы гыйлеме бәрәкәтендә генә улыр. Чөнки гыйлем инсанны дөньяда вә ахирәттә газиз идәр.

Һөнәрле вә мәгърифәтле улырга тырышып, боннан соң мөслимәләр дә тәгълим-тәрбия турысында милләтемез сәгадәт эчендә яшәсен.

Сезе ифрат сәвән: М.Б.:
Мәрьям Бобинская (Буби).

Мәрьям Бобинскаяның (Буби) кульъязмасы

Якын танышларым вә дусларым!

Танышларымның мәгънәле фикер вә нәсыйхәтләрене җыйнап, анларны сагынган чакларымда күңелемне юату өчен, укырга карар биргәнлегемнән сезгә шушы альбомымны тәкъдим итеп, үзеңезнең каршыңызда хөрмәтле тотылган сүзләреңезне миңа ядгярән язып калдыруыңызны үтенәм.

Зәйтүнә Чистайлы.

Бик зур мәхәббәтләр илә сәүдекем *(сөйгәнем)* мәхәббәтле Зәйтүнәм!

Ничек ялгыз каберне күрсә юлчы,
Аннан ул китә алмас туктамыйчы,
Шулай бит, газизем Зәйтүнә?..
Бу саргаеп беткән кәгазь дә
Күз алдыңда торыр бит, Зәйтүнәм.
Һәр заманда озак тормам, җаным Зәйтүнәм, мин үләрмен.
Шулай итеп язмышым бурычын түләрмен.
Менә, мәхәббәтле Зәйтүнәм, шунда алырсың альбомыңны,
Укырсың шунда язган зар-моңымны.
Ничек янган, ничек яраткан сине Гөлсем, беләрсең,
Мине чынлап та яраткан, дуст күргән артык, диярсең.
Үзе юк моның, диярсең, ул югалган,
Бөһтан, ифтира *(яла ягу)*, хөседләрдән күңелен саклый алган.

Сине ифрат сәвән (сөйгән) вә синең рәхәтең өчен җанын фидая хазыйр хакыйкый (фида итәргә әзер) вә чын дустың Гөлсем Рәхмәтуллина-Пермьле.

Кем бәхетле?

Һәркем бәхет эзли. Ничек бәхетле булырга, ничек бай булырга? «Шул теләгем булса, башка һичнәрсә кирәкми – аннары мин бәхетле», – ди. Дөньяда кешеләр бик күптөрле була бит. Аларның теләкләре дә, үзләре кебек, төрлесенеке төрлечә: ярлы баерга тели, кол азад булырга, авыру сәламәтләнергә, аерылган кушылырга, кавышырга тели… Боларның һәрбере бәхетне үзләренең теләкләренә генә ирешүдә күрәләр. Һәм боларның күбесе теләгәннәренә ирешәләр дә. Ләкин ул бәхетле булдымы? Аның башка һичбер теләге дә калмадымы?

Юк, мең мәртәбә юк!

Бәлки, кеше теләгенә ирешкәннән соң үзендә әллә нинди бер эч пошу, рухында бик зур бер бушлык сизә. Шул бушлык хәтта аны газаплый да башлый. Соң алай булгач, бәхет нәрсәдә?

Бәхетме? Бәхет ул байлыкта да түгел, дәрәҗәгә ирешүдә дә түгел. Теләгенә ирешү белән дә кеше бәхетле булмый. Чөнки ул бәхет һәркемнең үз теләгендә; теләкле, бик зур теләкле булуда һәм шул зур теләк артыннан чабуда; шул зур теләккә ирешүне эчтән өмид итеп, шуңа ышанып, бөтен вөҗүдең, рухың, йөрәгең белән шуңа омтылуда.

Төрекләр: «Ирадә икътидардыр», – диләр. Бу бик дөрест: кешедә чын теләк кенә булырга кирәк. Шул булса, ул һәммә эшне булдыра ала. Күп кешеләрнең теләгенә ирешмәве аңа ныклап ышанмауларыннан, аны эчке йөрәкләреннән теләмәүләреннән килә…

Моңа караганда, безгә зур дәрәҗәләргә ирешү, тәрәккъый итү зур теләк (бөек әмәл), ныклы иман белән генә булса булыр…

Гыйбадулла Алпаров.
1914 ел, 29 апрель

Кадерле Зәйтүнә апага!

Күңел кошың канат җилпеп очмас борын,
Урман, таулар, диңгезләрне кичмәс борын;
Шатлан әле, сөй дөньяны, уйна да көл,
Тормыш тавы басып, кысып измәс борын.
Чык сахрага, рәхәт тормыш көен көйлә,
Сандугачың күкрәгеңнән бизмәс борын.
Киң диңгездә колач салып бер йөзеп кал,
Тулкыннары тау-тау булып купмас борын.
Каек белә әйләнмәдә әйләнеп кал,
Упкыннары мәңгелеккә упмас борын.

Ибраһим Һилалов.
Троицк.
3/5/1914

*Кулъязманы басмага **Ильяс Мөстәкыймов** әзерләде.* ■

Теләкләрем тормышка ашты

Фатиһ Кутлу

Төшемдә Тукай

2015 елда «Кардәш каләмнәр» (Төркия) журналы Тукайның 130 еллыгына багышлап махсус сан әзерләде. Шулвакыт мин: «Тукайны төшендә күрүче шагыйрь, язучы, галим, мөгаллим, укучы-шәкерт, артист, журналист яисә гади халыктан берәр кеше булдымы икән? Газета-журналлар шундый сораштыру оештырып, «Төшләрдә Тукай» исемле сәхифә ачсалар, ничек кызык һәм яхшы булыр иде», – дип уйлап куйган идем. Махсус сан әзерләгәндә дә, төрек шагыйре Али Акбаш белән бергә Тукайның 130 шигырен төрекчәгә тәрҗемә иткәндә дә, бөек Габдулланы төштә күрергә тилмердем. Әмма насыйп булмады.

Шуннан соң дүрт ел чамасы вакыт үтте. Ниһаять, 2020 елның 6-7 августында күрдем мин аны…

«Тукай ае» җитү уңаеннан, ул төшне сезгә дә сөйләргә булдым, хөрмәтле укучылар! Бәлки, сезгә дә андый төшләр кирәдер? Бәлки, сез дә, миннән күреп, алар белән бүлешә башларсыз?..

Имеш, Тукай вафат булган көн икән. Ул җан тәслим кылганда мин янәшәсендә торганмын. Шагыйрьнең җәсәде кәфенгә төрелгән, янына халык җыелган. Мәрхүмне яратып, мактап телгә алалар. Алар арсында мин хөрмәт иткән, олылаган зыялы татар танышым, бер төрек дустымның колагына пышылдап: «Фатиһ татар әдәбиятында мөһим эз калдырды», – ди. Аның бу сүзләрне әйтүе миңа бик сәер тоела. Ахырда мин: «Тукайны, җирләгәнче, башта безнең фатирга кайтарыгыз. Янында җыелып дога кылырбыз һәм шуннан җирләргә алып китәрбез», – дим. Эчемнән генә «ул мизгелләрне камерага да төшерермен» дип уйлап куям. Тәкъдимемне кире какмыйлар. Халык шәһәрара йөри торган зур автобусларга төялеп кузгала – анда гел яшьләр генә. Үзем исә алдан ук өйгә кайтып киткән булам. Чынлыкта без бишенче катта торсак та, төшемдә сигезенче катта яшибез икән. Ләкин фатир шул ук. Капма-каршы күршенең фатир ишеге дә шыр ачык. Мин, җеназаны алып килүчеләр бутамасын дип, безнең ишекне дә киереп ачып куям, шунда ак кәфенле Тукайны көтеп калам…

Лифттан дүрт кеше (ничек сыйганнардыр!) табутсыз, җәймәсез-нисез ак кәфенле Тукайны күтәреп алып чыктылар һәм, ялгышып, каршы ишеккә юнәлделәр. Мин, атылып килеп: «Юк-юк, монда алып керегез!» – дидем. Мәетне башы белән безнең ишектән кертеп, коридорга сузып яткырдылар. Аяк очлары бусагадан бераз чыгып калды. Аны китерүчеләр шунда ук күздән югалды.

Бу мизгелдә хатыным бүлмә ишеген ачып керде һәм мин уянып киттем. Төш тәэсирендә куркудан дер калтырыйм. Кухняга кереп дару тамызасым бар, тик үзем генә анда узарга куркам, бара алмыйм – әле генә кәфенле Тукайны шул кухня ишеге янында, коридорда күрдем бит! Югыйсә чын тормышта кәфенләнгән мәеттән бер дә курыкканым юк. Үз гомеремдә моның хәтле куркып уянганымны да хәтерләмим. Ахыр чиктә, белгәннәремне укып, хатын белән бергә кухняга кердек…

Иртә белән торуга бернинди курку-мазар юк иде. Безнең төрекчә төшлектән карадым, анда бу хакта «яхшы төш» диелгән. Ләкин тик торганда нигә мондый төш кергән соң? Һич аңламадым. Теге вакытта күргән булсам, бер хәл әле… (Хәзер исә ул чактагы теләк-догам, үз вакыты җитеп, кабул булган, ахры, дип фаразлыйм.)

Шушы төшемне бер төрек танышыма сөйләп бирдем (мин аны төш юрауда белгеч саныйм). Ул миңа: «Беренчедән, ак кәфеннән булгач, шагыйрьнең шәһит киткән булуы мөмкин (туп-туры җәннәткә керә дигән сүз); икенчедән, аның фикерләре сезнең йортыгызда яши һәм яшәячәк дигән мәгънә белдерүе ихтимал», – диде.

Күптән көтелгән очрашу...

Алдагы бүлектә билгеләп үткәнемчә, 2015 елда бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан «Кардәш каләмнәр» (Төркия) журналына махсус сан әзерләү максаты белән җиң сызганып эшкә керешкәндә килеп чыкты бу хәл. Ркаил абый Зәйдулла миңа Зәйтүнә Мәүлүдованың (шагыйрьнең сөйгәне) Тукай турында истәлекләрен[1] тәрҗемә итәргә киңәш бирде.

«...Мин Зәйтүнәнең ихлас, саф мәхәббәтенә сокландым һәм күңелемдә аңа карата ихтирам хисләре урнашты. Ихтыярсыздан, мәрхүмәнең каберенә барып, рухына дога кылу теләге туды. Ләкин, ни кызганыч, күпме сорашсам да, әлегә кадәр аның каберен белүче галим-голәманы, әдип-әдибәне очратмадым...»

2016 елның апрель аенда басылып чыккан язмам шундый юллар белән башланып китә...[2]

(Сүз уңаеннан искәртеп узыйм әле: олуг әдип Атилла Расих бастырган (үзе дә Габдулла Тукай бүләге иясе) бу истәлекләр миңа шулкадәр тәэсир итте ки, Ркаил абый биргән фотокүчермә битләрне без белән тишеп төпләп, каты тышлык белән тышладым; тышлыкка Тукай белән Зәйтүнәнең фотосын ябыштырып, төпләмгә хуш исләр сөрттем; исне яхшылап сеңдерсен дип, хуш ис тараткан әсбап белән бер тартмага тәүлек буена салып куйдым. Ркаил абыйга кире тапшырганда, ул үзенең фотокүчермәсен танымый торды. Миңа шаккатып текәлүе һаман күз алдымда.)

Зәйтүнәнең күмелгән урыны билгесез булуын хәтта башыма да китерми идем. Бу хәлгә бик нык гаҗәпләндем. Күңелемдә Зәйтүнәнең каберен табу дәрте кабынып китте, һич тынычлыкта калдырмады. Аны эзләү максатыннан 2017 елның 28 апрелендә Әхтәмов урамындагы ЗАГСка барып сораштым, хезмәткәр ханым, күпме чиләнеп актарынганнан соң:

– Таптым! – дип сөрән салды. – Дәрвишләр бистәсендә түгел[3], Казанда үлгән. Хәйдәр кызы Зәйтүнә Рәсүлова. 08.06.1957. Туган елы куелмаган. Молотов районы[4], Курск урамы. Ләкин, ни кызганыч, кайда җирләнүе турында мәгълүмат юк, – диде...

Казанда вафат булгач, монда ук җирләнгәндер дә дигән өмет туды җанда. Шәһәр зиратлары буйлап Зәйтүнәнең каберен эзләргә керештем[5]. Яңа бистә зиратыннан башладым. Нәтиҗәсе булмады. Берәр мәгълүматка юлыкмаммы дип, Милли китапханәгә юл тоттым. Газета-журналларны актарырга тотындым. «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 7-12 саннарын тәфсилләп карап чыктым. Берәр кайгынамә бастырылмадымы, мәрхүмәне соңгы юлга озатырга барган язучыларның берәрсе хис-кичерешен кәгазьгә төшермәдеме, кайда җирләнгәнен телгә алмадымы икән дип уйландым. Юк. Зәйтүнә турында бөртек хәтле мәгълүмат та юк иде...

Чү! «Совет Татарстаны» газетасының 11 июнь санында[6]: «Татарстан Язу-

---

[1] Расих А. «Әнием хатирәләреннән» // «Казан утлары». – 1978. – №4. – 147-159 б.
[2] Кутлу Ф. «Зәйтүнә-Тукай мәхәббәте дәвам итә...» // «Казан утлары». – 2016. – №4. – 153 б.
[3] Кайбер язучылар шунда дип фаразлаган иде. – ***Автор.***
[4] Хәзерге Совет районы. – ***Автор.***
[5] Кутлу Ф. «Шагыйрьнең илһамчысы» // «Безнең мирас». – 2017. – №6. – 90-91 б.
[6] Үзем төшергән фоторәсемне тапмагач, Милли китапханә хезмәткәре Фәйрүзә ханым Вәлиевага шалтыраткан идем, кайгынамәнең фотосурәтен тиз арада яңадан төшереп җибәрде. Рәхмәт аңа! – ***Автор.***

чылар союзы правлениесе язучы А.Расих иптәшнең әнисе Зәйтүнә Хәйдәр кызы Мәүлүдованың үлгәнлеген тирән кайгы белән белдерә һәм мәрхүмәнең семьясының кайгысын уртаклаша» – дигән кош теле хәтле хәбәргә тап булдым бит! Сабый баладай сөендем шуңа. Әмма… «Бер уңайдан мәрхүмәнең кайда җирләнүе турында да искәртсәгез, ни була иде инде?» – дип уфтандым да. (Бу хәлдән сабак алып, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм әфәнде Галиуллинга: «Атаклы кешеләрнең вафаты турында журналыгызда мәгълүмат биреп барасыз, шушы игелекле эшегез өчен рәхмәт сезгә! Инде аларның кайда, кайсы зиратта күмелүе турында да өстәп язсагыз, тагын да яхшырак булыр иде», – дидем. Тәкъдимемне хуплап, гамәлгә ашырганы өчен «Казан утлары»на рәхмәт яусын!)


Татарстан Язучылар союзы правлениесе язучы А. Расих иптәшнең әнисе ЗӘЙТҮНӘ ХӘЙДӘР кызы Мәүлүдованың үлгәнлеген тирән кайгы белән белдерә һәм мәрхүмәнең семьясының кайгысын уртаклаша.

Шулай һаман баш ваттым. Атилла Расих 1996 елда вафат булган. Аңарчы бер язучы да Атилла абыйга: «Безне әниең каберенә алып барчы», – дип мөрәҗәгать итмәдеме икәнни? Өлкәнрәк әдипләрдән бу хакта сорашып та карадым. «Уйланылмаган, башка килмәгән», – диделәр. Зәйтүнәгә багышлап күпме әсәрләр, романнар, пьесалар язылган һәм языла тора югыйсә! Ә каберен яд итү дигәндә…

Ул көннәрдә бер дә белмәгән Атилла Расихның хатыны Зәкия Рәсүлеваны (1999 елда вафат) төшемдә күрдем. Имеш, Яңа бистә зиратында очрашканбыз. Мин, кабаланып, каенанасы Зәйтүнә Мәүлүдованың кабере хакында сорашам. «Мин сине шунда алып барып, күрсәтәм хәзер», – диде ул. Шулвакыт уянып киттем.

Башымда әллә нинди уйлар, хыяллар кайный!.. Барлык язучылар белән Яңа бистә зиратын айкап чыгуыбызны күз алдыма китерәм. Зәйтүнәнең каберен табу – без, язучыларның, Тукай алдындагы бурычы лабаса! Шагыйрь алдында оят бит!

Булмады, барып чыкмады. Тапмадым…

Аннан соң дүрт ел чамасы вакыт үтте…

2021 елның 17 февраль кичендә Ркаил абый Зәйдулла, шалтыратып:

– Фатиһ, Зәйтүнә Мәүлүдованың кабере табылырга тора, – дигәч, колакларыма ышанмадым! – Фейсбукта күрдем: Филүсә Арсланова (Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, музыка билгече. – ***Автор.***), опера җырчысы Шәфыйка Котдусованың каберен чистартканда, каралмаган кабергә юлыккан. Шуның Зәйтүнәнеке булуы ихтимал. Мин аңа: «Фатиһ Кутлу белән кызыксына идек, телефон номерыгызны бирмәссезме?» – дип яздым. Ул номерын язып җибәрде. Син бу өлкәдә ни… үткенрәк, үзең шалтыратып белешеп бетер әле?

Вакыт соң иде. Бер дә таныш кеше булмагач, шалтыратуны иртәгәгә калдырдым.

18 февраль көнне иртүк Филүсә ханымның номерын җыйдым. Үзем белән таныштырып, моңа кадәр Зәйтүнәнең каберен янып-көеп эзләп йөрүемне бәян иттем. Филүсә ханым, үз чиратында, болай дип сөйләде:

– Опера җырчысы Шәфыйка Котдусова 1956 елда Мәскәүдә вафат була. Васыяте буенча, җәсәден Казанга алып кайтып җирлиләр. Шәфыйка апаның улы Җәвит Котдусов минем остазым иде. Мин 2018 елда Шәфыйка апаның каберен чистартырга дип барганда, сул яктагы ташландык кабергә игътибар иттем. Таштагы

Зәйтүнә исеменә һәм Тукай шигыренә күзем төште. Бу безгә мәгълүм Зәйтүнәме икән әллә, дип, исем-фамилиясен язып алдым. Кайткач ныклап белешергә тотындым. Чыннан да, кабердә ятучы ханым – Тукайның мәхәббәте Зәйтүнә Мәүлүдова булып чыкты!

Кабаланып:

– Кайсы тирәдә соң ул? – дип сорадым.

– Шиһабетдин Мәрҗани кабереннән ерак түгел, – дип җавап бирде.

– Фотога төшердегезме?

– Узган ел төшергән идем.

– Миңа ул фоторәсемне хәзер үк җибәрә алмассызмы? – дип ялвардым.

– Әлбәттә.

Электрон почтамны ачып карауга, күз алмаларым дымланды. Валлаһи, Зәйтүнә Мәүлүдованың – Тукай илһамчысының кабере бу!.. Бүген изге Рәгаиб кичәсе бит! Догаларым кабул булдымы икәнни? Мең-мең шөкер Сиңа, Раббым!

Кабер ташындагы мәрмәргә Тукайның Зәйтүнәгә атап язылган мәшһүр шигыре уелган иде:

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит – чын җүләр түгел диген!
Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи[7]?
Ул Синең васфеңдә: «Ля шәркыйя, ля гарбия[8]», – ди!
Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла[9] сатып.

Г.ТУКАЙ

Һичшиксез, әлеге шигырьне кабер ташына яздыру фикере Атилла Расихның башына килгәндер. Нинди мәгънәле, нинди соклангыч эш кылган! Урыны оҗмахта булсын!

Ркаил абыйга шалтыратып:

– Әйе, чыннан да, Зәйтүнәнең кабере икән! Фоторәсемен күрдем! – дидем.

Ул да бик сөенде бу хәбәргә.

Хәзер минем көнделдә Зәйтүнәнең каберен үз күзләрем белән күрү, Тукай шигырендә өзек итеп бирелгән «Нур» сүрәсенең 35 нче аятен тулысынча уку теләге уянды.

Сүз уңаеннан, 2017 елгы Рамазан аенда хәтем чыкканда Коръән-Кәримдә әлеге аятькә үзем юлыккач, Тукайның зирәклегенә шаклар каткан идем: «Ля шәркыйя, ля гарбия» сүзләреннән алда анда... «Зәйтүнәтен...» кәлимәсе урнашкан иде! Моны күргәч, «...гә» («Очраган юлда...») шигырендәге нокталар урынына «Зәйтүнә + гә» дип укырга кирәклегенә мең кат ышандым! Димәк, Тукай Коръәннең һәр аятен бик яхшы белгән. Ихтыярсыздан, Тукай Коръәнхафиз да булмадымы икән дип уйлап куйдым. Белмәгән килеш әлеге аятьне һәм анда очраган «Зәйтүнә» сүзен алты мең алты йөз алтмыш алты аять арасыннан эзләп табу, ай-һай, авыр лабаса!

Йөрәгем Зәйтүнәнең каберенә ашкына башлады. Бу хакта Филүсә апага шалтыраттым, ул, бик теләп:

[7] Мәдхияңи – Сине мактау сүзен.
[8] «Ул Синең васфеңдә: «Ля шәркыйя, ля гарбия», – ди! – Ул Сине сыйфатлап: «Көнчыгышта да юк, көнбатышта да юк», – ди. (Коръәндә Аллаһны сыйфатлаганда, «Ул бар, әмма уңда да түгел, сулда да түгел, алда да түгел, артта да түгел, аста да түгел, өстә дә түгел, ләкин бар» дигән мәгънәне аңлатканда китерелә торган сүзләр.)
[9] Кәләмулла – Коръән.

– Ярар, мартта көннәр җылына төшкәч, барырбыз, – диде.

Ниһаять, түземсезлек белән көтеп алган 4 март килеп җитте. Җылы көн. Температура -2° тирәсе. Кар ява. Камера, көрәк-мазар алдым. Алдан сөйләшенгәнчә, сәгать 10.30 тирәсендә Филүсә апа яшәгән йорт янында очраштык. Шуннан бергәләп Яңа бистәгә юнәлдек.

Безнең өчен Шиһабетдин Мәрҗани кабере маяк булачак иде. Филүсә апа бу кабернең 15 нче аллеяда икәнлегенбелешеп куйган иде инде. Мәрҗани хәзрәтләренең каберен эзләп йөргәндә барган юлыбыз Тукай хозурына алып чыкмасынмы!

– Сөбханалла! – дидем мин, шаккатып. – Зәйтүнәгә Тукай аша барабыз!

Төп капкадан Тукайга килеп җиткәч, юл сул якка юнәлә. Шуннан күпмедер барганнан соң уң якка да юл кереп китә. Шунда ук тимер ук белән «15» саны язып куелган. Соңыннан адымлап махсус санап чыктым: әлеге «15» дип язылган урыннан Мәрҗани каберенә кадәр 22 адым. Мәрҗанидән соң 16 адым атлагач, сулга тар гына сукмак кереп китә. Шул сукмак башында маяк булып атаклы галим Гыйлем Камайның кара төстәге гаҗәеп зур кабер ташы тора. Шул кабер артында чардуган белән уратылган ике кабер бар, аларны үтеп, 11 адым атлагач... «Мәүлүдова Зәйтүнә Хәйдәр кызы».

Күңелләрем тулды, шатлыгымнан нишләргә белмәдем. Мәрхүмәнең кабере алдында торам, аны үз күзләрем белән күрәм бит! Өнме бу?! Йа Раббым, морадыма ирештердең, мең-мең шөкер Сиңа! Кар диме, салкын диме, мине, нибары телефон аша таныш кешесен, шушы изге урынга алып килгән хөрмәтле Филүсә апага да рәхмәт яусын! Аның ярдәме белән Зәйтүнәнең еллар буе каралмаган, йөрелмәгән ятим кабере, ниһаять, ятимлектән котылачак! Саннарга да игътибар итегез әле: Зәйтүнә Мәүлүдова (1893-1957). 64 яшьтә вафат булып, кабере янә 64 ел узгач (1957-2021) табылды.

Кулларымны күтәреп, «Фатиха», «Ихлас» сүрәләрен һәм... «Нур» сүрәсенең 35 нче аятен тулысынча укып, Зәйтүнә Мәүлүдованың рухына багышладым.

Әйе, алты ел элек әйткән һәм шушы мәкаләм башында телгә алынган: *«Ихтыярсыздан, мәрхүмәнең каберенә барып, рухына дога кылу теләге туды...»* – дигәннәрем тормышка ашты.

Йа Раббым! Син чиксез көч-кодрәт иясе!.. Моңа тагын бер кат ышанып, Синең алдыңда сәҗдә кылам. ■

безнең мирас №4 апрель 2021

«Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы...»

Гүзәлия Хаҗиева, филология фәннәре докторы

Татар культурасында им-том, теләк теләү текстларында төрле чир-сырхаулардан дәвалауны, бала тудыруда ярдәм итүне сорап теләк теләгәндә Гайшә-Фатыйма исеме киң кулланыла. Халык имтомнарында әлеге образ ислам мәдәниятында киң таралган Гайшә һәм Фатыйма исемнәренә барып тоташа. Ислам тарихында танылган Гайшә – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) хатыны, ислам теологиясендә «дин тотучыларның анасы» дигән мактаулы титул белән дан тоткан. Ул – пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрен ышанычлы тапшыручыларның берсе. Фатыйма – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) кызы, Али әбу Талибның хатыны, Хәсән һәм Хөсәеннең әнисе, мөселман дөньясында иң хөрмәтле хатын-кызларның берсе. Гайшә исеме гарәп телендә «тере» дигәнне аңлата, Фатыйма исеме гарәп теленнән «күкрәктән аерылган кыз, яшүсмер» дигән мәгънәне бирә. Билгеле булганча, әйләнә-тирә дөньяга йогынты ясау, теләгән күренешне чакыру, дини образларга мөрәҗәгать итеп төрле хәрәкәтләр башкару им-том текстларының төп максаты булып тора. Татар диалектларында Әйшә-Гайшә исеменнән ясалган «әйшәләү» фигыле «нинди дә булса им-том ясау» дигәнне аңлата.

Гайшә-Фатыйма образының хатын-кызларның яклаучысы булган борынгы төрки традициядә билгеле Умай образы белән параллельлеге күренә. Ислам динен кабул иткәч, Гайшә-Фатыйма образы халык арасында киң тарала башлый.

Төрки мәдәниятләрдәге Гайшә-Фатыйма образында исә Умай вазыйфаларына якынлык сизелә. Билгеле булганча, Умай борынгы төркиләрнең хатын-кызларны һәм балаларны саклаучы һәм яклаучы хатын-кыз алиһәсе буларак билгеләнә. Ул – борынгы төрки мифологиядә җирнең уңдырышлылыгын гәүдәләндерүче образ. Умай яңа туган баланы бу дөньяга кабул итә, балаларны һәм сугышчыларны яклый, тормыш көчен чагылдыра. Ислам дине кабул ителгәч, Умай исеме әкренләп онытыла башлый. Халык традицияләрендә мөселман изге хатын-кызларының вазыйфаларын чагылдырган Гайшә-Фатыйма исеме киң таралыш таба: *«Им булсын, минем кулым түгел, Әйшә-Фатыйма куллары, дип, такмаклап-такмаклап сабам баланы мунсада. Тәуфиклы бала картнәсен дә, картатасын да тыңлаучан була. Минем кулым түгел, Әйшә-Фатыйма кулы».*

Им-том текстларында «Әйшә-Фатыйма кулы», «Аша-Батман кулы» гыйбарәләре киң таралган:

«Минем кулым түгел,
Әйшә-Батыйма кулы,
Йакшыларның кулы.
Минем кулым түгел,
Фатыйма белән Гайшәнең кул-айагы.
Йабышкан кулымның сихәте килеп,
Изгеләрнең, әүлийәләрнең хәер-догаларында,
Өшкергән тынымның шифасы тисен,
Бу бала сихәтләнсен».

Халык медицинасында Гайшә-Фатыйма еш телгә алына. Сибелеп яшәгән татарларның җирле сөйләшләрендә, авыруларга каршы им-том ясаганда, бу исемгә мөрәҗәгать итәләр. Күз авыруларын дәвалау барышында, Гайшә-Фатыйма исеме магик көчләргә йогынты ясау чарасы буларак хезмәт итә. Казан арты татарлары, күзгә арпа чыккач, арпа бөртекләрен алып, Гайшә-Фатыйма исемен им-том сүзләрендә кулланалар. Им-том сүзләре әйтелгәч, әлеге арпа орлыгын этләргә ташлыйлар. Халык медицинасында күз чирләрен дәвалаганда, халык мондый им-том сүзләрен файдалана:

«Ак күз, кара күз,
Белгән күз, белмәгән күз,
Зәңгәр күз, коныр күз, усал күз
Чыксын да китсен,
Бала өстендә тормасын.
Мин эшкермим,
Аша-Батман карчыгы килгән,
Шул эшкерә, шул чыга».

Халык арасында очан авыруын дәвалаганда Гайшә-Фатыйма исеме белән им-том йоласы үткәрелә:

«– Нәрсә булган? – Очан булган,
– Нәрсә имнисең? – Очан имним.
Җиде – җилгә кузгалсын,
Биш – бизеп китсен,

Өч – очып китсен,
Бер – берлексез булсын,
Минем кулым түгел,
Гайшә-Батман кулы,
Бетсен- китсен, –
дип имнисен, тфү-тфү, дип».

Кызыл тимгелләрне дәвалаганда да Гайшә-Фатыйма исеме кулланыла. Самара өлкәсе татарлары биттәге бетчәләрне дәвалау вакытында, кызыл сөлге белән каплап, мондый им-том сүзләрен кулланалар:

«– Нәстә имлисең?
– Менә канчау канчаулыйм,
Кайан килдең – шунда кит,
Бүре күзенә бассаң – бүрегә кит,
Кочок эзенә бассаң – кочокка кит,
Сихергә эләксәң – сихерчегә кит,
Бозыкка эләксәң – бозучыга кит,
Кем бозган – шуңа китсен.
Минем кулым түгел,
Әйшә-Фатыйма кулы».

Төрки культурада Гайшә-Фатыйма культы бик киң таралган. Сабыйга бәхет, сәламәтлек, озын гомер теләп, аны начар көчләрдән саклау максатыннан, изге хатын-кызлар Гайшә-Фатыйманың исемнәре файдаланыла.

Төрки үзбәк культурасында да, балага бәхет теләгәндә, Гайшә-Фатыйма исеме телгә алына: «Менинг қўлим эмас, Биби Фотиманинг қўли, Әнвәр Онамнинг қўли, етти Момонинг қўли» («бу минем кулым түгел, ул биби Фатыйма, Әнбәр ул, җиде Момо») дигән сүзләр белән мөрәҗәгать итәләр.

Татарлар өй хуҗалыгында ярдәм сораганда да Гайшә-Фатыйма образына мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, себер татарлары җиләк-җимеш һәм гөмбә җыйганда.

Башкорт мифологиясендә Ғәйшә-Батима, Әйшә-Батман образы авыру балаларның, хатын-кызларның яклаучысы булып санала. Ғәйшә-Фатыйма ҡулы, Ғәйшә-Фатыйма теле, Ғайшә-Фатыйма сөйләме кебек гыйбарәләр башкорт магик йолаларында, им-томнарында, теләкләрдә очрый.

Азәрбайҗан культурасында Фатыйма куллары термины киң таралган. Бала туу, кендек кисү йолаларында Гайшә образы түгел, Фатыйма кулы искә алына: «Минем кулым түгел, Фатыйма кулы».

Шулай итеп, татар һәм башка төрки халыкларның традицияләрендә Гайшә-Фатыйма образының берничә вазыйфасын билгели алабыз. Беренчедән, Гайшә-Фатыйма образы – барлык хатын-кызларның яклаучысы; икенчедән, изгеләр вазыйфасын башкарып, ул кеше белән Аллаһы Тәгалә арасында арадашчы функцияләрен үти. Өченчедән, берәр авырудан, бозымнан, күз тиюдән коткара һәм төрле чирләрне дәвалауда катнаша; дүртенчедән, Гайшә-Фатыйма кешеләрнең нәсел-нәсәбен яман чирләрдән һәм бәхетсезлекләрдән саклау һәм яклау вазыйфасын башкара, исемен телгә алган сораучыларга бәхет һәм уңыш китерә. Моннан тыш, татарлар бу образга яхшы уңыш алу, өйдә иминлек саклау, сәламәтлек сорау өчен дә мөрәҗәгать иткәннәр. ■

Тукай Әстерханда[1]



Г.Тукай. Әстерхан, 1911 ел

Габдулла Тукай 1911 елда дусларына язган хатларда Әстерханга барырга, кыргыз[2] кымызыннан авыз итәргә, дәваланырга ният итүе, форсат туса, Истанбулны да күрергә теләве турында бәян кыла.

Ниһаять, апрель азагында ул «Самолет» ширкәтенең «Тургенев» пароходына утырып, сәфәргә кузгала. *«Урыным 3 нче класста иде. Парахуд эчендә кеше күп булса да, миңа ярарлык, сөйләшеп утырырлык берәү дә күренми иде. Эчем пошкач, «приличия»-фәлән рамкасына кысылмаган, прастуй 4 нче класс халкы арасына чыга идем. Вакыйган, анда чыгу бушка китмичә, бер хили заман карап торырлык күренешләр булгалый иде»,* – дип яза ул бу турыда.

Суны тәгәрмәче белән сосып, пароход Идел буйлап аска төшә. Сембер, Самара, Сарытау артта кала. Озын-озын гудоклар биреп, «Тургенев» Сарычин белән саубуллаша. Һәм ары бара, ары бара…

Озакламый ап-ак Әстерхан кирмәне күренә. Ярлар тулы сарайлар, келәтләр, балык үрчетү бүлемнәре… Пароход, көчле тавыш биреп, шәһәрне сәламли. Пристаньга җитүгә, тәгәрмәч, кире якка әйләнергә тотынып, тизлеген киметә. «Тургенев», шыгырдап, дебаркадерга терәлә. Трап сузыла, гавам агымына буйсынып,

[1] Язма Әстерхан дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы һәм шәхси тупланма материаллары нигезендә әзерләнде. – ***Автор искәрмәсе.***

[2] Казакъ халкының ул вакыттагы атамасы. – ***Автор искәрмәсе.***

Тукай ярга төшә. Аны каршы алучы күренми. Шагыйрьнең монда киләсен белмиләр дә – тыйнакланып, ул һичкемгә телеграмма сукмаган була.

1911 елның 29 апрелендә «Идел» газетасы «күренекле шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаевның» Әстерханга аяк басуы турында хәбәр бирә.

Бер атнадан Тукай Казанга хат юллый: *«Мин <...> Әстерханда. <...> Тагын бер ай кадәре торырга карар бирдем. Киләсе хатымда рәсемнәр өчен темалар вә, булдырып булса, мәкалә вә шигырьләр дә җибәрсәм кирәк. Әле хәзер кунакка йөрүдән бушаганым юк. <...> Кымыз эчәм. Ит ашыйм, һава яхшы. Хәзердән үк үземдә җисмән вә рухан бер көч хис итә башладым. Квартирым да начава. Сәгыйть белән бергә торабыз».*

Сәгыйть Рәмиев ул чакта «Идел» газетасында сәркатип вазыйфасын башкара. Редакция исә Әстерханның татарлар иң күп яшәгән Тияк бистәсендә, ике катлы агач йортның аскы катында урнашкан була.

«Әле Тукай килгәнче үк, Шәһит Гайфи татар әдәбиятына, театрына һәм аларны пропагандалауга багышланган открыткалар сериясен булдырырга уйлый. Сюжетлар эзли, грим сылый. Иван Бочкарев исә аны фотосурәткә күчерә. Әдәби каһарманнар сурәтләнгән бу рәсемнәрне Иван Митрофанович Берлин нәшриятларының берсенә җибәрә, алар анда төсле яисә аклы-каралы итеп бастырыла.

Бу елларда Әстерхан шәһәре татар дөньясы мәркәзләреннән берсе санала. Җирле хәйрия җәмгыятьләре мәктәп-мәдрәсәләргә бихисап ярдәм күрсәтә, бистәләрдәге һәм якын-тирә авыллардагы укытучыларга хезмәт хакы түләп тора, гомумән, һәрьяклап татар җәмәгатьчелегенең милли-мәдәни тормышын кайгырта. Бу тормышны җанландырып җибәрергә теләүчеләр арасында, шагыйрь Сәгыйть Рәмиев һәм актер Зәйни Солтановтан кала, бик күп газета-матбага әһелләре, мөгаллимнәр, дин эшлекләре һәм эшмәкәрләр була.

Өч атнадан соң Тукай Рәмиевтән Калмык Базары авылында укытучылык иткән Шәһит Гайфигә күченә, «хуҗа» белән бергә мәктәпнең бер бүлмәсенә урнашып, шунда яши башлый, ял итә. Укыйсы килсә – укый, йоклыйсы килсә – йоклый. Болардан туйган арада шәһәргә чыга, Әстерханның көмешләнгән тупыллары күләгәсендә хәл җыя, пароходларның, баржаларның, каекларның тыныч сәфәрен күзәтә...

Шат күңелле, җор телле «хуҗа» кешене Тукай тиз арада үз итеп өлгерә. Өстәвенә, Гайфи сәхнәдә дә уйный икән, фоторәсем төшерү белән мавыга, карикатураларны оста итеп ясый белә. Әстерханның күренекле фотографы һәм популяр открыткалар авторы Иван Бочкарев белән дуслыгы гына да ни тора!

Әле Тукай килгәнче үк, Шәһит Гайфи татар әдәбиятына, театрына һәм аларны пропагандалауга багышланган открыткалар сериясен булдырырга уйлый. Сюжетлар эзли, грим сылый. Иван Бочкарев исә аны фотосурәткә күчерә. Әдәби каһарманнар сурәтләнгән бу рәсемнәрне Иван Митрофанович Берлин нәшриятларының берсенә җибәрә, алар анда төсле яисә аклы-каралы итеп бастырыла.

Шагыйрь Әстерханга килүгә үк, Гайфи Тукайның берәр шигыре эчтәлегеннән ачуга багышланган открытка чыгару хәстәренә керешә. «Бер шәехнең мөнәҗәте» дигән шигырьне сайлыйлар. Сатирик әсәр герое «к» хәрефенә башланган биш әйбергә мөкиббән, имеш. Болар: казылык, кузый (бәрән), каз, кымыз һәм кыз. Шәех бөтен дин әһелләре исеменнән, шул биш рәхәттән мәхрүм итмәвен сорап, Ходай Тәгаләгә ялвара, дога кыла.

Ак сакал ябыштырып, Шәһит үзе шәех булып киенә. «Кыз» булып бизәнгән яшь хатыны (төрекмән кызы Нурбибә) келәмгә, кулларын күккә сузып дога укый торган ире янына утыра. Алларында – казылык, кымыз, кыздырылган каз һәм кузый ите. Боларын исә Туликов исемле бай табып бирә.

Гайфиләрдә ун көн ял иткәннән соң, Тукай Рәмиев янына кайта, алдынгы карашлы яшьләр мохитенә эләгә. Аңа каланың тарихи урыннарын күрсәтеп йөриләр. Тукай хөрмәтенә җиләк-җимеш бакчаларында, балыкчылар ыстанында мәҗлесләр корыла. Шагыйрь театр труппасы тамашасын карый, әдәби-музыкаль һәм бию кичәләрендә катнаша.

Ләкин рәхәт көннәр тиз уза, китәр вакыт җитә. Хушлашыр алдыннан, дусларның фотосурәткә төшәселәре килә. Тукай рәсемгә төшәргә яратмый. Алай да... Күрәсең, аны Шәһит Гайфи үгетли алгандыр. Менә алар бутафор көймәдә утыралар: Шәһит Гайфи – ишкәкче, уртада – Сәгыйть Рәмиев, сулда – Габдулла Тукай. Икенче фотосурәттә – юан Солтанов белән мәһабәт Рәмиев, алар арасына кысылып утырганы – Тукай. Ул әтисенең фуражкасын кигән малай сыман гына.

Тукай Әстерханнан июнь аенда, каладан да, аңа кадер-хөрмәт күрсәтергә омтылган шәһәр халкыннан да бик риза-бәхил булып кайтып китә. Кунакта рәхәт, әмма өйдә аннан да рәхәтрәк, диләр. Озак кунак булу да туйдыра. Шагыйрь Казанын, Печән базары каршындагы «Болгар» кунакханәсенең нәни бүлмәсен сагынып кайта. Ирекле тормыш, саф һава, дала кымызы шагыйрьгә көч-куәт, күңел күтәренкелеге, иҗат рухы өсти...

Истанбул исә аның мәңге чынга ашмас хыялы булып калачак.

Ләкин ел ярым калган гомерендә ул Уфа белән Санкт-Петербургны күрергә өлгерәчәк әле...

***Абдулла Дубин**, хаҗи, филокартист һәм төбәкне өйрәнүче* ■

Тукай «Идел» газеты редакциясендә

Габдерәхим Утабалиев

Әстерханга Г.Тукай килү уңае белән 1911 елның җәендә төшерелгән фоторәсем. Урта рәттә сулдан: артист Зәйни Солтанов, Габдулла Тукай, шагыйрь Сәгыйть Рәмиев.

«Идел» газеты редакциясе һәм матбагасы шәһәрнең эшчеләр бистәсе Тияктә, хәзерге Воронеж урамында, ике катлы агач йортның астагы этажында урнашкан, өстә приходская школа иде. Без аны Хәбибулла Насыйбуллин мәктәбе дип йөртә идек.

Мин матбагада газетның беренче номеры чыккан көннән – 1906 елның май аеннан – өйрәнчек, аннан хәреф җыючы булып эшләдем.

1911 елның апреле, матур бер көн иде. Хәреф җыю бүлмәсендә Сәгыйть Рәмиев тә эшләп утыра. Ул «Идел»дә редакция секретаре булып эшләргә 1910 елда килде. Кәефе яхшы чакта авыз эченнән «Ашказар»ны көйли иде. Бу көнне дә ул «Ашказар»ны җырлап утыра иде. Мин тәрәзә янында басып, газетның чираттагы номерын җыям. Кинәт күземә редакциягә килүче бер кеше чагылып китте. Аңа җентекләп карадым: башына иске картуз, өстенә озын җөббәсыман пальто, аяк асты коры булса да, ботинка белән галош кигән, ябык һәм сары йөзле. Мин аны капкадан кереп киткәнче күзәттем дә:

– Сәгыйть әфәнде, безгә бер авыру рус малае килә, – дидем.

Рәмиев миңа җавап кайтарырга өлгермәде, әлеге «малай» ишектән килеп тә керде. Сәгыйть, аны күргә урыныннан торып, каршы барып:

– Әй, Тукайҗан! – дип, ишектән керүчене кочаклады.

Габдулла Тукай белән мин шулай таныштым. Әстерханда чакта Тукай редакциягә көн дә диярлек килә иде.

Озакламый аның белән дуслаштык. Сәгыйтьнең эше тыгыз вакытта Тукай минем белән сөйләшеп утыра, үзенең Уральскида матбагада эшләгәнен хәтерли иде. Ә кайчакларда кәгазь келәтенә кереп, кәгазьләр өстенә ятып ял итә, хәтта йоклый да иде. Башта моңа безнең исебез китте, без аңардан, икенче катка менеп, безнең торактагы йомшак урынга ятуын үтендек. Ләкин Тукай, баш тартып:

– Рәхим, миңа монда да «Люкс» номерыннан ким түгел, чебен дә тешләми, – дип җавап бирде (Әстерханга килгәч, ул шул исемдәге кунакханәгә төшкән иде).

Тукай тагын бер исне китәрде. Без бер тапкыр Татар базарына барып чыктык. Яшелчәләр яңа чыгып килә торган вакыт иде. Яшелчәләргә аның исе китмәде, бәлки, Сәгыйть белән мине карусель янына тартып алып китте. Үзе карусельгә менеп, агач атка атланып әйләнә башлады. Ул шулкадәр хозурланып балаларча әйләнде ки, аңа минем генә түгел, кәмит караучы башка кешеләрнең дә исе китте. Ул бер генә әйләнеп канәгатьләнмәде, тагын һәм тагын әйләнде. ■

Фатыйма ханым

Гөлмару Мырзагалиева[1]

Җиһангир хан белән Фатыйма

Казакъ тарихында үзенең акыл-гыйлеме, зыялылыгы белән киң җәмәгатьчелеккә танылган хатын-кызлар шактый. Бүкәй Урдасыннан Җиһангир ханның әнисе Атан ханымны һәм хатыны Фатыйманы аеруча искә алырга мөмкин. Атан ханымның исеме еш кына ире Бүкәй хан вафат булганда һәм улы Җиһангирның хан тәхетенә утыруына бәйле документларда чагылыш таба. Ә менә Фатыйманың белемле һәм тәрбияле булуы хакында Хан Урдасында гына түгел, Мәскәү, Оренбург, Казан һәм Әстерхан калаларында да еш искә ала торган булганнар.

Мөфти кызы Фатыйма

Әлеге зыялылык һәм белемнең тамыры кайда соң? Фатыйма – мәгърифәтле татар милләтеннән, Оренбург мөфтие Мөхәммәджан Хөсәеневнең кызы. Мөхәммәджан 1785 елда Оренбург чик буе комиссиясе ахуны итеп тәгаенләнә, 1789 елда ул Екатерина II (татарлар аны Әби патша диләр) фәрманы белән Россия мөфтие вазыйфасына керешә. 35 ел

[1] Гөлмару Мырзагалиева – Көнбатыш Казакъстан өлкәсенең Хан Урдасы тарихи-мәдәни архитектура-этнография музееның фәнни хезмәткәре.

эшләү чорында Мәскәүдән алып Тубылга кадәрге мөселман шәһәрләренең үзәкләрендә дистәләгән мәчет һәм мәдрәсә төзелә.

Атаклы татар галиме Ризаэддин Фәхреддиннең язуынча, Фатыйманың әнисе Кәримә Мөхәммәдҗан мөфтинең икенче хатыны була. Аның туган җире – Кара диңгез буендагы Анапа шәһәре. Мөфти вафат булганнан соң, ул, кызы Фатыйма янына китеп, Җиһангир хан тәрбиясендә дөнья кичереп вафат була.

Хан Урдасы тарихи-мәдәни архитектура-этнография музеенда Фатыйма ханым бүлмәсе

Никахлашу тарихы

Уфада яшәүче Фатыйма белән Бүкәй илендәге Җиһангир ничек танышкан соң? Хан, тәхеткә утыргач, татар муллалары йогынтысында казакъ халкында ислам динен ныгыта, милләттәшләрен намаз укырга өйрәтә, мәчет төзетә. Бер үк вакытта Уфа, Оренбург кебек мөселман руханилары күпләп яшәгән шәһәрләргә сәяхәт итә. Шундый сәфәрләрнең берсендә Җиһангир хан яшь һәм сылу Фатыйма туташ белән таныша.

Фатыйма, дини гаиләдә үссә дә, дөньяви белемне дә үзләштерә: хатын-кызлар гимназиясендә рус телен өйрәнә, Европа кызлары дәрәҗәсендә тәрбияләнә, милли рухны, туган телне дә саклый. 1824 елда Җиһангир белән Фатыйма гаилә кора. 1827 елда гаилә башлыгы аның өчен затлы сарай салдыра башлый, ә бер ел узуга, гаилә зур террасалы йортка күченә. Биредә аларның 10 баласы дөньяга килә.

Р.Фәхреддин: «Җиһангир ханның танылуы шушы хатынның уйлап эшләве белән бәйле булган»

Фатыйманың укымышлылыгы, берничә телне белүе, кунакчыллыгы турында Россия түрәләренең һәм галим-тикшеренүчеләрнең искиткеч матур фикерләре, истәлекләре бар. Ризаэддин Фәхреддин: *«Мөфти хәзрәтенең дөрес бәхетле вә үзенең дә хәер илә исеме хәтердә калуына сәбәпче баласы шушы Фатыйма булган, диләр. Чөнки, барлык туганнарыннан аермалы буларак, гаять диндар, тәкъва, инсафлы, гакыллы, уйлап эш итүчән бер хатын булып, ханның мәхәббәтен җәлеп иткән вә ханның үзен тәрбия иткән кебек, бөтен Бүкәй иленә мәдәният керүенә сәбәп булган. Казакъ гаиләләренә шәхсән үзе гореф-гадәтләренең гүзәл булганнарын өйрәткән, әисламга туры килмәгәннәрен кире каккан, тәһарәт вә пакьлеккә аеруча зур игътибар биргән. Хан хатыны булып барганнан соң, Бүкәй иле белән Оренбург, Уфа вилайәтләре арасында килеп-китеп йөрү халык арасында таралу белән арада бөек бер дуслык вә танышлык пәйда булган. Казакъларның дәүләтлеләренең угылларын – үз байлыкларыннан, мохтаҗ вә фәкыйрьләрнең балаларын үз кесәсеннән чыгым тотып, Эстәрлетамак вә Эстәрлебаштагы мөселман мәдрәсәләренә җибәреп укытканнар. Бүкәй илендә бу көндә булган могтабәр галимнәр һәм танылган мөдәррисләр әлеге ике мәдрәсәнең вә аларны тәрбияләгән шәехләрнең тәрбия җимешләреннән. Җиһангир ханның мәсҗид салдырып һәртөрле ыруг вә кабиләләргә имамнар билгеләве, вә аларга рәсми сурәттә хокук кәгазе биреп, мәхәллә балаларын укыту вә сабыйларга борынгылардан калган исем*

бирү нәтиҗәсендә танылуы шушы хатынның уйлап эшләве белән булган», – дип яза.

Фатыйманың императорга җавабы

И.С.Иванов *«Джангир, хан Внутренней Киргизской орды»* исемле хезмәтендә Фатыйма турында: *«Это была девушка образованная, знавшая иностранные языки, музыку и танцы»,* – дип яза. Ә менә Илья Казанцевның «Описание киргиз-кайсак» исемле әсәрендә: *«Фатима – женщина образованная, хорошего общения, знала все приличия общежития. Она с супругом своим в 1826 году находилась в Москве при торжестве коронования их Императорских величеств, от Высочайших щедрот удостоена драгоценными подарками. При торжественном бале во дворце участвовала в танцах и на удостоенный Государем вопрос: «Не лучше ли для нее быть в Москве, нежели в степи?» – ответствовала: «Государь, здесь все хорошо и превосходно; но для всякого, где кто родится, там жить, кажется, еще всего лучше»,* – дигән мәгълүматлар китерелә.

Фатыйманың кунакчыллыгы һәм кайгыртучанлыгы турында 1844 елда хан ставкасында булган барон Бюлер көндәлегендә дә язылган. *«Однако ханша Фатима, несмотря на грустное расположение духа, сумела оказать нам внимание, еще не видав нас. Она прислала к нам на дорогу две бархатные шапки с меховой опушкой – одна из этих шапок татарская, обшитая позументом, другая киргизская тюбетейка, т.е. остроконечная шапка, вышитая золотом, такая, какие носит хан и султаны. 26 ноября, в воскресенье, хан представил нас первой своей супруге. Она очень хороша, хотя набелена и нарумянена. Ей эти искусственные прикрасы не нужны, но таков обычай. Костюм ее чрезвычайно богат и сложен. Он не есть чисто киргизский или татарский, а смесь азиатских одеяний. Жемчуга и бриллианты на голове, на шее, на вуалях и платье. Ханша говорит по-русски, понимает французский и немецкий языки. Она воспитывалась в пансионе в Оренбурге»,* – диелә анда.

Ханбикә Казанда

Җиһангир Мәскәүдән кайтканда Казанда туктала, университет галимнәре, татар руханилары белән очраша. Хан аларга Бүкәй Урдасында гыйлем учагы ачарга, казакъ балаларын югары уку йортларында укытырга теләве турында сөйли. Бу сәфәрендә ул Казан университеты профессоры һәм ректоры Карл Фукс, көнчыгыш телләре белгече Казимбәк белән таныша. Соңрак хан алар белән гомере азагына кадәр дусларча аралаша. 1844 елда Казан университетында Жиһангирның «Мохтәсәрел викаять» исемле хезмәте басыла. Шул ук елда ул университетның «шәрәфле әгъзасы» итеп тә сайлана.

Җиһангир ханның Казанга сәяхәте турында галим Карл Фукснын «Пребывание в Казани киргизского хана Джеан-Гиря» исемле мәкаләсе «Казанский вестник» газетасында басылып чыга. Анда галим Фатыйма турында менәниләр яза: *«Жена моя посетила супругу хана и была ею принята очень учтиво и ласково. Ханша поздоровалась нею по Европейскому обыкновению, посадила ее на диван и очень охотно с нею разговаривала. Она говорит довольно по-русски, и произношение ее так хорошо, что трудно заметить, что она не русская. Лицо у нее азиатское, но чрезвычайно милое и приятное, наряд ее придавал ей особенную прелесть в нем, богатство соединялось со вкусом. На ней была белая, атласная рубашка, обшитая внизу золотою бахромою, в четверть ширины и подпоясанная широким золотым поясом. Сверху было надето малиновое бархатное платье, в турецком вкусе, обшитое золотым позументом и узкою*

бахромою. Шея ее украшалась ожерельем, в вершок шириною, снизанным из крупного жемчуга и бриллиантов, которое застегивалось богатым фермуаром. На голове ее была шапка в венгерском вкусе, украшенная жемчугом и бриллиантами и большою жемчужною кистью, которая склонялась к правой стороне. Ханше только 17 лет, но она уже 3 года замужем, ее зовут Фатимой».

Фатыйма чит җирләргә барганда Европа стилендә киенгән, ә үз өендә татар һәм казакъ хатын-кызларына хас булган милли киемдә йөргән. Затлы зәркән һәм башка бизәнү әйберләре аның болай да табигатьтән матур булган буй-сынын, нурлы йөзен бизәгән. 1829 елда патшабикә Александра Федоровна ханбикә Фатыймага алтын склаваж, тарак һәм алкалар бүләк итә.

Хан балалары

Җиһангирның дүрт хатыны булган. Өлкән хатыны Казимә турында мәгълүмат юк. Икенче хатыны Йөзем исемле. Ул – шәркеш ыруыннан чыккан Әсиреп Айдаболовның кызы. Өченче хатыны – Фатыйма. Дүртенче хатыны – Салих, Бүкәй Урдасы старшинасы, сәүдәгәр Карауыл-хуҗа Бабаҗановның кызы.

Архив документларыннан ханның Сәхибгәрәй, Ибраһим, Әхмәдгәрәй һәм Гобәйдулла исемле улларының, Зәһрә, Зөләйха, Гайшә һәм Хәдичә исемле кызларының Фатыймадан туган икәнлеген беләбез. Моннан тыш, Җиһангирның башка хатыннардан Зөлкарнәй, Искәндәр, Сәедгәрәй, Исмәгыйль исемле ир балалары булган.

Фатыймадан туган балалары турында Ризаэддин Фәхреддин менә ниләр яза: *«Сәхибгәрәй 1263/1847 елның 25 июнендә (рәҗәб аенда) хан исеме алып, ике елдан соң, 1265/1849 елда вафат булды. Минемчә, өйләнмәгән иде, балалары да юк.*

Ибраһим 1269/1853 ел сәфәрендә, февраль аенда, хан исемен алып, Оренбург шәһәрендә торды, яшьлегендә вафат булды. Кабере Оренбургта, балалары юк иде.

Әхмәд Петербургта Пажеский корпуста укып, хезмәткә керде вә гвардейский полковник дәрәҗәсендә хезмәттән чыкты. Туган елы – 1834. 1287/1870 елның 30 августында (рәҗәб) Русия дәүләте тарафыннан «князь Чингиз» дип дәрәҗә вә моның өчен өч ел соңрак герб бирелде. Дәүләт иганәсе белән энесе Гобәйдулла белән берлектә, Хиҗазга барып, хаҗ сәфәрендә дә йөреп килделәр. Әүвәлге хатыны – полковник Пәйдәсов исемле кемсәнең Зөһрә бинте Шаһингәрәй бине Йосыф әт-Тәукили исемле хатыныннан булган кызы Хәдичә. Моның вафатыннан соң мирза Баһадиргәрәй бине Шаһингәрәй бине Йосыф әт-Тәукили кызы Зөһрәгә өйләнде (моның анасы Гөлсембикә бинте Сөләйман – Дәүләткилди фамилиясенә карый иде). Әхмәднең исә әүвәлге хатыныннан князь Исмәгыйль исемле улы булып, бүген гаиләсе һәм балалары бар, диләр.

Гобәйдулла дәүләт хезмәтендә булып, генерал дәрәҗәсенә иреште, бүген исә Петербургта сәламәт вә хезмәтеннән чыккан. Балалары юк, диләр.

Хәдичә Сәедгәрәй мирза бине Шаһингәрәй бине Йосыф әт-Тәукили никахында вафат булды. Өммегөлсем, Мәдинә исемле кызлары бар һәм һәр икесенең балалары күп.

Зөләйха казакъ түрәләреннән Сәедсолтан бине Җантуар исемле майорда кияүдә булып вафат булды. Аның Сәлимгәрәй исемле улы бүген сәламәт, гаиләсе, балалары бар.

Моннан аңлашылганча, Җиһангир хан хәзрәтләренең нәселе Әхмәд исемле улы белән Хәдичә һәм Зөләйха исемле кызларыннан таралган»[2].

[2] Бу юллар Р.Фәхреддиннең «Асар» китабыннан алынды. Аны басмага әзерләгәннәре һәм нәшер иткәннәре өчен милләтпәрвәр татар галимнәре Раиф Мәрдановка һәм Рамил Миңнуллинга зур рәхмәтебезне белдерәбез.

*(**Редакциядән:** Р.Фәхреддин: «Кайбер хата вә ялгышлыклар булса, белгәннәр төзәтерләр», – дип яза.)*

Хан Урдасындагы хан каберлеген өйрәнү барышында без аның сабый вакытта вафат булган, тарихи документларда исемнәре очрамаган балаларының каберләрен дә таптык. Шуларның берсе – Ханзадә. Сабый 1829 елда ике яшендә вафат була. Безнең фикеребезчә, ул Җиһангир белән Фатыйманың беренче газиз баласы.

Җиһангир 1842 елның маенда Оренбург чик буе комиссиясе рәисе Г.Ф.Генскега җибәргән хатында: *«Милостивый государь Григорий Федорович! По постоянному обязательному расположению вашего превосходительства я счел необходимым уведомить вас о супружеских союзах в моем семействе. Сын мой Сахиб-Гирей по закону нашему должен был взять в замужество дочь султана Чингали Урманова, так как она была двукратно помолвлена за старших моих сыновей, и дочь моя Зюрекею помолвил за единственного сына султана Чингали, молодого Джиганшаха, которому поручил управление танинского рода, так как этот молодой человек похвальными качествами своими приобрел особую мою любовь и подает прекрасные надежды»,* – дип бәян итә. Бу хаттан аңлашылганча, солтан кызы Җиһангирның Зөлкарнәй, соңрак Искәндәр исемле уллары белән ярәшкән була, әмма аларның икесе дә яшьли үлә. Язмыш аны, хатта язганча, Сәхибгәрәй белән түгел, Йөземнән туган Сәедгәрәй белән кавыштыра. Сәедгәрәй һәм Әрмәкҗаннан танылган казакъ акыннары Шәңгәрәй һәм Мөхәммәдгәрәй дөньяга килә. Сәедгәрәй үзе бернинди дан-дәрәҗәгә дә омтылмый, Бөкәй-Урдасында яши бирә.

Фатыйма ханым Е.Мерлинга язган хатында улы Сәхибгәрәйнең укудагы казанышлары турында бик шатланып яза һәм: *«Зюрекея (Зөһрә) моя благодарит вас за участие в ее судьбе, она*

Зөләйха кызы Гөлсем белән

действительно помолвлена за сына бывшего ханом зауральских киргизов, но еще не замужем, и свадьба отложена на многие годы», – ди. Туйның ни өчен кичектерелүе безгә мәгълүм түгел. Бары тик Зөһрәкәйнең Җиһаншага кияүгә чыкмавы, 1844 елда 16 яшендә вафат булуы гына билгеле. Әгәр ул кияүгә чыккан булса, кабер ташына, һичшиксез, иренең дә исеме язылган булыр иде. Соңрак, 1846 елда, солтан Җангали Урманов Җиһангир ханнан, улы Җиһаншага ярәшелгән Зөһрәнең вафат булуы сәбәпле, кызы Зөләйханы сорый. Әмма Зөләйхага да солтан килене булу насыйп булмый.

Балаларының һәм 1845 елның 11 августында Җиһангир ханның вакытыннан алда вафат булуы Фатыйманың сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый. 1845 елның 16 августында Оренбург хәрби губернаторы В.Обручевка язган хатында ул, борчылып: *«Ваше высокопревосходительство Владимир Афанасьевич! Несчастье невыразимое постигло меня и семейство хана Джангира – 11 августа, после шестидневной болезни он умер, я тяжко больная, семейство его, в котором девять малолетних детей-сироты.*

Генерал! С первого свидания с вами во всю службу под вашим начальством и в особенности после последней поездки своей к вам в Оренбург, покойник с живою признательностью говорил мне о Вас, как о начальнике справедливейшем

и благодетельнейшем – с постели моей, к которой я прикована тяжкою, может быть даже смертельною болезнью, окруженная малолетними сиротами, молю вас именем Бога взять под свое покровительство меня и мое семейство, устроить в лице Сагиб-Гирея признанного уже государем императором, как знаем мы от хана, преемником ханского в Орде достоинства, участь нашу и участь Орды», – дип белдерә.

Хан Урдасы казые, тархан Җ.Хәмидулла һәм указлы мулла Айтуган Мостафинның шаһитлыгында васыять язып, анда мөлкәт бүлгәндә уллары һәм кызларының тигез булачаклары, тәхеткә утырганчы 15 яшьлек улы Сәхибгәрәйгә Гадел Бүкәйханов белән энесе Әмирханның опекун итеп билгеләнәчәген хәбәр итә.

Фатыйма 1845 елның 2 октябрендә бакый дөньяга күчә. Аның үлеменнән соң, хан гаиләсеннән бәрәкәт китә. 1849 елның 11 июнендә төп варис Сәхибгәрәй вафат була. Аны хан тәхетенә утырыр дип өметләнгән булалар. Җиһангирның Фатыймадан туган башка ул һәм кызларына Хан Урдасында яшәү насыйп булмый.

Р.Фәхреддин язганнар белән бездә булган мәгълүматлар бик үк тәңгәл килми. 1850 елның августында ханның Неплюев кадет корпусында укыган Исмәгыйль исемле улы бакый дөньяга күчсә, «князь Чингиз» дип аталган Ибраһим Оренбургтагы хезмәттән азат ителә алмый һәм 1865 елда, 31 яшендә вафат була. Хәдичәдән алда туган кызлары Гайшә дә яшьли үлә. Зөләйха исемле кызы морза, штаб-ротмистр, мөселман дин эшлеклесе, Оренбург Мөселман диния нәзарәтенең 2 нче мөфтие Сәлимгәрәй Тәфкилевкә кияүгә чыга һәм кече сеңлесе Хәдичәне үзе белән алып, Уфа шәһәрендә яши. Соңрак Хәдичә солтан Сәедхан Җантуринга кияүгә чыга. Аларның никахыннан күренекле галим, сәясәтче, «Иттифак әл-мөслимин» фиркасен оештыручыларның берсе, «Милләт» гәҗитенә нигез салучы Сәлимгәрәй Җантурин дөньяга килә. Җиһангирның уллары Әхмәдгәрәй белән Гобәйдулла Кырымда яшиләр һәм шунда бакый дөньяга күчәләр.

Фатыйма ханымның балда кигән күлмәге

***

Татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани казакъ ханы Җиһангир турында: *«Диндар, галимнәрне яратучы, яхшы күңелле, юмарт бер зат иде»,* – дип язып калдырган. Үз вакытында белемлелеге, зирәклеге белән аерылып торган, рус патшасын үткен җаваплары белән таң калдырган Фатыйма ханым иренең фикер-карашлары формалашуга зур йогынты ясаган, аңа акыллы киңәшче һәм тугры хатын була белгән.

Фатыйма ханымның кигән камзолын кызы Зөләйха саклап, кызы Гөлсем Шейх-Алига бүләк итеп калдыра. Соңрак бу бишмәт Казакъстан Республикасы вәкиллеге тарафыннан сатып алына һәм 1923 елда музей фондына тапшырыла. Хәзерге көндә Астана шәһәренең Милли музеендагы бу ядкяр Фатыйма ханымның гүзәл буй-сынын гәүдәләндерә кебек. Ә балда кигән затлы күлмәге Хан Урдасы тарихи-мәдәни архитектура-этнография музееն бизи.

Казакъчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе* ■

Коточкыч ачлык

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Чистайда ачлык көннәре

Чистай кантонында Красноярволосте белән Биләр волостьлары кантонның башка волостьларына караганда аерата җәфа чигәләр. Биләр волостендагы Югары һәм Түбән Майна авылларында һәр көн 5-6 кеше ачлыктан үлеп тора. Бу авылларда эт, песи, күгәрчен кебек җан ияләре күптән ашалып беткән. Ат, сыер кебек хайваннарның 70-80 проценты суелган. Кәҗә, сарык кебек вак хайваннарның 90 проценты ашалган.

Красноярволостендагы Урманасты Шынтала авылында эш тагын да начаррак. Бу авылда һәркөн 6-7 кеше ачка үлеп торса да, казып күмүче юк. 25шәр, 30ар гәүдәне салкын амбарга җыеп торалар. Монда да эт, мәче, үләксә, күгәрчен ашалып беткән. Авылда балалар өчен ачылган американский вә башка столовойлар булса да, алар белән генә, әлбәттә, ачлыкны җиңәрлек түгел.

Красноярволостендагы Урманасты Шынтала авылындагы ачлыкны түбәндәге рәкымнар *(саннар)* аңлатыр дип беләм. 1900 нче елларда бу авылда барысы 953 җан хисапланган. 1922 елның февралендә ир вә кыз-хатыннар барысы 800 җан икәнлеге Авыл Советының ясаган хисабыннан мәгълүм булды. Аурупа сугышына кадәр авылда 200 баш ат, 215 сыер, 500 баш сарык, 300 кәҗә бар иде. 1920 елның көзендә бу хайваннарның 25-30 проценты кимеде. Ә 1921 елның көзендә, ягъни бу ел кышта бу авылдагы хайваннарның хисабы түбәндәгечә: ат – 45, сыер – 50, сарык-кәҗә – 70 баш; тавык, каз, үрдәк кебек йорт кошлары бөтенләй юк. Әгәр хөкүмәттән тиз генә ярдәм килеп җитмәсә, бу күренеп торган корчаңгы атлар да суелып, ашалып бетәчәк. Тимер белән таштан башка нәрсәләр ашалып бетте. Ярдәм булмаса, авылыбызда 100-150 җаннан артык кеше калыр дип беребез дә уйламыйбыз. Авылыбызда баерак йортлар булса да, капкаларын, ишекләрен бикләп торалар. Шул байлар ачка үлүчеләрнең бөтен нәрсәләрен, 5-10 кадак алабута оны биреп, үзләренә җыеп бетерделәр инде. Пот-пот ярым алабута оны биреп, үлүчеләрнең йортларын алалар.

Кыскасы, Урманасты Шынтала авылы очы-кырые булмаган бер караңгылыкка – җәһәннәмгә төшеп бара. Көндезләрдә урамнарда йөрүче юк, озын төннәрдә авылның һичбер җирендә, һичбер йортында ут янганын күрмәссең!

13 февральдә Краснояр авылында укытучылар съезды булды. Съездда мәктәпләрнең ябылганлыгы, тик Урманасты авылында гына ябылмыйча дәвам итәчәге игълан ителде.

«Таңчы».
Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 15 март.

Лаеш кантонында ачлык нәтиҗәсе

31 мартта Сәләнгүш волостеның Күн авылы кырында 4 яшь белән ике яшь арасында бер ир бала табылды. Бала хәзерге көндә исән, гаять таза һәм тере

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2021) санында.

гәүдәле. Төрелгән һәм чорналган киемнәренә караганда, керәшен баласы булырга тиеш. Олы юлдан 30-40 сажин читкә кертелеп кар өстенә ташланган. Юлчылар баланы күреп алып, Күн Авыл Советына тапшырып киткәннәр. Авыл Советы баланы волостьтагы милиция башлыгына тапшырды вә аннан районга озатылды.

Мондый вәхшилекләр барысы шул ачлык аркасында эшләнә. Тиздән киң рәвештә ярдәм бирелмәгәндә, тагы әллә никадәр яшь балалар үз ата-аналары тарафыннан буылып, суга яисә башка урынларга ташлануы ихтимал.

Мөхбир.
Татарстан хәбәрләре.–
1922. – 6 апрель.

Чистай кантонында ачлык дәһшәтләре

Чистай кантонында ачлык һәм тиф сәбәпле, бөтен халыкның да тормышлары бик авыр: аларның 90 проценты ач вә 22 проценты авыру. Азыклар һәм терлек азыклары булмау сәбәпле, кешене иткә суеп ашаулар бик күбәйгән. Кайсыбер кешеләр хәер эстәп йөрүчеләрне, алдап кертеп, иткә суя башлаганнар. Үз балаларын суеп, кисмәкләргә салып куючылар да бар. Февраль эчендә 14 мәетнең ашалганлыгы һәм 33 кешенең иткә суелганлыгы мәгълүм булган. Ачлык сәбәпле, кантонда һәртөрле җинаятьләр арта, Совет мөәссәсәләре *(оешмалары)*, шифаханә, мәктәпләрнең эшләре җимерелә. Тиф һәм башка авырулар һаман көчәя бара. Халык тәмам эштән чыккан вә шул сәбәптән үлемгә салкын кан белән карый башлаган. Кантонга хәзер үк катгый ярдәм кирәк!

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 7 апрель.

Качаклар дулкыны

Ачлыктан куркып кача торган зур кешеләр арасында бик күп балалар да катнашалар. Алар ач җирләрдән зурлар белән бергә һәм алардан башка да качалар. Алар шәһәрләргә киләләр, аларга: «Шәһәрдә ашаталар да, киендерәләр

дә», – дип әйтәләр. Әмма вакыйгда *(чынлыкта)* һәммәсен урнаштырырга мөмкин булмый.

Ач халыкларның шәһәрләргә качып килүләрен туктату өчен, түбәндәге чараларны гамәлгә куярга кирәк: крестьяннарны һәлакәткә төшерерлек куркынычлы сәфәрләргә чыкмаска һәм ярдәм килеп җиткәнче түзеп торырга үгетләү; һәм кантоннарга азыклар җибәреп, мохтаҗ булганнарга урыннарда турыдан-туры паеклар өләшү вә бөтен запас азыкларны ачларны туйдыру эшләренә сарыф итеп, гамәли чаралар күрергә кирәк.Шушы чараларны тиз гамәлгә куйган вакытта гына ачларның качып китүләрен туктатырга яки беркадәр киметә төшәргә мөмкин булачак.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 14 апрель.

Мамадыш

Ачлык көннән-көн куәтләнә. Соңгы көннәрдә ачлык ниһаясез куәтләнде. Халыкның күбесе, былтыр көздән әзерләп калдырган алабута, имән әкәлесе, алма, юкә вә башка агач кайрыларын ашап бетерү өстенә, мал-туар, кош-кортларны да, мәче, эт, тычкан, күсе, күгәрчен, карга кебек мәхлукатларны да байтак азайтты. Инде моннан соң ашарга һәрбер төрле ризык таба алмый тәмам аптырашта калды. Бер кабым икмәккә тилмереп, ачлыктан егылган гәүдәләрне урамнарда, юлларда, урманнарда бик җыш очратырга мөмкин. Менә мондыйларның күбесе, йөреп-йөреп тә ашарга таба алмагач, урманнарда, юл буйларында кызганыч хәлдә үләләр.

Бу хәл урысларда күп күренми, чөнки алар яшелчә эшләп үзләрен бу куркынычтан саклап кала алдылар. Урыс хатыннары яшелчәләргә су сибеп йөргәндә, безнең татар хатыннары тик кенә яттылар. Шуның нәтиҗәсендә, эш шул дәрәҗәгә килеп җитте.

Инде үткәндәге ачы хаталарны төзәтергә кирәк, киләчәктә тагын бундый көннәргә төшмәс өчен, татар халкын яшелчә үстерергә кызыктырырга, хәтта мәҗбүри рәвештә яшелчә бакчалары тәрбия итәргә кушарга кирәк.

Мирза угылы.
Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 21 апрель.

Арча кантонында уҗымнарны сату

Ачлыкның соң дәрәҗәдә куәтләнеп китүе сәбәпле, авылларда яңадан-яңа вакыйгалар туып торганлыгы һәркемгә мәгълүм. Арча кантоныннан килгән бер иптәшнең сөйләвенә караганда, ачлыктан крестьяннар үткән ел чәчеп калдырган уҗымнарын да авыл кулакларына юк бәһагә (бер-ике пот бәрәңгегә) сатып ашый башлаганнар. Димәк, үткән ел чәчеп калдырган игеннәр дә авыл кулаклары кулына кереп бетсә, киләсе җәйдә иген уңса да, ачлыкның һаман озакка сузылуы ачык күренеп тора һәм бу көндәге актык уҗымын сатып ашаган ачларның сабан ашлыгын чәчә алулары да шөбһәле. Бу эшкә волость, Авыл Советлары тарафыннан чик куелмаса, киләчәктә ачлыкның нинди нәтиҗәләр бирүе үзеннән-үзе күренеп тора.

Шуның өчен бу мәсьәләгә урыннардагы оешмалар ачык күз белән карарга тиешләр. Әгәр дә авыл кулакларының дисәтинә-дисәтинә уҗым сатып алыр-

лык маллары була икән, шул уҗым бәрабәренә бирә торган он, бәрәңгесе кебек нәрсәләрен түләү шарты белән ачларга алып бирсә, бу эш ил өчен, әлбәттә, файдалы булачак. Вөҗдан ягыннан караганда да ачларны кайгырту дисәтинәләп уҗым җыярлык кешеләр өстенә төшә.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 22 апрель.

Тәтеш кантонында ачлык көчәя

Тәтеш кантонының Балчыклы авылында үткән елның май аенда гына 1174 җан хисапка алынган иде. 1922 елның 15 апреленә шуннан барлыгы 650 җан калганлыгы мәгълүм булды. Авыл халкының күбрәге Себергә күчсәләр дә,елның сентябрь аеннан бирле фәкать ачлыктан гына да 150 кеше үлде. Карт һәм балаларга караганда хезмәт көчләре күбрәк үлгән. Моннан соң да хөкүмәт тарафыннан ярдәм бирелмәсә, июль аена кадәр байтак эшчеләрнең үлүе күренеп тора. Хәзерге көндә 20 йорт кадәр гаилә, шешенеп, үлем нәүбәтендә тора.

1921 елда авылыбызда 120 баш ат бар иде, 1922 елның апрель аена кадәр фәкать 20 баш калды. Авыл халкына хөкүмәт тарафыннан чәчү орлыгы бирелсә дә, авылдагы атларның шулкадәр аз калуы, икенчедән, алар да күтәреп торгыза торган атлар гына булуын исәпләгәндә, 268 дисәтинә җирне эшли алмаячагыбыз мәгълүм булса кирәк. Шуның өчен ат көче белән дә ярдәм ителмәсә, язгы чәчү эшләрен рәтләп булмас кебек күренә.

Авыл Советы секретаре: Минһаҗ Җәләлетдинов.
Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 3 май.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

Нурлы шәхес

Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе

Студент вакытындагы дуслык гомерлек (сулдан уңга): Равил Шаһимәрданов, Минтимер Шәймиев, Әнвәр Иванов. 1990 нчы еллар

Үз гомеремдә – яшүсмер чакларда, институтта укыганда, төрле эшләрдә, югары вазыйфаларда булганда, бик күп кешеләр белән танышырга-аралашырга туры килде. Шулар арасында күңелгә чынлап кереп калганнары, еллар узгач сагындыра торганнары күп дип әйтмәс идем. Андыйлар үзгә. Алар, гадәттә, үзләре турында искә төшерергә кыймый торган, тәрбияле, тыйнак һәм затлы кешеләр. Казан авыл хуҗалыгы институтында укыган вакытта танышкан курсташым, дустым Равил Габделнур улы Шаһимәрданов та – шундыйлардан. Студент елларыннан ук күңелемә якын кешеләрнең берсе ул.

Без хәзер Актаныш районына керүче, ул чакта Калинин районының Әнәк авылыннан 1954 елда Казанга килеп, Авыл хуҗалыгы институтында укый башладык. Моңарчы Минзәләгә дә барганыбыз юк иде, ә монда – Казан үзе! Әйләнә-тирә ят, бер генә таныш кеше дә юк, аңлашыла ки, беренче көннәрдән үк авылны, әти-әнине, туганнарны сагына башлыйсың. Шулай ямансулап-каңгырап йөргән көннәрнең берсендә үзебезнең курс студентлары арасында күркәм буй-сыны, дустанә мөнәсәбәте, ягымлылыгы белән аерылып торган Равил исемле егеткә игътибар иттем. Ул үз-үзен тотышы, кыяфәте, сөйләшүе белән минем Хантимер абыема охшаган иде. Без күпбалалы гаиләдә үстек, инде сөйләгәнем дә бар: бездән алданрак туган ир балалар гомерле булмаган, шуңа күрә әти-әни, нык булсыннар дип, 1934 елда туган абыема – Хантимер, миңа Минтимер дип исем кушкан. Шуңа да карамастан, абыем озын гомерле булды дип әйтеп булмый, 50 яшькә дә җитә алмады, артык күп эшләде, машина йөртүче иде, көне-төне юлда булды, безгә, туганнарына гына түгел, бөтен кешегә булышырга тырышты. Без, гаиләдә ике малай, хуҗалыктагы авыр эшләрне гел бергә эшләдек. Миңа китап укырга вакыт калсын дип, күп эшләрне үзе генә башкарып чыга иде ул. Бик ярата идем абыемны, шуңа күрә аңа охшаган Равилне күреп алгач, Казанда да абыем кебек яхшы кешеләр бар икән, дип, ничектер, бераз тынычланып киттем.

Икенчедән, Равил бик шәп биюче иде. Ул елларда тулай торакта, институтта очрашулар, концертлар, бию кичәләре еш оештырылды. Шул кичәләрдә Равил биергә чыкса, барысы да шаккатып, сокланып карап торалар. Гәүдәгә зур булса да, бик җиңел, матур бии иде үзе. Гомумән, һәркемне үзенә җәлеп итә, «сөйкемле сөяк» дип әйтәләр андый кешеләр турында.

Гаилә дуслары (сулдан уңга): Сиринә һәм Равил Шаһимәрдановлар, Сәкинә һәм Минтимер Шәймиевләр, Суфия һәм Әнвәр Ивановлар. 1990 нчы еллар

Менә шулай читтән генә карап, сокланып йөргәндә, бервакыт сөйләшергә дә җай чыкты. Аның татарча чиста, яхшы сөйләшүе, кем әйтмешли, җанга май булып ятты. Казан егете бит, шәһәрдә үскән! Без, авыл балалары, русча юньләп сөйләшә белмибез, кайбер шәһәр малайлары көләләр иде бездән. Ул гына да түгел, кайберләре үзләрен бик өстен тота иде. Сөйләгәнем дә бар: беренче курс башында безне Балык Бистәсе районына бәрәңге алырга җибәрделәр. Шунда шәһәр малайлары бәрәңгенең сабакларын йолкып чыгалар да, бәрәңгесен калдырып узып китәләр. Авыл баласы моңа түзеп тора алмый, билгеле. Шундыйларның берсенә кисәтү ясадым, ә ул исә, җавап итеп, «чаплашка», дип кычкырды. Башына бәрәңге җибәрергә туры килде. Бу бик яхшы сабак булып чыкты, биш ел буена берәү дә андый сүз ычкындырмады. Теге егет белән дә соңыннан дуслаштык.

> «
> **Без, авыл балаларына, аның мөнәсәбәте дустанә, җылы иде. Равил ярдәмендә шәһәр тормышына күзебез ачылды. Ул безгә көчле терәк булды.**

Ә Равил Шаһимәрданов, әйткәнемчә, Казан егете булуына карамастан, рәхәтләнеп, авыз тутырып, матур итеп татарча сөйләшә иде. Тиздән якыннан танышу өчен форсат та килеп чыкты. Имтихан биреп йөргәндә Әнвәр Шакир улы Иванов белән таныштык. Ул шахтер гаиләсеннән, Казанга Кузбасстан килгән. Элекке заманда, күп гаиләләр кебек, әти-әниләре шахтага китеп төпләнгән. Фамилияләренең тарихы да кызыклы: Әнвәрнең бабасы патша армиясендә хезмәт иткән, командиры бабасының Ибниев фамилиясен әйтә алмаганга, аның рөхсәтен алып, Иванов дип атый башлаган. Шулай берегеп калган Иванов фамилиясе. Әнвәр исә туган җиргә, Казанга кайтып, Авыл хуҗалыгы институтында укырга хыялланган. Дуслашып киттек, укырга кергәч, күрше фатирларга урнаштык. Ул бездән яшькә бераз зуррак иде, мин аңа кайчак уку буенча булыша идем. Ә безнең торак-хуҗалык эшләрен күбесенчә ул алып барды. Әнвәр Шакирович кешелекле, ярдәмчел иде, без аның белән гомер буе дус булдык, гаиләләр белән аралашып яшәдек.

Әнвәр исә, имтихан биргәндә, Равилләрдә яшәгән булып чыкты. Аның Равил белән таныш булуы миндә Равилгә карата ихтирамны тагын да арттырды. Әнвәр аша якыннан белешеп, дуслашып киттек Равил белән. Без, авыл балаларына, аның мөнәсәбәте дустанә, җылы иде. Равил ярдәмендә шәһәр тормышына күзебез ачылды. Ул безгә көчле терәк булды.

Институтны тәмамлагач, төрлебезне төрле якка эшкә җибәрделәр. Бераз вакытлар узганнан соң, мине обкомга эшкә алдылар, аннары мелиорация һәм су хуҗалыгы министры итеп куйдылар. Ул заманда, Брежнев вакытында, ил тарихында беренче мәртәбә мелиорация эшләре хөкүмәтнең колачлы сәясәтенә әйләнде. Чөнки халыкны азык-төлек белән тәэмин итү өчен сугарулы җирләр кирәк иде. Алдыбызга мелиорация эшен фәнни нигезгә кору мәсьәләсе килеп басты. Шул чакларда Равил Габделнур улы белән ничектер күрештек, ул Казан авыл хуҗалыгы институтында укыта иде. Мин аны үзебезгә эшкә чакырдым. «Без фәнни оешмалар төзибез, безгә килсәң, яхшы булыр иде», – дидем. Без аңа Төньяк гидротехника һәм мелиорация фәнни-тикшеренү институтының Казан гидрология һәм су ресурслары бүлеген җитәкләргә тәкъдим иттек. Ул ризалык бирде. Равил Габделнур улы бар яктан да булган кеше, ул яхшы укыды, эчке дөньясы бай аның. Без, мин, Әнвәр, Равил, һәрвакыт аралашып яшәдек. Равил гомерен фәнгә багышлады, күренекле галим булды. Кайда гына эшләсә дә, уңышка иреште. Гыйлеме, тырышлыгы, акылы, бай эчке дөньясы зур эшләрендә матур чагылыш тапты. Мәскәү фәнни институтлары белән эш итте. Безгә һәрвакыт зур таяныч булды. Татарстан Фәннәр академиясенең Экология һәм табигый системалар институтын оештыруны башлап йөрде, аның беренче директоры булды, институтны 2010 елга кадәр җитәкләде.

«Сокланырлык күркәм сыйфатларга ия матур гаилә бу. Милләтебездә менә шундый затлы гаиләләрнең булуы – зур байлык.

Булганнан бар да була, ди безнең халык. Равил үзенә тормыш иптәшен дә Мәскәүдән алып кайткан булып чыкты. Туры килә бит шулай, язмыш шундый кешеләрне махсус очраштыра диярсең! Карап кына торырлык чибәр кыз Сиринә һәм безнең Равил – соклангыч пар. Белүемчә, Равил Мәскәүгә эш белән барган да студент кыз Сиринәне очраткан. Совет чорында да динне ташламаган көчле, затлы, белемле нәселдән Сиринә. Ялгышмасам, чыгышлары белән Ютазы районыннан, Башкортстан чигеннән. Сиринә – уңганнарның уңганы, энергиясе ташып тора. Вакытында без гаиләләр белән очраша идек, минем Сәкинә белән дә дуслаштылар.

Равил белән Сиринә төрле холыклы. Сиринә – ут кебек, бөтен нәрсә кулыннан килә, эшендә дә, гаиләдә дә өлгер. Равил исә тыныч, сабыр, күп сөйләшмәс, әмма үз сүзен вакытында әйтеп куяр. Шуңа да карамастан, араларыннан җил дә үтмәде, гомер буе бер-берсен яратып, тигез, тату гомер итәләр. Искиткеч булдыклы, ипле егетләр үстерделәр. Гомумән, Шаһимәрдановлар – заманнар нинди генә булмасын, ана телебезне, гореф-гадәтләребезне, динебезне олылап-саклап, түкми-чәчми үз балаларына тапшыруның мөмкин хәл икәнен ачык күрсәтеп торучы үрнәк гаилә. Барыбыз өчен дә үрнәк дип әйтер идем. Бик зур рәхмәт аларга! Уллары динебезне үстерүгә зур өлеш кертәләр. Сокланырлык күркәм сыйфатларга ия матур гаилә бу. Милләтебездә менә шундый затлы гаиләләрнең булуы – зур байлык.

Равил Габделнур улы Шаһимәрданов – гомер буе яратылып яши торган мәхәббәтле, нурлы шәхес. Аны 85 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм! Шушы форсаттан файдаланып, аңа гомер буе әйтелмәгән сүзләремне әйтәсем килде, гәрчә әйтеп бетерү мөмкин булмаса да. Аның кебек кешеләрне Ходай тормышыбыз игелеклерәк булсын өчен бирәдер, мөгаен. Алар үзләре өчен генә түгел, кешеләрне тәрбияләү өчен дә яшиләр. Чөнки алар тирәсендә начар булып булмый. Аллага шөкер, күз тимәсен, хәзерге көндә Равил белән Сиринә матур яшиләр. Исәнлек-саулык телик үзләренә!■

Чирек гасыр бергә

Асия Горшкова*

1980 нче еллар башында Төньяк гидротехника һәм мелиорация фәнни-тикшеренү институтының Казан Гидрология һәм су ресурслары бүлеге университетны әле яңа гына тәмамлаган яшь белгечләр төркемен эшкә алды. Алар арасына миңа да эләгеп, республикабызның елгаларын өйрәнү бәхете тиде. Кайнап торган яшьлек дәрте, яңа белемнәр, үз көчебезгә һәм СССР фәне перспективаларына ышаныч бездә яңа прогрессив идеяләр барлыкка килүенең нигезе булды. Җитәкчебез Равил Габделнур улы Шаһимәрданов яшь галимнәрнең бөтен инициативасын хуплады, безгә рухи һәм матди ярдәм күрсәтте. Дөньяның төрле мәшәкатьләрен күреп, шактый тәҗрибә туплаган кеше буларак, һәр идеянең дә үсеш алмаячагын белә торып, директорыбыз бернинди каршылык тудырмады, киресенчә, сораган һәр җиһаз, реактивлар, лаборатория киемнәре, транспорт чаралары белән тәэмин итеп, безгә төрлечә ярдәм күрсәтте. Ел саен без озак вакытлы экспедицияләр оештырдык, беренчел табигый материалларны алып кайтып, аларны өйрәндек, статистик исәпләүләр, аналитик эшләр башкардык, фәнни нәтиҗәләребезне китап һәм җыентыкларда бастырдык. Кыскасы, һәр ачыш һәм фәнни нәтиҗәдән соң, без бәхет күгендә йөздек. Хәзерге заманнан үткәнгә борылып карасаң, Равил Габделнур улына, бигрәк тә 1990 нчы еллар башында, шактый авыр булганлыгын, нинди акыллы карарлар кабул итеп, институтны һәм совет чорында формалашкан фәнни мәктәпне, тәҗрибәле белгечләрне саклап калу өчен көрәшергә, кыю эш-гамәлләр башкарырга туры килгәнен ачык аңлыйсың.

Тормыш шулай корылган ки, һәр кеше, билгеле бер яшь чиген үткәч, үткәнне хәтердә яңарта башлый. Әле кайчан гына Сукно бистәсендә яланаяк, ваемсыз гына йөгереп йөргән Равилнең мәктәп еллары да үтеп китә. Шәһәр егете тормыш юлын Казан авыл хуҗалыгы институты белән бәйләргә була: механизация факультетын тәмамлый. Аннары Мәскәүдә Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясе аспирантурасында укып, техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Армиядә хезмәт

* **Асия Тихоновна Горшкова** – ТР Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институтының гидрология (кече елгалар) лабораториясе мөдире.

итә, чирәм җирләрне күтәрүдә катнаша. Ниһаять, Равил Шаһимәрданов Мәскәүдә татарның иң сылу кызы Сиринәгә гашыйк булып, гаилә кора. Шуннан соң Татарстанга кайтып, Усад авыл хуҗалыгы училищесында укыта башлый. 1961 елда ул яңадан Казан авыл хуҗалыгы институтына кайтып, озак еллар булачак агроном һәм инженерларга авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итүнең гидравликасы курсын укыта.

1976 елда Казан авыл хуҗалыгы институты доцентын курсташы, ТАССР мелиорация министрыМинтимер Шәрип улы Шәймиев үз янына чакырып ала һәм Төньяк гидротехника һәм мелиорация фәнни-тикшеренү институтының Казан Гидрология һәм су ресурслары бүлеген җитәкләргә тәкъдим итә. Шул көннән башлап, галим республикабызның су ресурслары белән ныклап шөгыльләнә башлый. 1993 елда аның инициативасы белән ТР Фәннәр академиясенең Экология һәм табигый системалар институты оештырыла. Равил Габделнур улы әлеге яңа институтның беренче директоры була һәм аны 2010 елга кадәр җитәкли.

Институтта галим җитәкчелегендә елга-күлләрне өйрәнүнең гидрологик-географик ысуллары, су ресурсларын рациональ файдалану методикасы эшләнә һәм кешенең сулыклар пычрануга йогынтысы өйрәнелә. Фәнни казанышларның берсе булып кече елгаларның үзлегеннән чистарыну механизмнарын тикшерү тора. Бу фәнни хезмәтләр республикабыздагы елгаларны һәм табигый күлләрне «яшелләнү»дән (фәнни телдә – эвтрофикация) саклау ысулларын эшләргә мөмкинлек бирә.

Равил Габделнур улы Шаһимәрданов җитәкчелегендә гидрологик, мелиорация һәм су хуҗалыклары карталарын төзү методикасы эшләнә. Шуның нигезендә Татарстан, Чуашстан, Мари-Эл Республикалары һәм Ульяновск өлкәсе өчен уникаль гидрологик карталар булдырыла. Шулай ук Татарстан Республикасындагы гадәттән тыш экологик вазгыятьне тасвирлый, районнарда табигатьнең пычрану дәрәҗәсен күрсәтә торган карталар сериясе дә эшләнә. Республикабыздагы елга-күлләрдә һәм су хуҗалыкларында дәүләт мониторингын оештыру, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының экологик торышын, кече елгаларның гидроэнергетик потенциалын бәяләү ысуллары булдырыла.

Әлеге фәнни хезмәтләр язгы су басуларның күләмен алдан фаразларга, су күләме артып киткән очракта сусаклагычларны җимерелүдән саклау чараларын күрергә, елга-күлләргә агып төшә торган пычрак суларның күләмен ачыкларга, сулыкларны нефть белән пычранудан сакларга, елга бассейннарындагы басу-кырларга кертелә торган ашламаларның рөхсәт ителгән күләмен билгеләргә мөмкинлек бирә. 2005 елда, Равил Шаһимәрданов җитәкчелегендә, Казанның 1000 еллыгына багышланган фундаменталь хезмәт – «Татарстан Республикасы Атласы» әзерләнде һәм нәшер ителде. Атластагы карталарның шактый өлеше безнең институт галимнәре тарафыннан төзелде.

Ачык йөзле, олы йөрәкле, белемле һәм инициативалы җитәкче Равил Габделнур улы Шаһимәрданов ТР Фәннәр академиясе Президиумы каршындагы Экология проблемалары Советы әгъзасы, ТР Дәүләт музееның Попечительләр Советы әгъзасы, ТР Экология фонды Советы әгъзасы, Россия экология академиясенең мөхбир әгъзасы, Казан авыл хуҗалыгы институтының шәрәфле профессоры булды. Мелиорация-хуҗалык эшчәнлеген нәтиҗәле башкарганы һәм фәнни-оештыру өлкәсендә уңышлы эшләгәне өчен, ул Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, «Су хуҗалыгы отличнигы» күкрәк билгесе белән бүләкләнде, аңа «Россия Федерациясенең атказанган экологы» дигән мактаулы исем бирелде. Галим «Казанның 1000 еллыгы» һәм «Әйләнә-тирә мохитне саклаудагы казанышлары өчен» медальләренә лаек булды. ■

Тукай «таныштырды»

Сиринә Сәлимшина-Шаһимәрданова

Мин Мәскәү технологик институтында 4 нче курста укыганда бер егет белән таныштым.

Ә ул болай булды. 1966 елның апрель аенда Татарстаннан СССР башкаласына килгән XXIII партия съездында катнашучылардан 10 делегат арасында миңа да Мәскәү дәүләт университеты бинасында бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулу уңаеннан үткәрелгән конференциягә бару насыйп булды. Анда Г.Тукайның тормыш юлына, иҗатына багышланган бик күп чыгышлар ясалды.

Әлеге конференциядә булган делегатлар арасында ТАССР өлкә комитетының беренче секретаре Фикърәт Табеев, данлыклы җырчыбыз Илһам Шакиров һәм башкалар бар иде. Бирегә Мәскәү дәүләт университетының күп кенә профессорлары һәм белем бирүче укытучылары, башка югары белем бирү йортлары студентлары да килгән иде.

Бөек шагыйребезнең туган көне белән котлау сүзен рус телендә Фикърәт Табеев башлады. Шунда бер профессор, урыныннан торып: «Нишләп Сез котлау сүзен русча сөйлисез?» – дип әйтеп куйды.

Чыгышлар күп булды. Илһам Шакиров бик матур итеп татарча сөйләде, аннары рояль артына утырып, «Кара урман»ны җырлап бирде. Җыелыш Тимирязев исемендәге академия клубында дәвам итте һәм татар студентлары оештырган зур концерт белән тәмамланды. Музыкаль биюләр барышында мин Казан егете Равил белән таныштым (МДУ бинасында үткәрелгән конференциядә ул анда булса да, мин аны әле белми идем). Концертта ул Тукайның ике шигырен русча сөйләде һәм татар биюен башкарды. Мин җыр белән катнаштым. Казан егете бу академиянең аспиранты Равил Шаһимәрданов булып чыкты.

Без Габделнур улы Равил белән ныклап танышып китеп, 1967 елда Аллаһының рәхмәте белән өйләнештек. Ике ул үстердек. Олы улыбыз Рөстәм КАИ тәмамлады, хәзерге көндә Мәскәүдә тимер юл компаниясендә коммерция директоры булып эшли. Хатыны белән Рафаэль, Роберт, Руслан, Ренард һәм Лилия исемле балалар үстерә. Кече улыбыз Айдар КДУ, КДФЭИ һәм Россия ислам институтын тәмамлады, Россия Федерациясенең Мөселман эшкуарлары ассоциациясе президенты булып эшли, бизнес белән шөгыльләнә. Хатыны белән Әмир, Асель һәм Мәрьям исемле балалар үстерә.

Редакциядән: *Россия Федерациясенең атказанган экологы, галим Равил Габделнур улы Шаһимәрдановка 85 яшь тулды. Аны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, саулык-сәламәтлек, гаиләсенә бәрәкәт, иминлек һәм бәхет-сәгадәт теләп калабыз!* ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – язучылар һәм сәнгать әһелләре март аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтте. Менә алар:



1 март – язучы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Нурислам Габдулла улы Хәсәновка (1941) 80 яшь

6 март – җырчы, ТАССРның халык артисты Шамил Сабир улы Әхмәтҗановка (1941) 80 яшь

10 март – Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Фоат Миңлеәхмәт улы Садриевка (1941) 80 яшь

18 март – Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Клара Гариф кызы Булатовага (1936) 85 яшь

19 март – балет артисты, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Камил Гайфулла улы Гайнуллинга (1946) 75 яшь



21 март – әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, ТРның һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре Фоат Галимулла улы Галимуллинга (1941) 80 яшь

27 март – шагыйрә һәм прозаик, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Сәйдә Закир кызы Зыятдиновага (1941) 80 яшь

29 март – балет артисты, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ирина Шәрифҗан кызы Хәкимовага (1951) 70 яшь

Күренекле шәхесләребезнең барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз!

Остазым Рәдиф Гаташ турында

Чулпан Зарипова-Четин

Күренекле татар шагыйре Рәдиф Гаташ татар, төрек һәм Аурупа әдәбиятларының иң матур, иң бай традицияләрен үрнәк итеп алып, менә инде алтмыш елдан артык армый-талмый шигырьләр язып, безләрне сөендереп яши. Мондый язмыш бик сирәк шагыйрьләргә генә насыйп буладыр дип уйлыйм. Күренекле татар язучысы һәм әдәбият белгече Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйтсәк, «анасыннан шагыйрь булып туган», бөтен торышы, тышкы кыяфәте һәм рух халәте белән Байрон һәм Сәгыйть Рәмиев кебек гыйсьянчы шагыйрьләрне хәтерләткән Рәдиф Гаташ шигырьләрендә татар халкына, Ватанына, матурлыкка һәм мәхәббәткә мәдхия укый. Һәр буында үз укучысын таба белгән шагыйрь татар милләтенең шанлы үткәне белән горурланып, аның бүгене турында кайгырта һәм киләчәге турында күрәзәлек итәргә тырышып, тирән мәгънәле, чынчынлап милли шигырьләр иҗат итә.

Галимә һәм шагыйрә Чулпан Зарипова-Четин остазы Рәдиф Гаташ белән. Казан, 1994 ел

Рәдиф Гаташ татар дөньясының иң бай тарихлы һәм абруйлы журналларыннан берсе булып саналган «Казан утлары» журналында кырык елга якын шигърият бүлеген җитәкләде. Кече күңелле, кешелекле, бай эрудицияле, фәлсәфи уй-кичерешләргә ия талантлы шагыйрь 1960 елдан бүгенгә кадәр, илһам чишмәсеннән су эчеп иҗат итү белән бергә, татар шигъриятен яңа исемнәргә дә баетты. Аның укучылары (Зөлфәт, Наис Гамбәр, Рафаэль Сибат, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Нурия Измайлова, Чулпан Зариф, Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллина һ.б.) инде күптән шигърияттә үз юлын тапкан шагыйрьләр һәм шәхесләр булып җитеште. Араларыннан Зөлфәтнең остазы булу гына да үзе ни тора!

...Рәдиф Гаташка 80 яшь тулуны кабул итү, бер караганда, мөмкин дә түгел кебек. Чөнки тәүге мәртәбә «Казан утлары» редакциясенә башыма эшләпә, кулларыма нәфис перчаткалар, ә аякларыма Арча читекләре киеп, «Сәгыйть Рәмиев һәм Нәсими» исемле мәкаләмне китергәндә, аңа әле нибары 55 яшь иде һәм ул күз алдымда гел шул килеш кала бирә. Хисчән, сабый рухлы, арабызда яшь аермасы зур булуга карамастан, менә инде утыз ел чын мәгънәсендә якын дустым, остазым булып кала алган нечкә күңелле шагыйрьне олы юбилее белән чын күңелдән котлыйм һәм мәкаләмне аның шәкерте, шагыйрь Рафаэль Сибат сүзләре белән тәмамлыйм: *«Такташлары, Гаташлары булган әдәбият – бәхетле вә тәхетле, һай диярлек бай әдәбият, әдәпле әдәбият ул. Күңелендә җәүһәрләр – ак ташлар яткан Гаташлар бу әдәбиятның матур бер бизәге булып тора»*.

Төркия, Карс

Редакциядән: *Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ (Рәдиф Кәшфулла улы Гатауллин) 30 мартта гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Аксакал әдибебезне юбилее белән ихластан котлап, аңа саулык-сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!* ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Сеул вокзалы. XX гасыр башы

Шундый төш күрдем: иксез-чиксез киң кыр янында торам икән. Янымда берничә кеше дә бар. Бу басуга берәр нәрсә чәчү турында сөйләшәбез. Киңәш-табыш бетәргә дә өлгермәде, кулыма китмән алдым. Балчыкны йомшартам да орлык сибәм, йомшартам да орлык сибәм. Ул арада тагын бер-ике кеше килеп чыкты. Алар да басуга төрле яклап килеп, казып йомшарту һәм орлык чәчү эшенә керештеләр. Мин ул арада эштән туктап, бер якка карап китеп бардым.Ниндидер мәмләкәтләр буйлап йөрдем, гомердә күргәнем булмаган тауларны аштым, гаҗәеп юллар буйлап бардым. Ниһаять, бер биек тау башында зур гына төркем эчендә икәнмен. Һава искиткеч матур. Тирә-ягыбыз зөбәрҗәт кебек таулар, бакчалар белән әйләндереп алынган. Монда да сөйләшүебез җир-туфрак, чәчү, үстерү турында иде. Кинәт бер гөрелте ишетелде, аннан соң ниләр булганын белмим, тик колагыма: «Вә калилүн мин-гыйбадие-ш-шекүр [Колларымнан шөкер итүче аз] (Җәбә: 13)», – дигән бөек аять ишетелде.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Шунда уянып киттем. Иртәнге намаз вакыты җиткән. Ул көнне дә иртүк юлга чыгасым бар иде. Тордым да төшемне дәфтәремә язып куйдым. Әйберләремне җыеп, кунакханә хуҗасына тиешле акчамны түләдем. Поезд станциясенә киттем. Моннан туры Мукденга юл тотачакмын. Биредә хезмәткәрләрнең дә, эшчеләрнең дә һәммәсе япон кешеләре. Миңа сөйләшер, сорашыр өчен бик җайлы.

«Корея хөкүмәте вакытында милләт табигый тормышы белән яши иде, кешесе хөр һәм азат иде. Бернинди басым юк, мал-мөлкәте булса, хөкүмәткә ни дә булса бирә, булмаса, берни бирми һәм җаваплы да түгел иде. Һәр кеше үзен үз өендә итеп тоя, үз мал-мөлкәтенә үзе хуҗа иде. Һичьюгы вөҗданы тыныч һәм калебе канәгать иде. Хәзер исә алай түгел, бар да үз йортында чит әмир күрә, бераү дә үз йортына үзе хуҗа, тапканы үзенә түгел. Без тырышып-тырмашып табабыз, алар, өлешкә кереп: «Яртысын син аша, яртысын миңа бир», – диләр.

Инде менә Корея мәмләкәтеннән дә китәргә җыенам. Поезд билеты алып, поездга утырган гына идем, каршыма бер корея кешесе килеп утырды.

Японча: «Кай җирләргә юл тоттыгыз?» – дип сорадым. Японча белми, ахрысы, җавап бирмәде. Аннары русча сораган идем: «Хотин», – диде. Әлегә мин Хотинның кайсы җир икәнен аңлап җиткермәсәм дә, бу кешенең русча белүен төшендем. Аннан соң: «Хотин ул кайда?» – дип сорадым. Болай дип җавап бирде: «Руслар Мукден диләр, тик аның чын иseme Хотин. Кытайлар да, без дә Хотин дибез. Руслар ник Мукден диләрдер, белмим».

Бу кешенең русчаны яхшы белүе һәм миңа Мукденга кадәр юлдаш була алуы бик әйбәт булды. Моңа бик шатландым. Поезд Сеулдан кузгалып китте. Юлдашым белән рәхәтләнеп сөйләшә башладым.

– Сезнең Кореяда поезд вокзалы бик матур, вагоннар да бик төзек, юллар да бик яхшы булырга тиеш, һич селкетми.

– Кореяның поезд юллары безнеке түгел, японнарныкы.

– Зыяны юк, сезнең мәмләкәтегездә төзелгән лә. Барыбер сезнеке булып чыга инде, борчылыр урын юк. Мал-мөлкәтнең төп хуҗасы барыбер сез буласыз.

– Әгәр кеше үз мөлкәтенә хуҗа була алмаса, башка кешенең мөлкәтенә хуҗа була алмый.

– Сезнең фикерләрегезне белергә телим, мөмкин булса, сөйләгез әле. Кореяда атна-ун көн вакыт үткәрсәм дә, берни сорашып белә алмадым, чөнки тел белмим. Аз гына японча беләм, тик ул бары японнар ярдәме белән генә сөйләшергә яраганга, чынбарлык турында фикер барлыкка китерү мөмкин булмады. Корея милләтенең бүгенге хәл-торышы, үткәннәре һәм киләчәкләре турында бераз мәгълүмат алырга теләгән идем. Очрашуыбыз бик яхшы булды әле, Сез тел беләсез. Иң башта шуны сорыйм әле: рус телен бу кадәр яхшы итеп кайда өйрәндегез?

– Минем белемем юк, бер вакытлар Владивостокта яшәгән идем, аннары Порт-Артурда гомер иттем. Эшем таләп иткәнгә өйрәндем.

– Динегез буддизм, шулаймы?

– Әйе, элегрәк будда динендә идем, аннан соң шулай килеп чыкты инде, православие диненә күчтем. Хәзерге көндә исә үз акылым үземә дин булып тора.

– Бик яхшы, мин бик шат, Сезнең болай шәхси фикергә ия булуыгыз миндә өмет тудырды. Мин, күргәннәремә таянып, Корея мәмләкәте корея милләтенең кулыннан киткән дигән фикергә килгән идем. Хәзер исә Сездән аласы мәгълүматлар белән бу фикер, бәлки, үзгәрер. Меңнәрчә ел үз җиренә үзе хуҗа булып торган милләтнең кинәт кенә сүнеп юкка чыгуына кайгырдым. Корея мәмләкәтенең киләчәге турындагы фикерләрегезне әйтеп, бераз мәгълүмат бирегезче, зинһар.

– Кореяның киләчәге-фәләне юк, Сезгә ничек күренгән булса, шулай.

– Мин бер атнада әллә ни күрә алмадым, тик, кая карама, японнар эш тоҗыралар – шуны күрдем.

– Мәмләкәтнең хуҗалары хәзер алар инде. Берничә ел үткәч, менә күрерсез, бөтенләй басып алачаклар.

– Японнарның басып алуына риза булырсызмы икән?

– Буласы калмаган инде, булган, беткән. Безнең риза булуыбызның яки булмавыбызның бернинди мәгънәсе дә юк. Бүгенге көндә японнар безнең ризалыгыбызны уйламыйлар, үз мәнфәгатьләрен кайгырталар. Вазыйфалары да шул. Бар да үз мәнфәгате өчен яши. Үз мәнфәгатебезне кайгырту безнең бурычыбыз иде, ләкин ул кадәрен уйлый алмадык. Бүгенге көндә инде мәмләкәтебез дә безнең кулда түгел. Ходай бер мәмләкәтне дә иясез калдырмый, әлбәттә, милләт үзе хуҗа булырга теләмәсә, башкага бирә. Без үзебез хуҗа була алмадык, Ходай японнарга бирде.

– Японнарның идарәләре тәртиплерәк кебек күренә. Элек золым күп булгандыр.

– Кеше, үз атасыннан күпме генә золым күрсә дә, газап хис итми, җисеме белән җәберләнсә дә, калебе тыныч була. Әгәр читтән кыен күрсә, канун даирәсендә – хәтта хаклы буларак – кечкенә генә бер җәзага тартылса да, чырыйлап кычкыра. Бу бик табигый хәл, чөнки атаның мөгамәләсе, синең кыска акылың буенча, күпме генә золым кебек күренсә дә, чынбарлыкта золым түгел. Хәтта чынбарлыкта да золым булган очракта да, атаның гаилә тәрбиясе турындагы яхшы нияте ул золымны җиңеләйтә һәм сау акыллы кеше аңа золым итеп карамый, чөнки гаилә мәнфәгатен уйлап башкарылган. Шулай булгач, японнар күпме генә гадел булсалар да, аларның мөгамәләсе безнең өчен барыбер җәбер һәм золым булып тоела, чөнки бу – аларның файдасы һәм мәнфәгате өчен башкарылган гаделлек. Ә менә Корея хөкүмәте вакытында милләт табигый тормышы белән яши иде, кешесе хөр һәм азат иде. Бернинди басым юк, мал-мөлкәте булса, хөкүмәткә ни дә булса бирә, булмаса, берни бирми һәм җаваплы да түгел иде. Һәр кеше үзен үз өендә итеп тоя, үз мал-мөлкәтенә үзе хуҗа иде. Һичьюгы вөҗданы тыныч һәм калебе канәгать иде. Хәзер исә алай түгел, бар да үз йортында чит әмир күрә, берәү дә үз йортына үзе хуҗа, тапканы үзенә түгел. Без тырышып-тырмашып табабыз, алар, өлешкә кереп: «Яртысын син аша, яртысын миңа бир», – диләр. Әлбәттә, тормыш җиңеләйде, бар кешенең кулында акча бар, менә бер айлык юлны 2-3

көндә үтә алабыз. Болар да мөһим нәрсәләр, тик болар барысы да күз буяу өчен генә. Әгәр минем йөрәгем елый икән, йөзем көлсә ни дә, көлмәсә ни – һич әһәмияте юк...

– Шулайдыр, ләкин мин японнарны бик яхшы һәм мәрхәмәтле итеп күрәм. Барган җирләремдә игътибар иттем: авылларыгыздагы түрәләр шактый кешечә мөгамәлә күрсәтәләр, корея кешеләренә мыскыллап карамыйлар.

– Әйе, сезнең мәмләкәттәге кебек үк түгел, ләкин шулай да корея кешесе өчен Владивостокта руслардан күргән кимсетелү Сеулда японнардан күргән ихтирамнан яхшырак. Анда минем вөҗданым газап чикми, чөнки кимсетүче үз өендә, мин исә – килмешәк. Бераз гына тоя һәм уйлый белгәннәр өчен мондагысы түзәрлек кайгы түгел, тик ни чара, адәм баласы түзә икән.

– Сез, укымадым, дисез, тик бу дәрәҗәдә фикер йөртә алуыгызга күрә, Сез, һичшиксез, укыган булырга тиеш.

– Бүгенге көндә без, японнар аркасында, университетларда да укыдык хәтта. Японнарның һәр адымы, һәр мөгамәләсе – безнең өчен зур сабак. Тик бу сабакны, кызганыч ки, форсатлар кулдан ычкынганнан соң гына алдык һәм алабыз. Ватан башка берәүнең мал-мөлкәтенә әйләнгәннән соң гына бу хис-тойгыларга ия булдык.

– Корея халкы арасында Сезнең кебек фикер йөртә торган кешеләр булганда, һичьюгы кайбер хокукларыгызны саклап кала алырсыз дип уйлыйм.

– Юк шул, болар үтте инде. Вакытында уйламагач, хәзер күпме генә баш ватсалар да, файдасыз, чөнки кулда берни калмады. Бүре бәрәнне бер эләктерсә, тешләреннән ычкындырмый. Бәрән күпме генә ачыргаланып мәэлдәсә дә, бүре инде аны барыбер ботарлап тәгамләячәк. Көтүче дә шулай: бәрәнне кулыннан бер ычкындырдымы, бүтән кайтарып ала алмаячак. Көтүче, үз җанын коткарыр өчен, хәтта көтү-көтү сарык хайванын фида итә, итте дә. Тик үзен дә коткарып кала алмаячак.

Шул рәвешле, кореялы юлдашым белән сөйләшә-сөйләшә вакыт үткәрәбез, мин шул ук вакытта карандаш белән кайбер нәрсәләрне язгалап та куям.

Юлчыларның күпчелеге кытайлар иде һәм алар арасында да русча белүчеләр бар икән. Безнең сөйләшкәннәребезгә колак салалар. Поезд туктады. Юлдашым: «Бу Кей Жийо дигән җир, ярты сәгатьтән Ней Жийо дигән җиргә барып җитәчәкбез. Анысы зур шәһәр, теләсәгез, бераз йөреп килербез. Поезд бер сәгать тә ун минут торачак. Шәһәргә барсак, чәй дә эчәрбез», – диде.

Нәкъ ярты сәгатьтән Ней Жийо шәһәренә килеп җиттек. Юлдашым белән шәһәргә чыгарга җыенабыз, мин:

– Әйберләребез шулай калса, зыян булмасмы? – дип сорадым.

– Безнең корея халкы урлашуның ни икәнен дә белми, борчылмагыз.

– Японнар да белмиләр, шулай түгелме?

– Японнарның вазыйфалары – саклау. Вазыйфаларын үтәмичә, киресен эшләмәсләр бит инде. Гомумән, Япониядә ышанычлылык бөтен. Тик андагы ышанычлылык белән бездәге ышанычлылык арасында шактый аерма бар. Бездә урлашу зур вөҗдансызлык булып санала. Бер кеше әгәр берәр нәрсә урласа, ул туган-тумачасы белән арасын өзәргә тиеш. Япониядә исә хөкүмәтнең җәзага тартуыннан куркып, караклыктан ерак торалар, ә болай табигатьләрендә урлашу юк түгел. Караклык өчен бик авыр җәза каралган кануннары бар. Әлбәттә, милләт тә шактый тәрбияле.

Без шәһәргә киттек. Бу кечкенә генә шәһәр булса да, японнар бик яхшы төзекләндергәннәр. Электр трамвайлары, телефоннар, гаҗәеп төзек урамнар, базарлар. Трамвай белән шәһәрне бер әйләнеп чыктык. Аннары бер япон өендә чәй эчеп алдык. Поездга әйләнеп кайтканда, безнең вагон ишек төбендә бер полиция кешесе тора иде, безгә: «Әйберләрегезне бер кат күздән кичерегез әле», – диде. Карадык, әйберләребез бар да урынында, ничек калдырган булсак, шулай торалар иде.

Юлдашымнан:

– Сезнең исемегез ничек? – дип сорадым.

– Ван-Бин-Йу.

– Нәрсәне аңлата, мәгънәсе бармы?

– Киң күңеллелекне аңлата, дияргә мөмкин. Тик бу төгәл түгел, Сезгә русчага башка төрле тәрҗемә итә генә алмыйм. Ул бик мәгънәле сүз. Аны белдерә торган иероглиф та бик матур.

– Корея халкының язуы белән японнарның язуы арасында аерма зурмы?

– Аерма бик зур, ләкин японнарның язуын корея кешесе укып аңлый алган кебек, корея язуын да японнар укып аңлый ала. Тик бер-берләренең әдәбиятын аңлап бәяли алмыйлар. Мәсәлән, бер корея кешесенең язганын башка бер корея кешесе рәхәтләнеп укый, мәгънәсен аңлаудан тыш, укыганнарыннан ләззәт тә ала. Бер япон кешесе дә бу язылганнарны укый ала, ләкин ләззәт ала алмый. Безнең язуыбыз тагын да борынгырак. Японнар соңыннан шактый иероглиф өстәгәннәр, бераз үзгәрткәннәр. Безнеке исә, моннан меңел элек ничек булса, бүгенге көндә дә шулай кулланыла, үзгәрмәгән.

– Корея халкы арасында укый-яза белә торган кешеләр күпме?

– Бик күп түгел, ләкин руслардагы кебек тә түгел. Безнең һәр авылыбызда бер мәктәп һәм бер укытучы бар. Әмма безнең балаларыбыз япон балалары кебек 3-4 ел эчендә укып-яза башламыйлар. Укып-яза башлар өчен ун ел кирәк.

Ул арада поезд Ней Жийо шәһәреннән кузгалып китеп барды. Көн бик матур иде, тәрәзәдән карап бара-бара юл үтәбез. Бер сәгатьтән Какузанга килеп җиттек.

– Бу җирләр тоташ Корея мәмләкәте, шулаймы? – дидем.

– Бүген кичкә кадәр үтәсе җирләр Корея җирләре иде, ләкин хәзер Япониянең Корея өлкәсе була инде. Хотинга кадәр гел Япония, әле тагын өч көн барасы, – дип көлде.

Биредә җир өсте гаҗәеп матур иде. Иген чәчелгән кыр-басулар сөйләп-аңлатып бетереп булмаслык күп. Кая карама, хезмәт белән мәшгуль японнар күренә. Юлдашым:

– Сез игътибар итәсезме? Боларның эше бөтенләй башка төрле. Какузаннан Сеулга кадәрге иген кырлары корея халкыныкы иде. Какузаннан алып бу җирләргә кадәргеләре гел японнарныкы, безнекеләрнекенә һич охшамаган. Безнекеләрдә җир табигый хәлендә. Биредә исә җир тәмам эшкәртелгән, кеше кулы тимәгән бер таш кисәге дә таба алмассың. Әгәр җир кешеләр файдалансын өчен билгеләнгән булса, аны японнарга бирергә кирәк, чөнки алар чын-чынлап файдалана беләләр. Безнең корея халкының кулында булганда, ул тауларда кеше аяк басмаган җирләр бик күп иде. Болар инде тау өстендә буш торган җир калдырмадылар, ул гынамы соң, җир астыннан да чыгарып булган бөтен нәрсәне чыгарып бетерделәр. Бу тауларда, кырмыска көтүе ке-

бек, японнар чабыша. Аһ, безнекеләр әле һаман күзләрен ача алмыйлар һәм ачу ихтималы да юк. Бөтен авыр хезмәтләрдә тагын да шул безнекеләрне эшләтәләр, ә табыш японнарга була.

– Заман таләп иткән белемгә һәм тормыш итү юлларына ирешмичә торып, яшәү була алмый. Бу мал-мөлкәтне японнардан кире алу өчен, аз дигәндә, шул японнар кадәр хезмәт куярга кирәк. Мәмләкәтне җаһиллек белән саклап калып булмый.

– Мәмләкәтне кире алу юк та юк инде, һич булмаса, кеше хокукларыбызны саклап кала алсак, яшәешебез беркадәр тәэмин ителер иде. Инде бөтен милләт юкка чыгу алдында тора, чөнки эчү күбәйде. Болай булса, буыннар юкка чыгачак, икенче яктан әле сифилис авыруы да керде. Христианлашкан корея кешеләре дучар булган бу ике афәт елдан-ел гына түгел, айдан-ай күбәя, җәелә бара. Мәмләкәтнең кай җиренә карама, кем ач – христиан ач. Милләт бер артка киттеме, фикер йөртү сәләте бөтенләй дә үлә икән, хисе дә калмый, намусы да. Хәлебезне сөйләп аңлатсам, ышанасыгыз килмәс. Япон кешесе, гади эшче генә булса да, безнең иң зур министрларыбыз белән чагыштырырлык түгел, үзен әфәнде итеп хис итә, үзен әфәнде кебек тота. Корея кешеләренә бу бөтенләй тәэсир итми. Хәтта шулай булырга тиеш дигәндәй кабул итәләр, үзләрен ким санап, әфәндесенә караган кебек карыйлар. Бүген мин корея милләте турында «рухсыз гәүдә» диюдән башка сүз таба алмыйм. Нигъмәт үз кулыбызда булганда, кыйммәтен белмәдек, бүгенге көндә бичара хәленә төштек, ләкин үзебез шуны белмибез.

– Сез ник бу кадәр өметсезләнәсез һәм кайгырасыз? Мин ул дәрәҗәдә үк өметсез булырлык хәл күрмим. Корея милләтенә хакимиятен кире кайтару өчен берничә ел тырышып, мәгарифне алга җибәрергә кирәк, аннары форсат туугa, кулга төшерергә мөмкин булачак. Безнең татарлар инде менә дүрт йөз ел русларның әсире булып яшиләр, шулай булса да, өметләрен өзмиләр. Русларның золымы белән чагыштырганда, японнардагы хөррият тә исәпкә алынса, сезне барыбер бәхетлерәк дип саныйм. Японнар алмаган булса, сезне руслар басып алыр иде. Ул очракта тагын да начаррак булыр иде, шулай түгелме?

– Билгеле бер дәрәҗәдә шулай, әмма безнең өчен русларның басып алуы яхшырак та булыр иде, бәлки. Беренчедән, безгә Русиядән күчеп килүче булмас, булса да, бик аз булыр иде. Аннары руслар, залим милләт булсалар да, акырырлар-бакырырлар, ләкин кешенең миллиятенә кагылмаслар. Тагын бик күп яклардан русларның басып алуын өстен күрергә мөмкин булыр иде. Бары тик бер ягы бар – әхлак бозыклыгы. Менә шул бик начар. Бу яктан караганда, безнең өчен японнарның басып алуы яхшырак булып чыга. Бу инде хәзердән үк күренә. Японнар белән аралашкан, якынайган кешеләр әхлакларын да төзәтәләр. Сәүдә һәм башка шундыйларда урынын тапкан кешеләребез бар. Әйе, ул яктан шикаять итәрлек тә, яманларлык та түгел.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

«Котадгу белек» – бәхетле итүче белем

Фирдүс Фәтхелисламов, философия фәннәре кандидаты



Борынгы төрки әдәбиятның иң танылган үрнәкләреннән берсе булган «Котадгу белек» әсәрен Караханлы дәүләте чорында Йосыф Баласагунлы язган. Бу эшне ул 1069 елда Баласагунлы шәһәрендә башлап, 1070 елда Кашгарда тәмамлаган. Галим үз әсәрен Караханлы хөкемдары Табгач Бугра Кара ханга тәкъдим иткән. Хөкемдар, язманы ошатып, авторына «хас хаҗиб» дигән дәрәҗә биргән. Шуңа күрә Йосыф Баласагунлыны кайвакыт Йосыф Хас Хаҗиб дип тә атыйлар. Биредәге «хаҗиб» сүзе гарәпчәдә хан сарайларындагы хөрмәтле дәрәҗә исемен белдерә, ә «хас» («хасс») сүзе ике мәгънәгә ия: 1) сизүче, тоючы; 2) бер нәрсәгә, бер эшкә билгеләнгән.

«Котадгу белек»нең бүгенге көнебезгә килеп ирешкән өч нөсхәсе бар: Вена, Каһирә вә Фәргәнә нөсхәләре. Әфганстанның Һерат шәһәрендә табылганы уйгыр язуы белән язылган. Башта ул Истанбулга эләгә, аннан аны танылган та-

рихчы Һаммер, сатып алып, Венага китерә һәм дәүләт китапханәсенә тапшыра. Маҗар галиме Һ.Вамбери бу нөсхәнең бер өлешен 1870 елда алманчага тәрҗемәсе белән нәшер итә. Моннан соң Каһирәдә «Котадгу белек»нең гарәп хәрефләре белән язылган икенче бер экземпляры табыла. Мәшһүр тюрколог Радлов, Вена һәм Каһирә нөсхәләрен чагыштырып, 1891 елда әсәрнең тагын да камил текстын, алман теленә дә тәрҗемә итеп бастыра. Узган гасырда Көнбатыш Төркестанда, Фәрганәдә ядкярнең өченче нөсхәсе табыла. Бүген ул Ташкентта саклана.

«Котадгу белек» – борынгы төркиләрнең әхлак, хокук вә дәүләт идарәсе турындагы бик бай чыганак. Ул, алманчадан гайре, күп кенә башка телләргә дә тәрҗемә ителгән һәм бүген дә галимнәр тарафыннан да, укыту вә тәрбия эшендә дә еш кулланыла. Үлмәс әсәрнең әһәмиятен иseme үк күрсәтеп тора: котадгу белек – котлы, ягъни бәхетле итүче белем. Бәхетле булу җиңел түгеллеген беләбез, дөньяда бәхетсез инсаннар бик күп. Бәхетле булу ул – үзе бер гыйлем, үзе бер сәнгатьтер. «Котадгу белек» бәхет гыйлемен бирә, бәхет сәнгатенә өйрәтә. Китапның төп темасы – гадел дәүләт идарәсе. Дәүләттә халык арасындагы мөнәсәбәтләрнең нинди булырга тиешлеге үтемле тел белән аңлатылган. Фәлсәфи бер система кору юлын сайлаган язучы, сәгадәтнең ничек төзелүен аңлатып, «идеаль дәүләт», «идеаль җәмгыять» һәм «идеаль кеше» типларын тасвирлаган. Әсәрдә төркиләрнең үз характерына, үз милли фәлсәфәләренә тугрылыклы булып яшәве таләп ителүен күрәбез.

«Котадгу белек» – әдәбиятыбыздагы тәүге сәясәтнамәдер. Әлбәттә, анда гарәп һәм фарсы әдәбиятларының йогынтысы да сизелә, ләкин бу әсәр – оригиналь хезмәт. Садри Максуди Арсал сүзләре белән әйтсәк, «Котадгу белек» һәрьяктан караганда да түрк әсәре» (2, 97 бит). Биредә «түрк» кәлимәсенең мәгънәсе русчаның «тюрок» сүзенең эчтәлегенә туры килә. Әлеге атама элек татар телендә дә кулланылган, әмма Сталин чорында тыелган һәм татар әдәбиятында түрк кабиләләрен – «төркиләр», ә түрк телен «төрки тел» дип атау гадәткә кергән. «Котадгу белек» бу телнең үтемле һәм гади бер шәкелдә кулланылуы, түркләрнең тормыш фәлсәфәләрен төрле ракурслардан чагылдыруы ягыннан да искиткеч зур кыйммәткә ия.

Нәсыйхәтнамә төреннән булган, ягъни үгет бирүче әлеге әсәр акыл бирү үзенчәлегенә ия. Ләкин ул әхлак сабагы биргән коры бер нәсыйхәт китабы да түгел. «Котадгу белек» шул дәвердәге башка әсәрләрдән үзенең гаҗәп күпкырлылыгы белән аерылып тора. Бу аның тирән фәлсәфи эчтәлегеннән килә. Әйткәнебезчә, автор төркиләрнең яшәү фәлсәфәсен аңлата. Ә фәлсәфәне тикмәгә генә фәннәрнең фәне димиләр. Әсәрдә сәяси, хокукый, икътисадый һәм төрле башка мәсьәләләр дә карала.

Еш кына «Котадгу белек»не, аның оригинальлеген инкяр итеп, ислам фәлсәфәсенең бер мисалы буларак танытырга тырышалар. Әмма инде телгә алынган мәшһүр галим, милләттәшебез Садри Максуди Арсал үзенең «Түрк тарихы вә хокук» исемле хезмәтендә Йосыф Баласагунлы әсәре турында: *«Бу әсәрдә исламият тәэсире бик сай, өстән-өстән генә»,* – дип яза (2, 98 бит). Садри Максуди ул вакытта Шәркый Төркестан халкына, ислам диненнән башка, хәтта аннан күбрәк тә, будда диненең йогынтысы булуын аңлата, әсәрдә Конфуций фикерләренең тәэсире тоемлануын да күрсәтә. Әлбәттә, авторга читләрнең фикерләре дә тәэсир иткәндер, ләкин алар барысы да бу даһи әсәрдә сизелер-сизелмәс күләмдә генә чагылган һәм язучының рухыннан бөркелеп торган төрки

балкыш эченә сеңгән. Дөрестән дә, «Котадгу белек»нең әдәби, фикри материалы тулысынча төрк тормышыннан алынган. Автор кулланган күпсанлы мәкальләр һәм әйтемнәр – төрки бабаларыбыз сүзләре, фикерне куәтләүче шигырьләр – төрк шагыйрьләренеке. Әсәрнең каһарманнары телендә чагылган фикерләр, хәят мантыйгы, тормышка караш – болар барысы да төркләргә генә хас.

«Котадгу белек»нең максаты ул чорда яшәгән төркиләрнең әхлак, хокук вә дәүләт идарәсе өлкәләрендәге традицион карашларын тасвирлап, киләчәк нәселләргә дә аңлатырга тырышуда гына түгел, ә бәлки, ханнарга һәм башка хакимнәргә дә нәсыйхәт бирүдер, гаделлектән, милли карашлар вә гореф-гадәтләрдән тайпылмаска чакырудыр.

Әсәр шигъри хикәя рәвешендә язылган. Бер үк вакытта аңа сәхнә әсәре дип тә карарга мөмкин, чөнки ул каршылыклы диалоглар шәкелендә әзерләнгән. Геройларның сүзләрендә, аларның характерларында билгеле карашларны чагылдыручы символик үзенчәлек күренә. Әдип үзе тасвирлаган идеал типларны кайбер аллегорик төшенчәләр белән символлаштыра.

Әсәрнең төп дүрт каһарманы бар: Күн Тогду, Ай Толду, Өгдүлмүш һәм Одгурмуш. Күрүебезчә, символизм хәтта исемнәрдә үк чагыла: көн тууы яисә ай тулуы белән чагыштырулар – тирән мәгънәле чагыштырулар. Бу каһарманнардан һәрберсе билгеле булган бер яки берничә әхлакый сыйфат һәм хокукый нигезне гәүдәләндерә. Күн Тогду – хан. Ул – канун һәм гадәләт символы. Ай Толду – вәзир. Ул дәүләтне, дәүләт идарәсен, сәяси хакимиятне символлаштыра. Ай Толдуның углы Өгдүлмүш образы акылның, гыйлемнең, тырышлыкның әһәмиятен күрсәтә. Соңрак Өгдүлмүш үзе атасы урынына вәзир булып кала. Одгурмуш – дөнья кудан һәм кешеләрдән ераклашып, тауларда яшәүче бер зат, вәзирнең туганы. «Одгурмуш» сүзе борынгы бабаларыбыз телендә уянганны аңлата. Кеше, уянып, яктылык күрә бит. Әсәрдәге Одгурмуш – ваемсызлыктан уянуны күрсәтүче тип. Китапның геройлары халыкның бәхеткә ирешүенең төп шартларын аңлаталар, моның катлаулы юлларын күрсәтәләр.

«Котадгу белек» күркәм бер калага охшаган. Ялтырап торган урамнарын аның изге бәетләрендә күрәбез. Аларның кайсы Тәңре боерыгы, кайсы кисәтү, кайсы үгет, кайсы өндәү, ә кайсы тыюдыр, – дип яза төрек галиме Агоп Дилачар. – *«Котадгу белек» безнең өчен, чыннан да, чиксез горурлык, бетмәс бер эчке (рухи) көч чишмәсе. Йосыф Баласагунлының хезмәте бездә горурлык тойгысы уятты»* (3, 156 бит).

Әдәбият:

1. Yusuf Has Hacib; Kutadgu Bilig – II çeviri: Reşid Rahmeti ARAT, Tűrk Tarih Kurumu Yayınları, 2. baskı, Ankara, 1974.

2. Sadri Maksudi Arsal; Tűrk Tarihi ve Hukuk, Istanbul, 1947.

3. Agop Dilaçar; 900.Yıldőnűmű Dolaysıyla Kutadgu Bilig Incelemesi, TDK Yayınları, 3. baskı, Ankara, 1995. ■

«Тарихын белгән халык – теп-тере бер милләттер»

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Ләбиб Каран карашынча, миллилекне саклауның, дәвам итүнең нигезен милли тәрбия, үз халкыңның тарихын белү тәшкил итә. Ул бу фикерне кат-кат, төрле вариацияләрдә искә төшерә. Шунысы мөһим: милли тарих төшенчәсенә ул киң мәгънәдә, үз кавеменең яшәеш-тереклеген төрле яктан, комплекслы өйрәнү-яктырту рәвешендә карый. Аңа без күнеккән саф тарихи, иҗтимагый вакыйга-хәлләрне генә түгел, милләтнең яшәү рәвешен, тереклек-көнкүрешен, этнографиясен, телен, сүз сәнгатен һәм, гомумән, рухи кыйммәтләрен дә кертә. Шуңа күрә аның язганнары да шактый үтемле, кызыклы чыга. Еш кына ул тарихны шигъри тел ярдәмендә дә яктырта. Мондый алым укучы, тыңлаучы күңелен, зиһенен ныграк кузгата, баета.

Алдарак без Ләбиб Каранның ике китабына махсус тукталып китәчәгебезне искәрткән идек. Шул вәгъдәгә тугры калып, хәзер шулар турында, мәкаләнең күләм ягыннан бик чикләнелгәнен күздә тотып, бераз гына махсус сүз куертып алыйк.

«Татарларның төп чыгышы» китабының эчтәлеге чын мәгънәсендә аның исеменә туры килә. Анда татарның этногенетик тарихы, яшәеше төрле яктан шактый тулы яктыртыла. Китапның керешендә («Баш сүзе»ндә) автор үзенең шактый бурычларын, бу хезмәтенә нинди вазыйфалар йөкләнүен бик кыска, әмма үтемле, ачык итеп бәян итә. Төп өлештәге бүлекләрнең исемнәрен атап китү дә монографиянең эчтәлек-табигатен билгеле бер дәрәҗәдә күзалларга булыша: «Татарларның төп чыгышы», «Татар милләте кайчаннан бирле бар?», «Аурупа һуннары турысында», «Угырлар, болгарлар һәм хәзәрләр», «Фин-угыр сүзе турында төшенчәләр», «Татарлар – Аурупаның мәдәни бер милләтедер», «Татарча тел турында», «Татарлар кай җирләрдә утыралар?», «Татарларда төрекчелек», «Татарлар һичбер вакыт динсез мәҗүси булмаганнар», «Дөнья мәдәни милләтләренә карата», «Олуг төрек милләтендән һәм хөкүмәтендән зур үтенеч», «Татар хатыннарына киңәш һәм аларга үгетләр». Китап «Соңгы сүз» һәм библиографик исемлекне бирү белән тәгәлләнә. Монографиядә бүлек исемнәре рәвешендә чыгарылмаган башка бик күп мәсьәләләр дә бар. Файдаланылган хезмәтләр арасында чит ил, урыс авторларының (L.Passony, M.Duhson, Н.Катанов, Ş.Günaltay...) китаплары белән бергә, Ш.Мәрҗани, Й.Акчура, З.Вәлиди, А.Баттал-Таймас кебек татар галимнәренең дә язмалары күрсәтелгән.

Ләбиб Каран монографиясенең эчтәлеген кыскача гына сөйләү дә бик кыен. Моннан котылуның төп юлы – аны шәхсән үзең уку, тулысы белән тәмам үзеңә танышу. Әмма бу да хәзергә бик мөмкин түгел [Бәлкем, алдагы көннәрдә берәр игелекле затыбыз ул китапны гамәлдәге язуыбызга күчереп, тиешле шәрех-аңлатмалар белән бастырып чыгарыр?!]

1962 елгы Истанбул басмасының төп рухы, асыл мәгънәсе халкыбызның озын-озак тарихлы булуын, данлы да, фаҗигале дә юл үтүен, кешелек яшәешендә тирән эз калдыруын яктыртудан гыйбарәт. Без фәкыйрегез 2018 елның декабрендә Пе-

Ахыры. Башы журналның 3 нче (2021) санында.

«Süyümbike Kültür Cemgiyeti»
ceyimlerinden : No. 6

TATARLARNINĞ TÜPÇIGIŞI

Yazuçısı :
Dr. A. Lebib Karan

Basılgan ciri : AHMED SAİD MATBAASI
İSTANBUL — 1962

кин университетындагы Ч.Айтматовның тууына 90 ел тулуга багышланган зур халыкара конференциядә катнашкан иде. Пленар утырышта доклад сөйләп, бераздан тәнәфескә чykkаннан соң, минем янга Кытайның бер күренекле профессоры тәрҗемәче һәм берничә хезмәттәше белән килде, докладтан гомумән канәгать булуын әйтте дә, сүзен алга таба болай дәвам итте: «Сез «төрки-татар» гыйбарәсен кулланасыз, ә бу бит тарихи яктан бөтенләй дөрес түгел. Төркиләр – соңгырак дәвердә яшәгән кавем. Аларның этнонимы да бишенче гасырларда гына телгә алына башлый. Ә татарлар – яңа эрага кадәр үк безнең әби-бабаларыбыз белән аралашып яшәгән бөек халык (тәрҗемәче бу сүзне урысча, «великий», дип берничә мәртәбә кабатлады – **Х.М.**). Шуңа күрә «төрки-татар» дип түгел, ә «татар» (һичьюгында – татар-төрки) дип авыз тутырып әйтергә кирәк. Артык тыйнакланасыз. Үзегезнең бөек татар халкының бер вәкиле, дәвамчысы булуыгызны һәрчак истә тотыгыз». Чыннан да, борынгы Кытай, өлешчә Һиндстан чыганакларында татарның бик борынгы, абруйлы, күпсанлы кавем булуы кат-кат искәртелә. Бу хакта, гәрчә сирәгрәк булса да, соңгырак дәвернең каләм әһелләре дә яза. Ләбиб Каран – нәкъ әнә шул тарихи хакыйкатьнең бер тарафдары. Аның тирәнтен инануынча, «татар милләте» – Евразиянең төп һәм «иң иске» халыкларыннан берсе һәм иң «зурысы». «Һун», «могол», «төрек» (төрки мәгънәсендә)... – татар нигезендә соңрак оешкан кавемнәр. Ләбиб Каран фикеренчә, мөселман дөньясы татарның соңрак тарихи мәйданга чыккан этник төркемнәре – төркиләр белән ныграк аралаша. Шуңа нисбәттән, төрки этнонимы да киң таралыш таба. Шушы нигездә, соңрак оешкан «тюркология» фәне дә татарлыкны оныттыруга үзеннән зур өлеш кертә. Ләбиб Каран «тюркология»не тәнкыйтьләп, аның урынына «татарология» атамасының урынлы булуын да искәртә. Автор халкыбызның соңгы дәвердәге авыр хәле, хокуксызлыгы турында ачынып яза. Әмма өметсезлеккә бирелмәскә, хәрәкәт итәргә, көрәшергә чакыра. Китапның «Соңгы сүз»ендәге иң ахыргы абзац та бу яктан бик тә мәгънәле, бик тә эчтәлекле. «Төркиядә, Финляндиядә, Япониядә һәм башка өлкәләрдә, – диелә анда, – үз рәхәтләренә кавышып, Рәчәйгә һәм урысларга тел тидерүдән куркып, үз милләтендән башка бер милләткә күчеп, рәхәтләренә кавышкан татарлар арасында, бигрәк тә укып нурланган һәм чын милләтчелекнең мәгънәсене аңлар дәрәҗәдә тырышкан яшь **Татарлар** да чыгачактыр! Без алардан да өметсез түгелбез! Без чын иманлы **Татарлардан** булыйк, әлхәмдүлилләһ, мөселманбыз! Мөселманнарның чын иман иткән нәрсәләрендән берсе – үлгәннән соң терелүдер. Без ул үлгән Алтын Урда өлкәсенең беркөн тереләчәген, Идел-Уралда без Татарстан өлкәсенең корылачагына иманабыз! Чөнки өлкәләр (илләр. – **Х.М.**) үләр, ләкин милләтләр үлмәс, яшәрләр!» (94 б.).

Укучылар инде игътибар иткәндер: Ләбиб Каран шактый тәнкыйди рухлы әдип. Гомумтатар мәнфәгатьләрен күздә тотып, ул үзе өчен бик тә газиз-якын булган милләтен, аның Рәшит Ибраһимов, Садрый Максуди, Гаяз Исхакый кебек күренекле вәкилләрен дә урыны белән тәнкыйть утына ала. [Мәсәлән, төрекчелек тарафдары Рәшит казыйны «Татарларга баз казучы» дип атый. – 35 б.]. Ул аеруча милләт исемен алыштыручыларга, бу юнәлештә эш-гамәл кылучыларга кискен мөнәсәбәттә. Автор андыйларны халыкны «адаштыручылар, ахмаклар» дип атый. Аның фикеренчә, «милли исемләр, тарихи исемләр мөкаддәстер; аларны үзгәртү бөтен милли эшләрнең бозылуына» китерә (90 б.). Ләбиб Каранның мондый карашлары бүгенге көнебезгә дә бик аваздаш. Чөнки әле безнең арабызда татар атамасыннан баш тартып, башка этнонимны алырга чакыручылар да бар.

Милләтенең соңгы дәвердәге аянычлы, авыр язмышына йөрәге әрнегән, аны ирекле, бәхетле итү өчен бәргәләнгән автор, мөһаҗирлектәге кайбер башка каләм әһелләре кебек, Рәчәй, урыс, Мәскәү, «большевизм» хакимиятләренә, Төркиядәге аерым хәл-вакыйгаларга каршы каты-каты гына тәнкыйть укларын ата, хәтта урыны белән тиешле әдәп-әхлак кысаларыннан чыгып та киткәли. Әлбәттә, без аның бу төр кискенлекләрен, таякны артык бөгеп җибәрүләрен кабул итә алмыйбыз, аны тәнкыйтьлибез дә.

Гадәттә, адәм баласының эш-гамәле, гәрчә ул төрле тармакларда хәрәкәт итсә дә, бербөтен системаның аерым өлешләре – компонентлары кебек, үзара бәйләнешле була. Әхмәд Ләбиб язмалары да аннан чыгарма түгел. Алар бер-берсе белән шактый керешкән, хәтта аерым кабатлану-вариацияләр дә бар. Бу аеруча авторның без сүз йөртә торган ике китабы өчен хас. Аларның һәр икесенең дә үзәгендә татар тематикасы, милләтнең тарихы, язмышы, бүгенге хәле, аның борчу-кайгылары, шатлык-өметләре, авторның киләчәк хакында уйланулары, яну-көюләре. Төп аермаларның иң зурысы шул: беренчесе – чәчмә, икенчесе – шигъри телдә.

Ләбиб Каранның 1959 елгы җыентыгы «Яшь вакытымның җырлары» дип исемләнсә дә, андагы шигырьләр бу чор белән генә чикләнми. Ул, нигездә, 1916-1952 нче елларда иҗат ителгән әсәрләрне үз эченә ала. Алар белән танышу шуны күрсәтә: автор татар язмышы, милли-азатлык мәсьәләләре белән «яшь вакытында» ук шөгыльләнә башлаган икән. Бу тематика аның берничә дистә елга сузылган шигъри иҗатында әйдәп баручы төп проблема – лейтмотив булып бара. Әхмәд Ләбиб Каранның «Татарларның төп чыгышы» монографиясе шактый дәрәҗәдә авторның моңа кадәр язылган шигъри әсәрләренең, алардагы уй-кичерешләрнең прозаик төстәге бер дәвам ителеше, шәкелләшүе, гомумиләштерелүе дә булып тора. «Бу китап, гомумән, фәнни хезмәт. Әмма анда авторның шагыйрьлеге хезмәтнең телстилендә, эчтәлегендә, вакыйга-хәлләрнең бәян ителешендә, проблемаларның яктыртылышында шактый сизелә. Мәсәлән, «Татар хатыннарына киңәш һәм үгетләр» дип исемләнгән соңгы бүлек үзенең уй-кичерешләргә байлыгы, эмоциональ аһәңе белән лирик-публицистик яңгырашлы поэманы, ялкынлы мөрәҗәгать-чыгышны хәтерләтә. Аның тәүге юллары ук укучы-тыңлаучының күңел дөньясын кузгатырлык: «Бөтен тоткын милләтләрнең бер генә теләге бардыр: ул да булса – шул тоткынлыктан котылу, котылу чараларын эзләү, бервакыт һәм һәрвакыт котылырга тырышудыр. Бу тырышу – ул тоткын милләтнең иренә, хатынына төшкән иң зур милли бурычыдыр. Бу бурычның күбрәк өлеше хатыннарга төшәдер... Чөнки хатыннар ул милләтнең анасы булалар...» (89 б.).

«Яшь вакытым җырлары» җыентыгында барлыгы 84 шигырь урнаштырылган. Күләм ягыннан алар төрле: икеюллык (фәрд), дүртьюллыклар белән беррәттән, шактый күләмлеләре дә бар. Мәсәлән, «Татар төректән бөектер», «Безнең умарталык» әсәрләре берничә битне алып тора. Автор үз тезмәләренең барысын да «җырлар» дип саный. Әмма ул чынлыкта шигырь атамасына туры килә. Аларның күпчелеге традицион дүртьюллык строфалар белән язылган. Автор, нигездә, 11-11, 15-15 иҗекле үлчәмнәр белән эш итә. Җыентыктагы шигырьләр биш тематик төркемгә бүлеп бирелгән: «Милли, сәяси мәгънәдәге жырлар» (25); «Матур язулар мәгънәсендә көзгеләндерү җырлары» (7), «Дини һәм фәлсәфи...» (19), «Сөю һәм ярату» (18); «Хикмәтле уен-көлке җырлары» (15).

Әмма бүлек атамаларына тәмам туры килеп җитмәгән парчалар да бар. «Татарның төп чыгышы» китабындагы бүлек атамалары кебек, биредәге шигырьләрнең исемнәре («Татар берлеге», «Йорт берлеге», «Татар», «Туктамыш һәм Аксак Тимер»,

«Татарның көче»...) аларның идея-тематикасын, эчтәлеген һәм жанр табигатен, авторның рухи халәтен, әдәби дөньясын шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Китапта робагый, мәдхия, марш, табигать һәм мәхәббәт лирикасы, юмор, хикмәтле сүз һәм кайбер башка жанр үрнәкләре бар. Багышламалардан аеруча 1948 елда иҗат ителгән «Шагыйрь Габдулла Тукайга» мәдхиясе игътибарга лаек. Автор бу затка карата бинигаһая зур ихтирам-хөрмәтен белдерә, аның фидакярлегенә, кылган гамәлләренең игелегенә соклана. «Тукай, – ди ул, – безнең терәк, йөрәк».

Җыентыктагы ике мәрсия Мөхәррәм Фәйзи Тугайга (?-1948) багышланган (шәхсән, бу милләттәшебез миңа таныш түгел. – **Х.М.**). Автор аны «сөекле остазыбыз», милләт өчен янып-көюче дип атый:

«... Төрек дөньясында яшәдең ашап торыр өчен,
Татар дөньясын яшәттең иректе көн күрер өчен...» (27 б.)

Җыентыкта мәхәббәт лирикасының матур гына үрнәкләре бар. Бу яктан бигрәк тә «Соклану» (1918), «Сөю» (1947) һәм кайбер башка парчалары хис-кичерешләрнең тәэсирле яңгырашы, лирик каһарманның рухи халәтен гәүдәләндерүе белән кызыклы гына:

«...Матур гына бер елмаеп, карап куйсаң үземә,
Өстемә нур тулкыннары шундук килеп түгелә,
Өстем-башым, эчем-тышым бөтен нурга төрелә, –
Шулвакыт торган йирләрем охшый оҗмах түренә» (84 б.).

«Сөю» шигырендә бу хис үстерелгәннән-үстерелә бара. Һәр юл азагында кабатланган «килә» сүзе (рәдифе) дулкын-дулкын булып аны көчәйтә.

1916 елда ук иҗат ителгән бер шигырендә автор, Урта гасыр әдәби традицияләрен дәвам итеп, мәхәббәтне яшәешнең асыл, табигый бер сыйфаты рәвешендә рәсемли:

«... Акылы булган сөйгесендән качармы?
Адәм баласы сөйгесез яшәрме?
Сөйге – вөҗдан пакьлеге, йөз аклыгы!
Тәңре ансыз оҗмахка юл ачармы?» (77 б.)

Мәхәббәт темасына язганда Ләбиб Каран сөйгән ярының портретын, төскыяфәтен дә шактый матур тасвирлый. Мәсәлән, «Гашыйк булу» парчасында автор кызның «җефәк чәчләрен», «ак шалкан төсендәге ияк асларын», «озын керфекләрен», «тал чыбыктай» буйларын атый (85 б.).

Шунысы мөһим: сөю төшенчәсенә шагыйрь еш кына милләтне сөю хисләрен дә кертеп карый. Хәтта соңгысына өстенлек тә бирә: [«Милли гыйшык нурын чәчмәгән җир һәм сөйкемсез, һәм караңгылык» һ.б.]. Автор кайвакыт башка мәсьәләләр хакында сүз алып барганда да мәхәббәт тематикасына кереп алгалый. Мәсәлән, «Зәңгәр туг» (әләм, байрак. – **Х.М.**) шигырендә ул бу төснең татар өчен бик тә кадерле, милли төс булуын искәртә: [«Без зәңгәрне бик сөябез, Зәңгәр – безнең төсебез, Зәңгәр белән билгеләнгән Безнең милли көчебез», «Алтын Урда» да «алтын белән зәңгәр төс»ле әләм астында корылган, яшәгән...]. Алга таба автор зәңгәр төснең татар җырларында да киң урын алуын, аның сөю символына әверелүен искә ала һәм «Йөгерә-йөгерә җиләк җыя, Зәңгәр күлмәк кигәне, Зәңгәр күлмәк кимәс иде, Бардыр аның сөйгәне» дигән халык җырын шигырь тукымасына да кертеп җибәрә.

«Яшь вакытым җырлары»нда, гәрчә әлеге җыентыкта билгеле бер тематик төрлелек булса да, төп урынны иҗтимагый-сәяси, тарихи эчтәлекле әсәрләр били. Инде әйткәнебезчә, алар, нигездә, татар тематикасы белән бәйле. Милли рух бу шигырьләрне, дисбе төймәсе кебек, бергә бәйләп, тоташтырып тора. «Татарларның төп чыгышы» китабындагы шикелле, автор татар төшенчәсенә географик, вакыт,

тарихи яктан гаять киң, масштаблы планда карый. Аның фикеренчә, «Идел-Урал һәм Төркестан – үзебезнең йортыбыз, Кафкасия илә Кырым – һәм үзебезнең яртыбыз…»; «Атилла, Чыңгыз хан булгач тарихтан чын асылыбыз…» (10 б.); «Бу затлар – күз өстендә кашыбыз». Автор әлеге төбәкләргә атап, алар белән мөнәсәбәтләрне ачыклап, аерым шигырьләр дә яза.

Мәгълүм ки, Алтын Урда татарның милли, дәүләти, мәдәни тарихында гаять мөһим роль уйный. Ләбиб Каран да бу хакыйкатьне тирәнтен аңлый, әлеге мәмләкәтнең әһәмиятен, төп дәүләтләребезнең берсе булуын күп шигырьләрендә телгә ала. Ул әлеге илгә «Татарның төп чыгышы»нда да шактый зур урын биргән иде. Автор, шул чор чыганакларына, шул исәптән М.Кашгарый китабына, Чыңгыз хан белән аның Җырчысы арасындагы 1227 елгы шигырь-җыр текстларына һәм кайбер башка материалларга таянып, Алтын Урдадагы «тел белән хәзерге татар теле арасындагы аерма бик аз гына» булуын искәртә (55 б.). Аныңча, Алтын Урданың теле ул – иске татар теле. Ләбиб Каран Үзәк Азиядә киң таралган чыгытай теленең дә чынлыкта «татар теле» булуын искәртә. [«Чөнки Чыгытайның үзе дә, теле дә «татардыр» (18 б.)]. Алтын Урда кебек дәүләтне кабат торгызу тоткынлыктан котылып, ирек-хөрриятькә ирешүдә төп максатларның берсе итеп карала. Ләбиб Каран еш кына «Алтын Урда», «Идел-Урал» («Идел-йорт») төшенчәләрен синоним рәвешендә дә куллана. «Татар берлеге» шигырендә ул биредә яшәгән башкорт, нугай, чуаш, чирмеш һәм кайбер башка кавемнәрнең, аларның әби-бабаларының Ауразия киңлекләрендә элек-электән гомер кичерүләрен, халкыбызның бу ырулар белән «бер» булып яшәвен искә төшерә, алар белән киләчәктә дә дус-тату, бердәм, яшәргә чакыра («Алар безгә якын килсә – бер дә читкә этмәгез» (13 б.)).

XX гасырда мөһаҗирлектә яшәгән һәм иҗат иткән күп кенә каләм әһелләре кебек, Әхмәд Ләбиб Каран да берлеккә, бердәмлеккә, татулыкка милләт яшәешенең төп шарты итеп карый, аны сакламауның аянычлы нәтиҗәләргә, ирексезлеккә, инкыйразга китерүен ачына-ачына, өзгәләнә-өзгәләнә яза, үз укучысын тарихны белергә, аннан гыйбрәт-сабак алырга чакыра. Шагыйрь карашынча, татар зур, олы тарих тудырган, әмма, ни кызганыч, аны тиешенчә язмаган, теркәмәгән; хәзерге милләттәшләребез ул тарихның билгеле кадәресен дә белми, өйрәнми… Халык үз тарихын үзе язарга тиеш. Үзенең иҗат җимешләренә дә ул шул бурычны гамәлгә ашыруның бер өлеше итеп карый.

«Кабынсын, алга омтылсын, юк булсын шул зур хәтәр!» (55 б.)

Ләбиб Каран 1959 елгы җыентыгында башка бик күп төрле мәсьәләләр турында да яза. «Туктамыш белән Аксак Тимер» шигырендә ике зур татарның үзара килешмәве аркасында милләткә зур зыян килүен, аеруча Алтын Урданың зәгыйфьләнүен искә төшерә. Бер парчасында хәтта «татар» атамасының мәгънәсен дә аңлата. Аныңча, чиннарда (кытайлыларда) «р» хәрефе юк, шуңа күрә алар «татар» сүзен «татан» дип әйткәннәр (22-23 б.). «15 октябрь» шигырендә фаҗигале 1552 ел вакыйгасын искә төшерә: «Ул көн тоткын булган барча татар» (21 б.).

Кагыйдә буларак, һәр аңлы, һәр зыялы шәхес үз милләтен чагыштырмача зур, бөек, дан-дәрәҗәле итеп күрергә тели. Татары өчен җан атар зат булган Ләбиб Каран да моннан чыгарма түгел. Халкы аңа йөрәге, бәгыре кебек. Ул милләте өчен яна-көя. Хәтта аны азат-ирекле итү юлында үзен корбан итәргә, үләргә дә әзер. Васыять рәвешендә язылган бер парчасында милләтенең ирек алачыгына ышанган лирик герой каберендә «шат» ятуын искәртә («Иман белән үлгәч, ятам шат кына» 61 б.). Урыны-вакыты белән үз милләтен артык идеаллаштырып та куя. Аның татар атамасын һәрчак баш хәреф белән язуы да бик мәгънәле. Идея-эстетик,

тәрбияви якны күздә тотып, автор үз милләтен еш телгә ала, аны шигырьдәге ачкыч сүз рәвешендә файдаланып, кайвакыт анафора, рәдиф рәвешендә дә куллана. Мәсәлән, «Татар» шигырендәге күпчелек юллар ахырында бу атама кабатланып, әлеге сүзнең эмоциональ тәэсир көчен тагын да арттыра. Авторның аерым карашфикерләре бәхәсле, хәтта ялгыш та булырга мөмкин. Моны аерым каләм әһелләре, аеруча «болгарчы»лар да искә төшергәләп тора. Мәсәлән, Ә.Кәримуллин «Ләбиб Каран турында бер-ике сүз» исемле язмасында, бу әдипнең гомуми эшчәнлеген уңай бәяләп, мондый фикерне әйтеп куя: «Аның безнең халкыбызны чыңгызларга илтеп тоташтыруы... тарихи дөреслеккә туры килми» (150 б.). Янә шунысын да искә төшерик: Ләбиб Каранның карашлары аның ихласи эчтәлекле иман ышанычына әверелгән. Аларны тәнкыйтьләү, кабул итү-итмәү – хәзерге укучының үз эше. Кабатлап әйтәм: ул еш кына үзенең яраткан газиз татарын да, башка милләт-кавемнәр кебек, хәтта урыны белән арттырыбрак та тәнкыйтьли, аны битарафлыкта, куркаклыкта, гамьсезлектә гаепли.

Совет чорында Ватанда, Идел-йортта милли хәрәкәт көннән-көн, елдан-ел сүнә, зәгыйфьләнә барганда, мөһаҗирлектәге татарлар арасында миллилек, киресенчә, көчәйгәннән-көчәя бара. Ул аеруча 1950 нче елларда чагыштырмача үсә. Башында Гаяз Исхакый торган бу хәрәкәттә Хәсән Хәмидулла, Шиһаб Нигъмәти, Исфәндияр Ишгай, Әхмәд Гәрәй, Садрый Хәмид һәм кайбер башка каләм әһелләре дә актив катнаша. Болар арасында Әхмәд Ләбиб Каран аеруча активлык күрсәтә. Гасыр урталарында гына да ул, шактый кыенлыкларга да карамастан, берничә китабын бастырып тарата. Шунысы мөһим: алар үз телебездә – татарча язылган. Авторның туган телен яхшы белүе, аның байлыгын иҗади файдалануы һәр әсәрендә нык сизелеп тора.

Бу күренекле зат, шагыйрь, галим, табиб, җәмәгать эшлеклесе, журналист буларак, рухи мирасыбыз тарихына үзенең өлешен керткән, анда шактый сизелерлек эз калдырган.

Хәзергә без Әхмәд Ләбиб Каранның, нигездә, кыскача тормыш юлы, ике китабы хакында гына сүз алып бардык. Аның мирасын колачлап өйрәнү, бүгенге укучыга җиткерү, гыйльми тикшерү – әдип-галимнәребез алдында торган мөһим бурычларның берсе. Безнең бу язмабыз – киләчәктә башкарылачак олуг җитди эшләргә бер терәк-таяныч булса, Хатыйп Йосыф угылы билгеле бер дәрәҗәдә канәгатьлек хисләре кичерер иде.

***

Әхмәд Ләбиб Каранның 1949 елда иҗат ителгән «Өмет һәм өметсезлек» дигән әсәре бар. Бу язмамны шул киң һәм тирән мәгънәле, һәм милләт, һәм аерым затлар өчен файдалы булырлык шигырь белән төгәллисем килә:

«Өмет дөньясы өметсезлектән киңрәк,
Яшәргә теләүче(гә) өметле булу кирәк.
Өметле булу үзе яшәүне арттыра,
Өметсезлек – кешенең җанына тигән бер ук.
Ул ук тигән кешедә яшәүнең тәме юк.
Өметле бул, Татар! Өмет дөньясы якты!
Өметсезләнмә син – өметле булу яхшы».

Инсан, кешелек өмет белән яшәгән, яши һәм яшәячәк. Син дә, газиз укучым, Татарым, нинди генә кыенлыклар булса да, өметеңне өзмичә яшәвеңне дәвам ит. Әбибабаларыбыз юкка гына: «Өмет максатка илтә», – дип әйтмәгәннәрдер. ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

Тукай мәңгегә халык күңелендә

Индус Таһиров

Тукай, аның иҗаты ниндидер вакыт кысаларына гына сыймый. Ул мәңгелек, халкыбызга көч-куәт, дәрт һәм дәрман биреп тора.

Тукай иҗаты – безгә тарих тарафыннан татарлыгыбызны саклау өчен бирелгән ядкяр. Аңа мили хис белән сугарылган талант иңдрелгән. Һәм Тукай үзенең кыска гына гомерен милләтенә хезмәт итүгә багышлаган. Гомеренең беренче көненнән башлап соңгысына кадәр халык гаме белән яшәгән, аның авыр язмышын үз язмышы рәвешендә кичергән. Тукай татар күңелениләр сизгәнен һәрвакыт барлап, үз йөрәге аша уздыра, халкының үткәнен һәм үзе яшәгән бүгенгесен барлый, аңа үз бәясен биреп килә. Ул, чыннан да, үзе әйткәнчә, коеп куйган шагыйрь генә түгел, сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә. Шагыйрьнең бу сыйфатларын күп әсәрләрендә тоемлап була.

Без аның «Шүрәле»сенә бер гади авыл егете Былтырның «урман иясе, урман җене» белән булган мавыктыргыч маҗаралары итеп кенә карарга күнеккән. Ә бит монда шагыйрьнең күпләребез игътибар итмәгән үткән тарихыбызга карашы да чагылган. Шагыйрь Чыңгыз гаскәре төшенчәсен урмандагы биниһая биек, бихисап агачлар белән чагыштыру өчен генә кулланмый. Аның күз алдына кылт итеп борынгы бабаларыбызның батырлыклары, дәүләтләре килеп баса, тарихның пәрдәсе ачылган кебек була, бу күренеш күңелендә уфтану хисләрен уята: *«Аһ, – дисең, – без ник болай соң? Без дә хакның бәндәсе!»*

Ник без болай соң, ягъни зәгыйфь?.. Без кемнән ким? Кайда безнең шанлы дәүләтләребез, кайда ул нам? Боларның берсе дә юк, алар *«бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады»*, дип яза ул. (Халык әдәбияты. 2 нче том, 262 нче бит.) Тукай милләтенең мескен, кол хәлендә булуына борчыла, бөеклегебезгә кайту хыялы белән яна. *«Кайчан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарың (язың), Кайчан китәр кичең, килер нәһарың (көндезең)? Килерме әллә кабергә мин сөрелгәч, Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?»* – дип, милләтенең, бигрәк тә яшьләрнең акрын «уяну»ына борчыла Тукай. *«Бара милләт зәгыйфь абныр-абынмас, Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас»*, – ди. (2 нче том, 83 нче бит.)

Габдулла Тукай

Шагыйрь 1905 ел революциясенә зур өметләр баглый. *«Без бишенче елны бер көнне уяндык таң белән»*. Аның бу сүзләре шул ук вакытта XIX-XX гасыр чикләрендәге

татар алгарышына өмет баглавы да. Чыннан да, шушы елларда татарларның меңләгән тираж белән чыга торган китаплары, 30дан артык газета-журналлары, дистәләгән берсеннән-берсе сәләтлерәк язучылары, журналистлары, театр, музыка сәнгате барлыкка килә. Халкыбызның милли горурлыгы уяна. Ул, бер газета язганча, гүреннән торып, өстеннән кабер туфрагын кагып төшерә һәм горур рәвештә янә тарих мәйданына чыга. Милләт абынудан туктый, яшьләрдә сүнмәс дәрт туа. Татар, Тукай язганча, үлмәгән дә, йокламаган да, аның бары тик хушы гына киткән. Ул 1552 елда башланган, Габделбарый Баттал сүзләре белән әйткәндә, урыс җәһәннәменнән, мескенлектән чыга башлый. Аны милли хисләр биләп ала.

Шушы яңарыш дулкынында милләтебезнең тарихи хәтере хәрәкәткә килә, үз тарихы белән кызыксынуы беренче урынга чыга. Иж-Буби шәкертләре әйтүенчә, «бернәрсәне дә яшермәстән, үткәнебезне һәм бүгенгебезне ачыкларга» вакыт җитә. Шушы ачыклау эшен Шиһабетдин Мәрҗани башлап җибәрә. Һади Атласи, Гайнетдин Әхмәрев, Газиз Гобәйдуллин кебек тарихчылар аны дәвам итәләр. Аларның хезмәтләре халкыбызның милли горурлыгын уята.

Тукай тарихчыларыбызның эшчәнлеген күзәтеп тора. Ул бигрәк тә Шиһабетдин Мәрҗанине олылый. Тукай да тарихыбызны барлый, ләкин профессиональ тарихчылардан аермалы буларак, үткәнебезне халык иҗаты аша төсмерли. Аңа, ди ул, «туплар да атмаган, уклар да кадалмаган». Шуның өчен ул аны тутыкмас көзгегә тиңли, халыкның тарихи хәтерен уяту чыганагы итеп күрә.

Шагыйрь тарихыбызны халык иҗатының җәүһәре булган җыр-моң аша да төсмерли. Ул халкыбыз җырларына гашыйк. Аларны тыңлаганда «аркадан каннар йөгерә», ди ул, һәм моңыбызның «алтынын коймаска» өнди. *«Балачагымда урман буенда ат көткән вакытларымда Сәйфетдин вә Гайнетдиннәрнең учак кырыенда җырлаган җырлары һәм дә моңлы күңелләреннән чыккан хиссият утлары минем йөрәгемә тәэсир итәләр иде, бу җырлаулар минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар»,* – дип язган Тукай. – *Мин кечкенәдән җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәгемнән миндә туган телебезгә сөю туды. Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!»* Күренә ки, монда Тукайның туган телебезгә мәхәббәте ярылып ята. Шагыйрь шушы мәхәббәтне җыр-моң аша яшь буынга сеңдерүне беренче урынга чыгарган. Ул кешенең балалык чорына махсус игътибар биргән, чын татар итеп тәрбияләүне баланың дөньяга килүе белән үк башларга кирәклеген аңлап эш иткән. Шагыйрьнең балаларга багышланган шигырьләрендә, әйтерсең лә, җыр-моң, туган тел бер җепкә тезелгәннәр.

Тукай иҗатында юкка гына бишек җырларына аерым игътибар бирелмәгән. Җыр, аның көе, теле – татар кешесенең гомерлек юлдашы. *«Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән».* Ана кеше моң аша баласының Аллаһы Тәгалә биргән туган телен ача. Ә әбисе мавыктыргыч әкиятләр белән аны баланың күңелендә ныгыта, анда аны камил рәвештә урнаштыра. Тукайның «Бишек җыруы»нда: *«Әлли-бәлли көйләрем, хикәятләр сөйләрем; Сиңа теләк теләрем, бәхетле бул, диярем»,* – дигән сүзләр бар. Әлеге юлларда – ананың, моң һәм тел аша, Аллаһы Тәгаләдән бала өчен изгелекләр сорау нияте.

Тукайның «Ана догасы»нда бу бигрәк тә матур чагылыш таба. Авыл киче, тирә як тыптын, халык йокыга талган, хәтта этләр дә өрми. Күктә нурлы ай калкып, тирә якка нур чәчә. Бары тик бер өйдә генә ут сүнмәгән. Анда бер ана, намазлык өстендә Аллаһтан сорап, баласына теләк тели. *«Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән газиз угълым!»* Аның күзләреннән тамчы-тамчы яшь тама. *«Карагыз,* – ди шагыйрь, – *шул догамы инде Тәңре каршына бармас?»*

Ул, гомумән, баланың итагатьле, мәрхәмәтле, эшсөяр рәвештә зур дөньяга чыгуын беренче урынга куя. Баланың үзенә

мөрәҗәгать итеп, ул: *«Тынма, эшлә, и сабый! Бел, Тәңредән эшләргә – көн; Эшләп аргачтан, бирелгәндер тыныч йокларга төн»*, – дип, аны кояштан үрнәк алырга чакыра. Шагыйрь, кояш, иртә торып, таң аттырып, көнозын күктә йөзеп, дөньяны яктыртып арганнан соң, «ирнеп кенә тауга бата», дип тасвирлый. *«Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман, Күп арасында, кояш күк, ялтырарсың бер заман!»* – дип, аны якты киләчәккә чакыра. Искиткеч матур төсмерле, мавыктыргыч язылган «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыренең исеме үк аның балада хезмәткә ихтирам уяту максаты куюын күрсәтә. Тукай балаларга атап язылган дистәләгән әсәрләрендә аларның күңеленә милли хисләр сеңдерүне, татарлык оеткысын салуны беренче урынга куя. Һәм бигрәк тә җыр-моң, халык иҗаты аша.

Тукай татар җырларына аларның нечкә кылларга кагылулары өчен генә түгел, телебезнең сакчысы булган өчен дә гашыйк: *«Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип, кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки: чын халык телен, чын халык рухын бары тик халык җыруларыннан гына табып була. Аннан башка каян табасың?»* Әйе, каян табасың?!.

«Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен».

Бу, әлбәттә, яшәештә уен-көлкегә урын булмаска тиеш дигән сүз түгел. Тукай иҗатында аларга да шактый урын бирелгән. Тик менә шагыйрь һәрвакыт диярлек халык күңелен кузгата, аның нечкә кылларын тибрәтә торган көйләргә өстенлек биреп килгән. Аларны ул милли рухыбызны ныгыту чыганагы итеп күргән. Тукайга, күрәсең, моңыбызның эченә үтеп керердәй сәләт иңдерелгән, аның сихри көчен аңлардай мөмкинлекләр бирелгән.

Тукай, халкын, аның иҗатын җаны-тәне белән сөйгәнгә күрә, үзенең бик кыска гомеренең шактый өлешен моң һәм халык әдәбиятын барлау һәм җыйнауга багышлый. 1910 елны Шәрыкъ клубында укыган лекциясендә аларның берсен – ачкыч, икенчесен йозак дип бәяли. Ачкыч белән, ягъни моң аша халык күңеленә үтеп кереп була, йозак белән, ягъни халыкның бертуктаусыз байый торган җор шигъри теле ярдәмендә аны югалмастай дәрәҗәдә саклап була. Чыннан да, гасырлар буе буыннан-буынга күчеп, бай вә фаҗигале тарихыбызны сеңдерә барган моң һәм әдәби мирас ачкыч һәм йозак рәвешендә яши ала. Алар игезәкләрне хәтерләтә.

Тукайның шушы искиткеч чагыштыруын бүгенге иҗат кешеләре дә үзләренә күрсәтмә итеп кабул итсәләр, бәлки, милли моңнарыбызны, җырларыбызны каплап-томалап бара торган хәзерге булыр-булмас сүзләргә көйләнгән мәнсез җырларга киртә-чик куярлар иде. Ә киртә кирәк, чөнки тел һәм милли моң – милләт сакчылары.

Тукай юкка гына шактый җырларның тарихын тикшереп, аларны төрле яктан анализламаган. Ул аларның бабаларыбыз тарафыннан калдырылган *«иң кадерле вә бәһале бер мирас»* икәнлеген аңлап эш иткән. Болгар шәһәре, авыллары *«беттеләр, эзләре дә калмады»*, әмма алар *«халкыбыз күңелендә һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер»*, дип язган шагыйребез. Ул халык җырларының яшәү көзгесе икәнлеген конкрет мисаллар белән күрсәтә алган. Аларны укыганда, Тукайның рухи дөньясы халыкчанлык хисе белән сугарылганлыгына тагын бер кат инанасың.

Шагыйрь күп җырларны җыеп-туплап кына калмый, аларның тарихы турында да мәгълүмат бирә. Мәсәлән, «Тәфкилев» көе мөфти Тәфкилев кызының француз егетенә булган бәхетсез мәхәббәтенә багышланган.

Шагыйрь бәхетсез мәхәббәтнең тамырлары шактый тирән икәнлеген аңлап эш иткән булса кирәк. Аның «Җырлар дәфтәре»ндә «Хан кызы көе» дә булган. Тик ул аннан ертып алынган. Кем белә, бәлки, ул Алтын Урда ханы Туктамыш кызының бәхетсез мәхәббәтенә багышланган җырның берәр варианты булгандыр. Әйтүе кыен, ләкин шулай булуы бик ихтимал.

«Мотыгия» шәкертләре. Җаек (Уральск), 1905. Тукай беренче рәттә уңнан икенче

Туктамыш ханның кызы Нәнекәйҗан караим егетенә гашыйк була. Хан, әлбәттә, кызын башка диндә булган егеткә бирергә теләми. Кайгысыннан кыз, текә кыядан сикереп, үзен үлемгә дучар итә. Шушы җырны ишеткән Зәки Вәлиди аның көе «Тәфтиләү»не хәтерләтә иде дип язып калдырган. Димәк, җырның көе, әлбәттә инде, ниндидер үзгәрешләр белән сакланып килгән, ә сүзләре һәрвакыт диярлек заман фаҗигасенә җайлаштырылган булып чыга.

Тукай аша без «Ашказар» көен дә шундый ук бәхетсез мәхәббәт тудырган икәнлеген беләбез. Бу һәм аның тарафыннан тупланган, тикшерелгән башка җырларның сүзләре һәм моңнары да ачкыч белән йозак рәвешендә яшәгәнлекләренә дәлил булып тора.

Шул ук вакытта Тукай халык иҗатының бертуктаусыз байый торуына да игътибар иткән. Ул, аларның үзе ишеткән төрле вариантларыннан мисаллар китереп, шуның белән халыкның үзендә җырга нигез салучыларның туа торуына ишарә ясаган.

Шагыйрь үзенең «Халык әдәбияты» рисаләсен тикмәгә генә «Туган тел» шигыре белән тәмамламый. Һәм инде бу шигырь шулай ук юкка гына милли гимныбызга да әверелмәгән.

Шикләнмим, әгәр дә ул шушы халык җәүһәрләрен тупламаган булса, күбесе инде онытылган да булыр иде. Нинди генә җырлар юк монда. Аларның барысында да халык язмышы. «Озын эрбет», «Сәгать чылбыры», «Җырчы Фәхри» кебек җырлар үзләре генә дә ни тора! Болар – халык җәүһәрләре. Бүгенге җырларның шактыеның сүзләре шул җырлардан алынган. «Хафизәләм иркәм» җырының сүзләрендә дә шуны күрәбез: *«Ак куян дип аткан идем – булды тауның катлавы. Аргы яктан бераү килә – безнең җаннаш атлавы».* Монысы – Тукайда. Бүген җырлана торган җырда исә шагыйрь китергән «безнең җаннаш атлавы» сүзләре «Хафизәләм иркәм атлавы» дип кенә үзгәртелгән. Шундый мисаллар дистәләгән. Минемчә, бездә Тукай иҗатының шушы ягына тиешле игътибар җитеп бетми.

Җырларыбызны туплау эшен яшь шагыйрь Уральскида вакытта ук башлап җибәргән һәм аны гомере буе дәвам иткән. Әгәр дә без, Тукай халык җырларын җыю традициясен башлап җибәрүчеләрнең беренчеләреннән булган, дисәк, зур хата булмастыр. Аның «Сабах» нәшриятында чыккан, дәвамчыларына үрнәк булып торырдай җырлар җыентыгы шул турыда сөйли.

Тукай Уральскида үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәгә багышланган бер мәкаләсендә «Тәфкилев», «Әллүки», «Сакмар суы» кебек җырлар турында, *«карт аталарыбызның чын йөрәгеннән чыккан», «туган һәм туачак балаларыбызның күңеленә яңа-яңа милләт хисләре... саба җиле шикелле, рух өрәчәктер»,* дип язган. (3 нче том, 107 нче бит.)

Шагыйрь фаразлаганча булсын, милли хисләр белән сугарылган «саба җилләре» бүгенге музыкаль сәнгатебезгә дә рух өреп торсын иде. Нәкъ менә Зифа Басыйрова, Гөлсем Сөләйманова, Фәридә Кудашева, Флюра Сөләйманова, Зөһрә Сәхәбиева, Ания Туишева, Рабига Сибгатуллина, Наҗия Теркулова, Габдулла Рәхимкулов, Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров, Мирсәет Сөнгатуллин, Идрис Газиев, Фердинанд Сәлахов, Шамил Әхмәтҗанов, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров кебек җырчыларыбызның иҗатларына өреп торган кебек.

Аларның иҗатында Тукаебызның бу сүзләре язылмаган канун рәвешендә яши. Аллага шөкер, бүгенге яшь җырчыларыбыз арасында да андыйлар юк түгел. «Татарстан – яңа гасыр» каналында бара торган «Җырлыйк әле!» һәм ВГТРКның филиалы радиотапшыруларында бу шактый яхшы чагыла. Тик шулай да бездә үзешчән сәнгатькә игътибар җитеп бетми. Ә бит халык иҗатына, аның җыр-моңына гашыйк яшьләр нәкъ шунда үсеп чыга. Чын халыкчан шигърият тә шунда яши. Үтемле чагыштырулар да шунда туа.

Тукайны татар шигъриятенең төзелеше дә юкка гына кызыксындырмаган. Ул аның шул үтемле якларына махсус игътибар биргән. *«Без, татарларның, шигырь сөйли торган бәхерләре* (үлчәүләре. – **И.Т.**) *гаять гүзәлдер. Бер татар шигырен әллә ничә төрле көйләргә җырларга мөмкиндер»* һәм хәтта татарлар җырлый торган көйгә рус шагыйрьләренең шигырьләре дә килеп торадыр, дип язган шагыйрь. Монысы, әлбәттә, рус җырларында да татар көйләре чагылганлыгына ишарә.

Дөрес, бу турыда язарга яратмыйлар. Чөнки ничек инде ул бөек рус халкының җырларында татар көйләре чагылсын?! Бу мөмкин түгел! Әмма мөмкин икән шул! «Ямщик» җырына гына игътибар итик. Аның русчасы да, татарчасы да бер үк хисләрне уята. Ә бит «ямь» хезмәтен татарлар барлыкка китергән. Шундый җырлар да иң элек аларда туган.

Күренекле рус этнографы, профессор мәрхүм Евгений Прокофьевич Бусыгин бу турыда һәрвакыт сөйли, бик күп рус җырларының татар көйләре белән сугарылганлыгын ассызыклый иде.

Шаляпинның җырларында да татар элементлары барлыгы турында язып чыгучылар булды. Татар моңына төрелеп, аннан рухланып яшәгән җырчының иҗатында моның шулай булмавы мөмкин дә түгел. Юкка гына заманында «Тәфтиләү», «Озын су», Мөхәммәдия», «Ашказар» кебек татар халык җәүһәрләрен скрипкачы Козлов, Г.А.Трейтер кебек җырчылар башкарманнардыр.

Татар моңы ул – борынгы моң. Ул үзенә киң далаларда яшәгән ерак бабаларыбызның күңел хисләрен сеңдергән. Бервакыт безнең тарих факультетында стажировка үтүче кытай профессоры Чянь-Бин: «Ә бит бездә сезнең музыкагыз. Без аны сездән алып, бөтен Ерак Көнчыгышка, Япон утрауларына кадәр тараттык», – дигән иде. Татарларның моннан мең ярым ел элек язылган кытай кульязмаларында ук телгә алынуы моңа бер дәлил булып тора.

Бу, чыннан да, шулай. Профессор Марсель Бакировның хезмәтләрендә Кытай императорларының татарлар янына, аларның көйләрен язу өчен белгечләр җибәрү фактлары күрсәтелгән.

Шулай булгач, нишләп аны татарлар белән йөзләрчә ел янәшә яшәгән руслар үзләштермәсен икән?! Юк, мин һич кенә дә рус музыка культурасын шик астына куймыйм. Ул бөек. Әмма борынгы рус халык җырларының татар моңнары белән аваздашлыгына шик юктыр дип уйлыйм.

Тукай исә моны бик яхшы тоемлаган. Шунлыктан ул Пушкинның бер шигырен татар көе белән җырлау мисалын китергән.

«Еду, еду в чистом поле,
«Җизнәкәй» (ике кәррә)
Колокольчик динь-динь-динь...»
«Балдызым, ялгызым» (бер кәррә).

Боларны язган вакытта аның алдында русларның «Народные песни» китабы торган.

Тукай – халык җырчысы. Аның шигырьләре, барлык язмалары да могҗизаи моң булып яңгырый. Аңа халык шагыйре исемен бернинди указ белән дә бирмәгәннәр. Милләт биргән исем ул. *«Мине әгәр синеке дип исәпләсәләр, мин бәхетле»,* – дип язган шагыйрь. Тукай милләт хыялын барлык хыяллардан да татлырак санаган. *«Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем».* Нәкъ шулай булды да.

«Халык аның үлеме турындагы хәбәрне гомум кайгы рәвешендә кабул итә. Бу көнне

барлык татарлар да җылый, чөнки алар үзләренең бөек сүз патшасын югалттылар», – дип язган «Кояш» газетасы.

Шул көндә чыккан газеталар, шагыйрь үзе калдырган 500 сум акчага, Тукай фондын булдыру максатыннан, «Тәрҗеман» газетасы үзеннән 100 сум өстәде һәм башкаларны да шушы башлангычка кушылырга чакырды, дип язганнар.

Һәммә җирдә, Кытайның Көлҗә шәһәреннән башлап Петербургка, Әстерханга кадәр диярлек, Тукай җәмгыятьләре барлыкка килә. Шагыйрьгә багышланган кичәләр үткәрелә. 1913 елның 14 ноябрендә Казанда Тукай җәмгыяте оеша. Әлеге җәмгыять мохтаҗ язучыларга ярдәм итүне үзенең төп максаты итеп билгели. Әстерханда да Тукай җәмгыяте булдырыла, аны күренекле азәрбайҗан җәмәгать эшлеклесе Нәриман Нәриманов җитәкли. Бу шәһәрдә 1914 елда сигезенче мәчетнең указлы мулласы Габдрахман Гомәров «Тукай Уральскида» исемле китап чыгара. Сарытауда Мәүлед бәйрәме вакытында Тукай шигырьләре яңгырый, аның рухына «Фатиха» сүрәсе укыла.

Мәкәрҗә ярминкәсендә шагыйрьнең сайланма һәм аерым әсәрләре күпләп сатыла. Петербургта Тукай исемендәге ике стипендия булдырыла: берсе – университетта, икенчесе – югары хатын-кызлар курсларында. Инде искә алынган Көлҗә шәһәреннән хаҗга баручылар да шундый стипендия фондына 50 сум акча кертәләр. Германиядәге Шакир әфәнде, Тукайның рәсеме төшерелгән открыткалар ясатып, аларны сатудан кергән акчаны шулай ук аның исемендәге стипендия фондына бирергә җыена.

Кызганыч, мондый эшләргә каршы төшүчеләр дә табылмый калмый. Мәсәлән, Оренбургта һәм Читада ике студентның Тукай иҗатына багышланган лекцияләре тыела. Казанда шушы эшне башкарырга тырышкан ике укытучыны урыннарыннан алалар.

Ләкин төрки һәм ислам дөньясында шагыйрьнең даны шулкадәр киң таралган була ки, аңа ихтирам йөзеннән барлыкка килгән халык хәрәкәтен беркем дә, берничек тә туктата алмый.

1913 елның апрелендә Бакуда рус телендә чыккан мөселман газетасы «Каспий»да «Дагестани» имзасы белән «Мөселман язмалары. Бер үлем тирәсендә» дип аталган мәкалә бастырыла. Анда мондый сүзләр бар: *«Сүзе белән йөрәкләрне яндырган шагыйрьнең истәлеге һәркем өчен дә кадерле. Сигез ел буе иҗтимагый эшләрдә катнаша килсәм дә, әле беркайчан да мөселманнарның сәнгать остазын (жрец) югалтулары өчен букадәр кайгырганнарын күргәнем юк иде... Идел буе мөселманнары культура һәм аң дәрәҗәләре белән без, кавказлыларны, уздырдылар. Русия мөселманнары үз шагыйрьләренең бәясен аңладылар һәм аңа тиешле бәя бирә башладылар».*

Шушы журналист, Тукай яшәгән җирләрдән читтә гомер кичергән кавказлы булуына да карамастан, шагыйрьнең халык йөрәгенә никадәр үтеп кергәнлеген билгели алган.

Тукайны төркиләр генә түгел, барлык башка мөселман халыклары да яраткан, үз иткән. Күренекле таҗик язучысы Садретдин Әйнидән, революциягә кадәр Пушкин белән Лермонтовны белә идеңме, дип сораганнар. Ул моңа, әйе, белә идем, Тукай аша, дип җавап биргән.

Тукай – халыкны, ә халык Тукайны яраткан. *«Барлык уем кичен дә, көндезен дә Синең турыда, милләтем. Синең саулыгың – минем саулыгым. Синең авыруың – минем авыруым».* Ул саулык чыганагын – тарихыбызда, аның җыр- моңнарында, ә авыруын аның бердәмлеге булмауда күргән. Һәм милләтебезне бер-береңә ук атудан туктарга, *«тәнебез аерым булса да, бер җан булыйк»*, дип яшәргә өндәгән.

Ул шушы рәвештә яшәгән һәм милли хисләр аша якты дөнья белән хушлашкан. Тукайның «күңел кошы» бу дөнья читлеген тарсынып очып киткән булса да, рухы – халкыбыз күңелендә. Ул безгә яшәү көче биреп тора. ■

Бер бәйләм беркетмә

«Ялкын»лы ялкынлы еллар хатирәсе

«Ялкын» журналының гыйнвар, февраль һәм апрель саннары (1961)

Февраль беркетмәсе

2 февраль, 1961 ел.

«Ялкын» журналы редколлегиясенең чираттагы утырышы.

Көн тәртибе:

1. «Ялкын» журналының 1 нче санын тикшерү.

2. Апрель планын раслау.

Фикер алышуда катнаштылар: Б.Камалов, Л.Зарипова, И.Гомәрова, Ш.Галиев, Г.Камай, Г.Закиров, И.Юзеев.

Барлас Камалов:

– №1 уңышлы, тормыш белән атларга тырыша. Темалар төрле. Тел әйбәт. «Мин походка чыктым» материалында балалык җитми.

Ләлә Зарипова:

– Элекке журналларга караганда күп тапкыр яхшырак. «Үзебез ясыйбыз»да фотолар ямьсез. «Курантлар чыңын тыңлаганда» – Ленин турында хикәя, «Ул безнең йөрәкләрдә», «Сумкалар бушап калса», «Вахта машинасыннан төшкәч» – әйбәт материаллар. Нефть чыгаруның ничек икәнен балаларга бирергә кирәк. Тәлгать Бикчурин бригадасына барырга кирәк.

Идея Гомәрова:

– Бу номер яңа программа белән эш итү өчен укытучыларга да әйбәт. Такташ, Фатих Әмирхан турындагы материаллар ошады. Аларның урнаштырылу тәртибе әйбәт. «Курантлар чыңын тыңлаганда» бик бай эчтәлекле, Ленин турындагы хикәя балаларны кызыксындырырлык. «Күзге күренешләр» бу номер өчен әйбәт түгел. «Октябрят буласым килә» әйбәт. Ләкин туган көнне бакчада акча җыеп үткәрү педагогик яктан дөресме икән? Детсад баласы бүләк алу өчен алдармы икән?

Киләчәктә журнал тагы да яхшырак чыксын иде.

Илдар Юзеев

Гыйлем Камай

Барлас Камалов

Шәүкәт Галиев

Шәүкәт Галиев:

– Уңай яклар белән килешәм. «Сәгать нигә ялгышты?» – бик актуаль, әйбәт әкият. Әдип Маликов очерклары ошады. «Сумкалар бушап калса»ны бирү әйбәт. Аны откликлар белән дәвам итәргә кирәк.

Өченче биттәге рәсемнәргә бәйләнеш җитми. «Минем хыялым» шигыре ошады. «Октябрят буласым килә» әйбәт. Н.Җиһанов турында яхшы бирелгән. Номерлар бер-берсенә охшамасыннар иде. Оформление төрлечә булсын. Һәр номерда юмор булсын.

Гыйлем Камай:

– Журнал артка китмәсә ярар иде дип курыккан идем. Бу номер шатландырды.

Ләкин бу сезнең беренче адым гына әле. Ленин хакында күпме язсак та, рәхмәт кенә әйтерләр.

Такташ турында җылы язылган. Ф.Әмирхан турында да шулай язылса... Н.Җиһановка кыска гына нота булса, тагы да шәп булыр иде.

Классик рәсемнәрне биреп барыйк.

Гали Закиров:

– Беренче номер ошады. «Физкульт-спорт» бүлегендә фактик материаллар бирергә кирәк. Чемпионнарны. «Үзебез ясыйбыз»да фотоларда химик приборлар түгел. «Ял сәгатьләре» бик җиңел. Авторлары ничәнче класста укый? Балалар көчләрен чагыштырып карасыннар. Өченче биттәге рәсем аңлашылып җитми.

Газиз Мөхәммәтшин март саны турында әйтеп үтә. Апрель планы белән таныштыра (Халыклар дуслыгы номеры).

Ләлә Зарипова:

– Бу теманы алуыгыз бик мактауга лаек. Киләсе номерларда балалар йорты, интернатлар турында бирегез.

Гыйлем Камай:

– Тышлык исеме: Россия – туган илем. Ленинның милләтләр дуслыгы турындагы үз сүзләрен бирегез.

План яхшы дип табыла.

Утырыш тәмам.

Җаваплы сәркатип *(И.Юзеев)* ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

«Гомернең дулкыннары» турында

Тәлгат Галиуллин

Кадыйр Сибгатуллин – шигърияткә «путевка»ны Хәсән Туфан кулыннан алган бәхетле язмышлы шәхес. Аның «Әманәт» исемле беренче җыентыгы 1974 елда дөнья күрә, ә Туфан «Социалистик Татарстан»да «Шигърият офыгы киңәя» мәкаләсен бер ел иртәрәк бастыра. Бераз вакыт үткәннән соң, остаз, чыгышын тулыландырып, киңәйтеп, «Казан утлары»нда чыгара. Яшь шагыйрь иҗатына мондый игътибар нәрсә белән аңлатыла соң? Әйтик, Сибгат Хәким тәнкыйть жанрына еш мөрәҗәгать итте, күп басылды. Аның фикерен ишетмәгән, ярдәмен тоймаган татар шагыйре юктыр. Хәсән Туфан бу яктан бик кырыс, нәзберек, сайланучан шагыйрь иде. Аның каләменнән «дежур» мәкаләләр төшмәде диярлек. Әмма затлы шигырьгә ул гаять игътибарлы булды, мактау сүзен кызганмады. Күренекле әдип К.Сибгатуллинның беренче шигырьләрендә үк дөньяны һәм кеше рухын яңачарак тасвирлауга омтылыш, табигый сәләт күрде һәм миһербанлы ярдәм кулын сузды. Хәсән Туфан ялгышмады, хәзер ул әдәбиятка татар поэзиясенең йөзен кызартмаслык шагыйрь алып керде дип өздереп әйтергә була.

Кадыйр Сибгатуллин да остазына бурычлы булып калмады. «Балкып тора Туфан тәрәзәсе», «Туфаннар» кебек шигырьләре аша ул «Туфан белән сөйләшү» поэмасына килде. Бу әсәр – Туфанны кеше һәм шагыйрь буларак аңларга, аның тормыш күренешләрен һәм әхлакый-фәлсәфи дөньясын ачарга омтылышның иң уңышлы үрнәкләреннән берсе.

«Сөйләшәсе килә,
Мөлдерәмә
Тулып тора күңел, нигәдер», –

кебек бик гадәти юллар, табигый интонация белән башланып киткән поэма үз эченә табигатькә, туган җиргә, туган телгә, рухилыкка мөнәсәбәт шикелле хәзерге чорның, яшәешнең бик күп якларын ала. Үлчәм берәмлеге бик олы – Туфан язмышы, Туфан тудырган шигъри дөнья. Хәл аяныч, татар әдәбияты классиклары әсәрләре китап киштәләрендә тузан җыеп ята, алучы юк:

«Өлкән буын таныш,
Бүгенгенең теле киселгән...»

Шагыйрь бу хәлнең эчке сәбәпләренә, асылына төшенергә омтыла. «Ана сөте юк шул чит телдә» гыйбарәсе икенче бер фикерне алга чыгара: *«Машиналар шавы кыйммәт бүген, Кыйммәтрәк халык моңыннан».*

К.Сибгатуллинның үзгәртеп коруга, хәбәрдарлыкка да үз мөнәсәбәте, үз бәясе бар:

«Заманга таянуым түгел,
Сүз әйтергә хәзер ярый, дип,
Дөрес сүзне нинди заманда да
Туры итеп әйтү ярый бит».

Бу юлда да үрнәк-өлге булып «тылсым иясе», «бәллүр йөрәк» Туфан тора. Әмма Алып батыр дәрәҗәсенә күтәрелү җиңел түгел икән:

«Туфан булыр өчен яшәү кирәк
Заманадан бераз зур булып».

Язучыларның бер корылтаенда Кадыйр Сибгатуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмовлар белән бергә, хәзерге татар поэзиясенең төбенә җигелеп, тотрыклы эшләп килүче шагыйрьләр рәтендә аталды. Бу олы бәягә ул озак һәм катлаулы эзләнүләр, югалтулар һәм ачышлар аша килде. К.Сибгатуллинның иҗат юлы тоташ уңышлардан һәм триумфлардан гына тормады. Мансур Вәлиевнең бу уңайдан язган ачык хаты укучыга мәгълүм. Тәнкыйтьче шактый кискен төстә (вакыты белән арттырыбрак, күпертебрәк тә җибәреп), чордашы каләменә уралган буш күпсүзлелеккә, сорылыкка, коры публицистикага каршы чыга.

Әмма Кадыйр Сибгатуллин, берише шагыйрьләр төсле, үз эченә бикләнеп, үпкәләп утырмады, тәнкыйтьне дөрес кабул итеп, эзләнү-уйлануларын дәвам итте, «Туфан белән сөйләшү», «Әни мәхәббәте», «Уел» кебек уңышлы әсәрләрен укучыга ирештерде.

Һәм менә безнең алда – шагыйрьнең барлык язганнарын, «Әманәт», «Гамь», «Авазлар», «Хыял», «Инану», «Таңнар, кичәләр», «Бер күкләргә карап» кебек элегрәк дөнья күргән китапларында басылган шигырьләрен эченә алган кульязмасы. Алгарак китеп булса да, шуны әйтәсе килә: автор, бөтен хәзинәсен укучыга тәкъдим итмичә, аларны иләк аша үткәреп, иң яхшыларын сайлап алуга омтылган. Ни дисәң дә, шагыйрьнең йөзен күрсәтердәй юбилей китабы булырга тиеш бит.

К.Сибгатуллин традицион формада да үз аһәңен, үз моңын чагылдыра алган шигъри индивидуальлеккә ия шагыйрь. «Иргә чыкмый калган апалар», «Кар шыгырдый», «Авыл урыны» кебек җәмәгатьчелекнең күңеленә, рухына уелып куелган шигырьләрендә бу сыйфаты аеруча ачык чагыла.

Мәхәббәт темасын читләтеп үткән, бу олы хис турында уйланмаган, илһамланмаган шагыйрь юктыр. Бу олы кичерешкә К.Сибгатуллин да бик күп әсәрләрен багышлый. «Зифа килен» поэмасы да шул рәттә тора. «Мәҗнүн» шигырендә ул хәтта традицион мотивта да үзен таба алган:

«Мин бит Мәҗнүн!
Аны эзләп йөрим,
Ләйлә генә таныр таныса!»

Шагыйрь «Көтәм әле», «Саубуллашу», «Үрдәләнеп, үпкәләшеп», «Шөкер дөньялар», «Әй гомер», «Югалткан, тапкан чагым» кебек шигырьләрендә мәхәббәтне тормышчан ямьлелегендә, самимилегендә ачуга ирешә. Аларда эротика бөтенләй юк. «Сурәтем калсын күзеңдә, Текәлеп карыйм әле» («Саубуллашу») кебек нечкә күзәтүләр һәртөрле физиологик «кызыктыру»ларга урын калдырмый.

Халык җырларына артык якын шагыйрьләрдән булмаса да, К.Сибгатуллин халыктан «тормыш дәресләре» алудан тартынып тормый. «Яратуның күзе сукыр, Хаклык була халык сүзендә», – дип башланып киткән шигырь җыр аһәңен үзенчә үстерә, яңарта. Бу якынлык аның шигыренә табигыйлек, тормыш фаҗигасенә сизгерлек, халык язмышы турында тирәнтен борчылып уйлану рухы бөрки. К.Сибгатуллинны яхшы мәгънәсендәге трагик шагыйрь диярга дә була.

«Чит илдән хат», «Читтәге авылдашлар», «Ирләр», «Өлкәннәр», «Карга оялары җирдә ята», «Есенинны уйлап» кебек нәкъ тормышның үзеннән, борылыш ноктасыннан үсеп чыккан шигырьләр теләсә кайсы шагыйрь иҗатын бизәрлек көчкә ия.

Каныга бит мәрхәмәтсез язмыш:
Бер башакта ничә арба сагыш.
(«Юлда үскән арыш»)
...Каюм бабай кабереннән
Әкият булып яфрак коела.
(«Әкиятче»)

Шагыйрь фәлсәфи гомумиләштерүгә менә шундый ачык күзәтүләр, детальләр аша юл ала. Әйтергә кирәк, каләменең шул сыйфаты белән ул Туфан иҗатына якынаеп китә.

«Кибәнче кар», «Ап-ак пароход», «Ике сүз турында», «Әйт әле», «Саллар», «Бозлар» кебек шигырьләрдә зур яңалык юк төсле. Гадәти сюжетка кеше язмышы килеп кергәч, шигырь җанланып, ямьләнеп, яшәреп китә. «Күңел», «Тормыш чире», «Нурфия» шигырьләрендә психологик күзәтү, кешелекле интонация өстенлек ала.

К.Сибгатуллинның бу кульязмасы аның поэма жанры үсешенә керткән өлешен дә тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. Жанр үзенчәлекләре, эчтәлекләре буенча әсәрләре төрле-төрле. «Утлар» поэмасында Прометей, билгесез зат, кеше, Хиросима кебек гомуми символик образлар кешенең җирдәге кыйммәте, үткәне һәм бүгенгесе турындагы уйлануларга юл ачалар. Утка мәдхия җырлаган, тыныч тормышны яклаган урыннарның публицистик ялкыны көйдерә, уйландыра. Шул ук вакытта поэма озынгарак киткән.

«Кыя илендә» әкият-поэмасын, бәлки, балаларга тәкъдим итәргә мөмкиндер, әмма бу китапка ул ятышып бетми, фикере кемнедер кабатлый дигәнрәк тойгы кала.

«Уел» поэмасы – бай эчтәлекле, төгәл һәм ачык сюжетка корылган, уйланылган поэма.

«Зифа килен» әсәренең сюжеты иске (сөйгәне Гариф сугышка китә, Зифа аның өенә күчеп килә, Гариф сугыштан яралы кайтып, өендә үлгәч тә, Зифа, әлбәттә, аңа турылыклы кала), тапталган, кабатланган булса да, поэма матур буяулар, йөгерек тел исәбенә кабул ителә, укыла.

«Изге җаннар яшәп китә,
Олы мәхәббәт кала», –

кебек юллар күңелгә ята.

Кульязманың сыйфатын яхшырту юнәлешендә эшлисе бар шикелле. Тәкъдим ителгән шигырьләрнең дәрәҗәсе тигез түгел. Бик тирән, затлы әсәрләр янәшәсендә үк шактый йомшаклары, К.Сибгатуллин каләме ирешкән дәрәҗәдән түбәнрәк торганнары да бар. Әйтик, кульязманы ачып җибәргән «Авылым» шигыре озын, искечә, декларатив, «Кырларым күмелгән рәшәгә» әсәрендә яңалык, шигъри рух юк. «Ватан утлары» шигыре хәзерге заманда яңгырамый, күңел мондый күтәренкелекне кабул итми. «Замана» әсәре дә шуңа якын. «Кар яуганда»га хис киеренкелеге җитенкерәми. «Ялгыз хатын» тормышчан әсәр, әмма бетеме уйланылып җитмәгән. «Табынам ташка» шигыренең мәгънәсе бүген инде яңгырамый. «Пионерлар», «Бәйрәмдә» шигырьләренең оптимистик рухын, пафосын кабул итүе кыен. «Җылы яктан язган хат»ның көньяк халкын тоташ мактаган юллары күңелдә расланмый, теләктәшлек тапмый.

Тулаем алганда, мин, тыныч иман белән, кульязманы бастырып чыгаруга тәкъдим итәм, укучыны сөендерер дип уйлыйм.

1990 ел ■

Алманиягә сәфәр

Камил Саттаров


Freunde bei uns zu Gast

Das Volkskunstensemble „JUNOS" aus der Tatarischen ASSR wurde in Malchow und Malchin stürmisch gefeiert. Foto: FE/Krüger

«Freie Erde» газетасының татар артистларының Германиягә сәфәре турында язылган 1972 елгы ноябрь саны

Узган гасырның 60-70 нче елларында Казан урамнарында шорты кигән, күбрәк өлкәннәрдән торган сәяхәтчеләр төркеме күренә башлады. Алар шәһәребезнең мәдәният сарайлары әзерләгән кызыклы чараларны зур кызыксыну белән карап китәләр һәм кайберләрендә үзләре дә катнашалар иде. Бу чаралар күп вакытта Химиклар һәм Төзүчеләр мәдәният сарайларында узды. Кунакларыбызга халкыбызның күмәк уеннары, фольклорга нигезләнгән концерт номерлары һәм татар халкының традицион киемнәре бик ошый иде. Шул концертларның берсен сәяхәтчеләр белән Алмания-Совет дуслыгы җәмгыятенең рәисе булып эшләгән ханым да карый. Алмания делегациясе җитәкчесе, Казан белән саубуллашу алдыннан, татар халкының кунакчыллыгына һәм талантына соклануын белдерә. Шуңа күрәдер дип уйлыйм, 1972 елда Алмания шәһәрләрендә һәм районнарында Бөек Октябрь социалистик революциясенең даими үткәрелә торган юбилейларына катнашырга Казанның сәнгать коллективлары чакыру ала. Чакыру хаты КПССның Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев исеменә җибәрелә һәм Татарстан Өлкә Советы профсоюзларының рәисе Салих Гарифулла улы Сафинга тапшырыла.

Ул чакта мин Өлкә Советында халык иҗаты эшләрен оештыручы һәм башкаручы өлкән инструктор идем. Салих Гарифуллович Алманиягә барасы коллективларны сайлау һәм хәзерләүне минем өскә йөкләде. Шулай итеп, мин Татарстан халык сәнгатен чит илгә әзерләп алып чыгучы беренче җитәкче булдым. Ассызыклап шуны әйтә алам: 1960-1980 нче еллар – республикабыз халык иҗатының чәчәк аткан чоры. Казан шәһәренең барлык мәдәният сарайларында һәм йортларында башкару осталыгы профессиональ дәрәҗәгә җиткән коллективлар бик күп иде. Җыр жанры буенча Казан шәһәренең Куйбышев исемендәге мәдәният йортының искиткеч музыкаль талантлы Рәфкать Гомәров җитәкчелегендә эшләп килгән, халык арасында бик популяр булган «Саз» җыр ансамблен сайлап алдым. Бию коллективлары арасыннан ТАССРның 10 еллыгы исемендәге мәдәният сараенда эшләп килүче, төрле милләт биюләрен бик оста башкара торган «Юность» халык бию ансамбленә тукталдым. Коллективның җитәкчесе Татарстанның халык артисты Геннадий Скалозубов иде. Шушы ук мәдәният сараеның күп кенә конкурсларда җиңеп чыгып, дәрәҗәле дипломнарга лаек булган Артур Соловьев җитәкчелегендәге инструменталь ансамбле алынды. Беренче баянчыбыз – Әүһәдиев исемендәге музыка училищесы укытучысы Таһир Сөләйманов, икенче баянчыбыз Рәфкать Гомәров иде. Баянчылар төркемен ныгытыр өчен, Казан консерваториясенең баянчылар әзерләү укытучысы Ильяс Шәриповны алырга тәкъдим ясадылар. Ул немец телен дә яхшы гына белә, диделәр. Моның өчен миңа халкыбызның атаклы композиторы, консерватория ректоры Нәҗип Җиһановка керергә туры килде. Сөйләшү барышында ул: «Безнең халык иҗаты чит илләргә алып чыгып күрсәтерлек дәрәҗәдә үстемени?» – дигән сорау бирде. Мин аңа: «Казаныбыз һәм республикабызның күп кенә районнары сәнгать коллективларының башкару осталыгы бик югары дәрәҗәдә», – дип җавап бирдем. Моңа каршы ул, шатлыгын яшермичә: «Бу бик яхшы!» – диде. «Ильяс Шәрипов мәсьәләсенә килгәндә, сезгә ярдәм итү йөзеннән аның чит илгә чыгуына мин каршы түгел», – дип өстәде. Бу өч баянчы Татарстан халкының иң яраткан, иң популяр музыкантлары иде.

Барлык кыенлыкларны җиңеп, 36 кешедән торган коллектив, «Татарстан» поездына утырып, ил башкаласына юл алдык. Мәскәүдәге «Россия» кунакханәсе алдына килеп җиттек. Мин, эчкә кереп: «Безнең сәнгать коллективлары фестивальга кайчан

һәм нинди поезд белән бара икән?» – дип сорадым. Андагы ханым: «Бездә заявка юк!» – дип җавап бирде. Мин үзалдыма: «Инде нишләргә?» – дигән сорау биреп, коридорда туктап калдым. Күзем көзгегә төште. Мин акбур кебек агарынган идем. Бераз уйланып басып торгач, Германиягә алып барасы сувенирлардан яңа гына басылып чыккан юлкүрсәткечне, борылгач, төрле төсләргә керүче Сөембикә манарасы статуэткасын һәм имән бармак кадәр генә чабатаны алып, Евгений Васильевич дип язылган ишекне шакыдым. Ул, башын күтәреп карады да, нәрсәдер ашыга-ашыга язарга тотынды. Мин, сувенирларымны аның алдындагы кечкенә өстәлгә куйдым да көтә башладым. Ул, башын күтәрде дә: «Тыңлыйм Сезне», – диде. Мин: «Сезгә Казан шәһәренең җитәкчеләреннән, халкыннан һәм сәнгать сөючеләреннән зур сәламнәр алып килдем!» – дидем. «Рәхмәт! Казанда булганым бар. Бик истәлекле, тарихи шәһәр». «Менә икенче безнең шәһәребезгә киләсегез булса, кирәкле урыннарыгызны табар өчен дип әле яңа гына чыгарылган путеводитель китабы да Сезгә, – дип, китапны өстәлгә куйдым. – Менә болары Казан шәһәренең Кремле һәм Владимир Ильич Ульянов-Ленин сурәте төшерелгән значоклар. Сөембикә манарасы статуэткасы да Сезгә. Борылгач, ул төрле төскә керә...» – дидем. Евгений Васильевич, сүзләремнең дөреслеген тикшерер өчен, статуэтканы әйләндерә башлады. Аннары: «Чыннан да, төрле төскә керә бит! – дип куйды. – Бу бик үзенчәлекле манара янында булганым бар». Бармак очы хәтле генә чабатаны кесәмнән чыгарып: «Бусы да Сезгә!» – дидем. Ул, чабатаны кулына алды да: «Вот это чудо лапты! Это татары сами плетут?» – дип елмаеп куйды. Мин, чабатаның аңа ошавына куанып: «Әйе!» – дидем. Евгений Васильевич, чабатаны кулында тоткан килеш: «Сез юкка гына кермәгәнсездер, берәр үтенечегез бармы әллә?» – дип сорады. «Үтенеч кенә түгел, бик зур проблемабыз бар! Безнең сәнгать коллективларын концертлар белән Бөек Октябрь бәйрәменә багышланган концерт-конкурска катнашырга чакырып, Алмания Демократик Республикасыннан КПССның Татарстан Өлкә комитетына чакыру хаты килгән. Менә ул имза салынган хат. Әле генә без Казан-Мәскәү поезды белән башкалага килеп төштек. Коллектив әгъзалары кунакханә алдында җыелып тора. Германиягә без нинди поезд белән баруыбызны белергә кергән идем. Безгә бүлек мөдирегез: «Казаннан заявка килмәде, шуңа транспорт та әзерләнмәде», – дип әйтте». Евгений Васильевич, телефон трубкасын алып: «Николай Иванович, Казан коллективларының Германиягә бәйрәм концертларына бару мәсьәләсе ничек тора? Заявканы без Казаннан соңыннан да соратып ала алырбыз. Хәзерге вакытта безнең резервта бик тәҗрибәле проводник белән яхшы вагон бармы? Алайса шул вагонны бүген китәчәк Мәскәү-Париж поездына 21 нче номер белән таксыннар», – дип әмер бирде. Миңа исә: «Поезд китәргә дүрт сәгать кенә вакыт калды. Сез хәзер, җыенып, Белорус вокзалына ашыгыгыз. Концертларыгыз уңышлы үтсен, хәерле юл сезгә!» – диде. Инде чыгарга дип ишеккә барып җиткәч, рәхмәтемне әйтеп, башны борып карасам, ул әле һаман, чабатага сокланып: «Чудо лапты!» – дип утыра иде.

Көн буена туган авырлыкларны хәл итә-итә талчыгып, поезд китәргә 5 минут калганда, үземнең урыныма барып аудым. Поезд әкрен генә безгә таныш булмаган җирләргә кузгалып китте. Мин, барысы да хәерле тәмамлануына куанып: «Аллаһ бар шул!» – дип уйлап куйдым. Поезд тизлеген арттырган саен, шатлыгым зурая бара иде.

Азрак хәл кергәч, егет-кызларның ничек урнашканлыгын тикшереп чыктым. Барысы да канәгать иде. 30-40 минуттан безнең белән танышып өлгергән проводнигыбыз дядя Миша: «Сезгә чәй өлгерттем! Һәрберегез килеп ала аласыз!» – диде. Шул арада баянчыларыбыз матур итеп үзебезнең моңлы татар көйләрен уйнап

җибәрде. Моңарчы күрмәгән шәһәр һәм авылларны, табигатьне карап, поезд туктаган станцияләрдә андагы халык белән аралашып, киосклардан чәй эчәргә тәмле ризыклар алып, Брест шәһәренә килеп җиттек. Дядя Миша безгә: «Хәзер барлык вагоннарның да көпчәкләрен алыштырачаклар. Моңа кимендә алты-җиде сәгать вакыт кирәк булачак. Вокзалдан якын гына Брест крепостенда тарихи музей бар. Аны Кызыл Армия солдатлары актык сулышларына кадәр саклаган. Аларның командиры сезнең татар кешесе майор Петр Гаврилов булган. Сезгә бу музей белән танышырга тәкъдим итәм», – диде.

Музей безне җанны өшетерлек музыка белән каршы алды. Экскурсовод безгә Брест крепостеның төзелү тарихын сөйләде. Кызыл Армия солдатлары дошман илбасарлары белән аяусыз, каһарманнарча сугышып ятканда, дошманның алдынгы хәрби частьлары Мәскәү янына килеп җиткән булалар инде. Ә Брест крепосте дошманга һаман бирешмәгән. Бервакыт крепость эче тынып кала. Фашистлар курка-курка гына эчкә үтәләр. Анда канга баткан, аңнарын югалткан совет солдатлары ята. Немецлар аларны носилкаларга салып, машиналарга төяп, Германия ягына озаталар. Безнең солдатларның командиры булган, дошманга актык сулышларына кадәр бирешмәскә өндәп торган командирларын алып чыгар алдыннан, немец офицеры, үзләренең солдатларын бер сафка тезеп: «Дошманыбызның командирын алып чыгабыз. Сез, ул үткәндә, баш киемнәрегезне салып, башыгызны иеп озатыгыз. Чөнки чын сугыш батыры менә шундый булырга тиеш! Бу – барлык сугышчыларга да үрнәк!» – ди. Бик кызганыч, аны туган илендә колач җәеп каршы алмыйлар. Ул вакытта дәүләте дә, законнары да башка була шул. Аңа туган ягына да кайтырга рөхсәт бирмиләр. Советлар Союзы Герое дигән югары исемне дә озак еллар үткәч кенә ала Петр Гаврилов. Музейдан без бик авыр халәттә кайтып, вагоннарыбызга урнаштык. Шул ук вакытта илебезнең чикләрен фидакярләрчә саклаган каһарманнарыбыз өчен горурлыгыбыз да чиксез зур иде.

Көпчәкләр алышынып беткәч, дядя Миша: «Озакламый Польша чиген узабыз. Барыгыз да паспортларыгызны әзерләгез», – диде. Тәрәзәдән Польша җирләрен карый башладык. Кайбер кеше үз биләмәсендә балалары белән бәрәңге алып маташа, кемдер ат белән җир сукалый, печән чаба, кечкенә тракторы белән йөк ташый. Монда колхозлар юк, ахрысы, дигән фикер туды. Поезд туктаган станцияләрдә поляк халкының сөйләшүен тыңлап, шул тирәдә төзелгән корылмалар белән танышып, безгә таныш булмаган, пластик шешәләргә тутырылган салкын суларны эчеп, киосктан тәмле ризыклар алып, Берлин шәһәренә таба юл тоттык.

Менә без Алманиядә. Егетләр-кызлар барысы да тәрәзәләргә ябырылып, Алмания җирләрен карарга керeште. Бу илнең кечкенә шәһәр һәм авылларын карый-карый, Берлинга якынлашканыбызны сизми дә калганбыз. Без яратып өлгергән дядя Миша: «Егетләр һәм кызлар, ике сәгатьтән Берлинга җитәбез, җыена башларга да була», – дип киңәш бирде.

Мәскәү-Париж поезды Берлин станциясенә туктады. Без төшәргә әзерләндек. Төркемнең җитәкчесе буларак, мин беренче булып төшәргә тиеш. Дядя Миша алдагы ишекне: «Рәхим итегез!» – дип ачып җибәрде. Карасам, безнең вагонга асфальтланган кара платформа җитмәгән. Немецлар бик экономияле халык дип ишеткәнем бар иде һәм дөрес булып чыкты. Әлбәттә, планнан тыш өстәмә вагоннар өчен платформа эшләнмәгән. Астагы балчыклы җиргә метр ярым араны сикерергә туры килде. Мин бию коллективы егетләренә үзләренең костюмнары тутырылган гофрларны һәм авыр ящикларны чыгарырга куштым. Шулвакыт күзем йөгерә-йөгерә килгән кешеләргә төште. Башыма, болар безне каршыларга килгәннәрдер, мөгаен, дигән

Берлин, Александрплац

уй керде. Алар килеп җиттеләр дә аптыраашта калдылар. Мин татарча:

– Егетләр-кызлар, безнең барысы да тәртиптәме? – дип сорадым.

– Тәртиптә!– дип җавап бирделәр.

Безне каршы алырга килгән хатын-кыз урысча:

– Вы откуда и кто вы? – дип эндәште.

Мин:

– Без бик борынгы тарихлы Казан шәһәреннән, Республикабыз – Татарстан, – дидем.

– Сез татарлармы?

– Нигә андый сорау?

– Без татарларны, һаман ат өстендә йөргәч, кәкре аяклы, кыска буйлы, кысык күзлеләр дип уйлаган идек. Ә сез матурларның-матурлары икән.

– Әйе, Идел елгасы буенда яшәгән күпсанлы халыклар арасында казан татарлары иң матурларының берсе. Тырыш, белемле һәм талантлы халык. Безнең концертларны карагач, аның шундый икәненә үзегез дә инанырсыз, – дидем.

Немецлар:

– Very good! – дип, кул чабып алдылар.

– Ә хәзер, мин сезнең белән яшәргә тиешле хезмәткәрләр белән таныштырам, – диде ханым. – Минем исемем Наташа. Мин – тылмач. Менә бу кеше – җитәкчебез Вальтер Кунс. (Тарихтан мәгълүм: Адольф Гитлер Эрнест Тельманны һәм аның ун көрәштәшен аттыра. Алар арасында Вальтерның әтисе дә була.) Шоферыбыз – Карл Никколь. Ә хәзер, кадерле кунакларыбыз, Германия Демократик Республикасының башкаласы Берлинга рәхим итегез! Әнә, мәйданчыкта сезгә дигән ак автобус тора. Сезне Берлинның үзәгендәге Александрплац мәйданына урнашкан күп катлы кунакханәгә урнаштырабыз.

Килеп җитеп, урнаша башладык. Алдан җибәрелгән исемлек буенча һәрберебезгә бүлмәләр билгеләп куелган. Бүлмәләрдә чисталык, ванналар капланган, аларга немецча һәм русча «дезинфицировано» дип язылган. Коллектив җитәкчеләрен һәм немец дусларны ярты сәгатьтән бүлмәмә кереп, алдагы планнар турында сөйләшү өчен, чәй эчәргә чакырдым. Хуҗаларыбыз безгә бик үзенчәлекле һәм кызыклы программалар төзегәннәр иде. Кунакларыбызга Казаннан алып килгән чәй ризыклары, аеруча чәк-чәк ошады. Чәйдән соң, тыныч йокы теләп, бүлмәләргә таралыштык. ■

Чал тарихка бер караш

Марат Хәбибуллин, Татарстанның атказанган артисты

50 нче елларда илебез, сугыш алып килгән хисапсыз җимерүләрне төзәтеп, тыныч тормыш төзүгә җиң сызганып керешә. Әтнә үзешчән театр коллективы да – үсеш, яңалыкка омтылу юлында. Коллектив, классик әсәрләр белән беррәттән, татар һәм рус совет драматургларының яңа гына «табадан төшкән» заманча пьесаларын да сәхнәләштерә. 1950-1955 нче елларда гына коллектив Олы Әтнәдә һәм авылларда «Галиябану», «Тормыш җыры», «Шәмсекамәр», «Икенче фронт артында», «Ил чигендә», «Энҗе бөртекләре», «Якты юл», «Якын дус», «Тапкыр егет», «Көтүченең көтелмәгән кунагы», «Тирән сөрү», «Җәмилә», «Кыз урлау» кебек спектакльләр белән йөзләгән чыгыш ясый.

1952 елда коллектив район смотрында Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» драмасы белән катнашып, беренче урынны ала һәм Мактау грамотасы белән бүләкләнә. «Районда да беренче урынны алмаска инде алар», – дияргә ашыкмагыз. Ул чорда авылларда бик көчле драмколлективлар яшәп, иҗат итеп килгән. Менә 1952 елның 9 февралендә Олы Әтнә радиосы тапшыруында район мәдәният йорты директоры Мөбарәк Сабиров чыгышы (эфирга рөхсәт итеп, редактор В.Бариев һәм тагын бер иптәш текст астына имзаларын куйганнар):

«Үзешчән сәнгать – халык инициативасының гүзәл күренешләренең берсе. Партия һәм Совет хөкүмәтенең көндәлек кайгыртуы нәтиҗәсендә, ул көннән-көн үсә, күтәрелә бара. Менә бер ай инде авылларда үзешчән сәнгать көчләренә смотрлар уздырыла. Авылларда уздырылган смотрларда үзләренең оештыручанлыкларын яхшы итеп күрсәтә алган коллективлар район смотрында катнашу хокукын алдылар.

Район смотры 10 февральдән башлап 23 февральгә кадәр дәвам итәчәк... Смотрга Бәрәзә коллективы Гамир Насрыйның «Күңел дәфтәре» һәм зур концерт белән, Мәңгәр авылы коллективы зур концерт һәм «Путевка» исемле пьеса белән, Киме коллективы – Р.Ишморатның «Кайту», Иске Кишет – «Күңел дәфтәре», Күәм – Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», Кече Әтнә коллективы Ш.Зәйнинең «Энҗе бөртекләре» спектакльләре белән һәм башка коллективлар бер-ике пәрдәлек пьесалар һәм концерт белән катнаша.

«Тормыш җыры» пьесасы сәхнәгә бүген, ягъни 9 февраль көнне куела. Бөек Ватан сугышы елларында республикабыз колхозчыларының героик хезмәтләрен чагылдырган бу спектакльнең баш рольләрен драмколлективның күренекле членнарыннан берсе булган Хәбибуллина Разия, Сибгатуллина Галимә, Хәсәнова Зәкия, Хәнәфиева Маһинур, Әхмәтов Вәли, Сәйфуллин Гадел, Хәкимов Вәли, Мөхәммәтшин Виуль, Сабиров Мөбарәк, Сираҗиев Абдул һәм башка иптәшләр башкаралар.

Һич шик юк, үзешчән сәнгать көчләренә уздырыла торган бу смотр районыбызда үзешчән сәнгать эшен тагын да югарырак күтәрүдә, киңрәк җәелдерүдә бик зур роль уйнар, авылларда, бигрәк тә район үзәгендәге хезмәт ияләре арасыннан яңа талантлар килеп чыгуга ярдәм итәр».

Нинди театраль җанлылык бит, ә!..

«Соңгы 1956-1957 нче елларда коллек-

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2021 ел) санында.

«Гөлзадә» (Р.Ишморат әсәре) спектакленнән бер күренеш. 1958 ел

тив эшен тагын да яхшыртты», – дип язылган «7 декабрь 1958 ел» датасы белән «Район культура бүлеге мөдире өчен (Х.Гәрәев)» дип имзаланган «Әтнә район Советы Башкарма комитетының Культура бүлеге тарафыннан Бәдри Җиһаншин исемендәге Әтнә район Культура йорты үзешчән театр коллективына» бирелгән характеристикада. – *Район Культура йорты һәм авыл клублары сәхнәләрендә «Үрнәк адымнар», «Бай кияү», «Зәңгәр шәл», «Американ», «Язылмаган законнар», «Яшел эшләпә», «Яшьләр алдатмыйлар», «Гөлзадә», «Кияү бакканда», «Чуен багана», «Өйләнгәнне өйләндерү», «Үзебез гаепле», «Казан сөлгесе», «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Фирая», «Өйрәнелгән гадәт буенча», «Гөлчәчәк», «Сәер мәхәббәт», «Беренче театр» һ.б. пьесаларны коллектив 112 мәртәбә куйды. 1958 елның башында район смотрында коллектив К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» дигән мелодрамасы белән катнашып югары бәя алды, Почет грамотасы белән бүләкләнде, барлык катнашучылар кыйммәтле бүләкләр, Почет грамоталары белән бүләкләнделәр. Бу спектакльгә тамашачылар конференциясе үткәрелде, чыгып сөйләүчеләр уйнаучыларга югары бәя бирделәр.*

Хәзерге көнне коллектив Ш.Әблиевнең «Шәмсекамәр» дигән драмасы өстендә эшли. Коллективның җитәкчесе – район культура йорты директоры М.Сабиров. Составта 30дан артык член бар.

Югарыда күрсәтелгәннәрдән чыгып, район Культура бүлеге бу коллективны республика оешмалары алдында бүләкләтү мәсьәләсен Район Советы Башкарма комитеты һәм КПСС райкомы карамагына кертә».

Бу чорда театр тарихында Кәрим Тинчурин әсәрләре аеруча зур урын алып тора. Шәхес культы чорында театр репертуарларыннан төшерелеп торган Тинчурин әсәрләре 1956 елны яңадан сәхнәгә менәләр. «Зәңгәр шәл» мелодрамасы, «Казан сөлгесе» музыкаль комедиясе, «Американ» пьесаларын сәхнәләштергәндә коллективның иҗади мөмкинлекләре тагын да тулырак ачыла, тамашачы бу спектакльләрне алкышлап каршы ала.

Драматургиягә – сәхнә әсәрләренә кытлык кичермәгән ул заманда театраль экспериментлардан да читләшмәгән Әтнә үзешчән театры! Мисал өчен, Николай Васильевич Гогольнең «Үле җаннар»ы буенча Мөбарәк Сабиров эшләгән инсценировканы, Александр Сергеевич Пушкинның тууына 150 ел тулу уңаеннан сәхнәләштергән «Алтын балык турында әкият»не атарга була.

Һәвәскәр артистлардан Разия Хәбибуллина, Гариф Төхфәтуллин, Маһинур Хәнәфиева, Зәкия Хәсәнова, Зөмәрә Мостафина, Фәрит Габидуллин,

Вәли Әхмәтов, Мөбарәк Сабиров, Софья Баязитова, Җәүһәр Шакирова, Бәнәнә Әхмәрова, Ләлә Таҗетдинова, Җәмилә Муллахмәтова, Кәүсәрия Миңлекаева, Зәкия Шакирова, Булат Бәширов, Гадел Сафиуллин, Фоадия Зарипова, Галимә Сибгатуллина, Вәли Хәкимов, Виуль Мөхәммәтшин, Фоат Фазлыев, Әхәт Маликов, Сергей Котельников, Кәримә Гайнетдинова, Тәскирә Садыйкова, Роза Шакирова, Җәүһәрия Хәйруллина, Абдулла Хәлиуллин, Револь Мөхтәров, Кәрим Гайнуллин, Каюм Баязитов, Фатыйма Сәфәргалиева, Мөбарәк Хәсәнов, Фердинант Сафин, Энгель Гарипов, Айдар Әхмәдуллин, Хәлимә Мәҗитова, Наил Сабиров, Наилә Әскәрова, Фәния Шакирова, Диләрә Садриева, Тарзан Баязитов, Равил Сабирҗанов, Илгиз Кадыйров, Римма Галиәхмәтова, Дамирә Билалова, Светлана Шиһапова, Роберт Баязитов һәм башка һәвәскәр артистларның уйнауларын тамашачы һәрвакыт җылы каршылый.

1945 елдан 1958 елга кадәр коллектив 100гә якын пьесаны Әтнәдә һәм авылларда 400ләп тапкыр куя, 70 меңнән артык тамашачыга хезмәт күрсәтә. Район һәм өлкә газеталарында уңай рецензияләр басыла. Тамашачылар да начар бәя бирми. Һәр өйрәнгән пьесаны кимендә өч мәртәбә Олы Әтнәдә кую, һәр куйганда клубның халык белән шыгырым тулы булуы халыкның үз һәвәскәр артистларын ничек яратканлыгын раслый. Бу елларда генераль репетицияләр һәм куелган спектакльләрдән соң тамашачылар белән фикер алышу матур гадәткә керә. Дөрес, гадәте матур булса да, спектакльдән соң туган фикерләрен бизәп тормыйлар, уйлаганны ярып салалар тамашачылар, ошамаган урыннарны, яшереп тормыйча, тәнкыйтьлиләр. Коры сүз генә булып калмасын өчен, бер документны тулысы белән китерәбез:

«2 март 1958 елда Район культура йортында «Зәңгәр шәл» мелодрамасына карата уздырылган конференциядә тамашачыларның фикерләре.

1. Вәлеева Банат:

«5 нче пәрдәдә Заһидә белән Мәйсәрә очрашкан вакытта Мәйсәрә Заһидәгә бик кычкырып дәшә».

2. Искәндәров:

«Уйнаучылар арасында тотлыгып торулар бар. Суфлерсыз уйнасалар әйбәт булыр иде».

3. Ибраһимова Сания:

«Мәйсәрә кыр казларын искә алып җырлаганда кыр казларының очып барганын тамашачыларга җиткерми. Җырлаганда өскә карап җырласа әйбәт булыр иде.

Булат Мәйсәрә белән сөйләшкәндә, Мәйсәрәгә булган мәхәббәте җитеп бетми».

4. Шакирова Җәүһәр:

«Күп мәртәбәләр куелуга карамастан, суфлерсыз өйрәнү каралмаган. Заһидә узган елга караганда сүрәнрәк. 4 нче пәрдәдә егетләр урынсыз сүзләр әйтеп куялар».

5. Нәҗипова Галия:

«Музыка белән Мәйсәрәнең җырлавы бергә бармый. Әллә Мәйсәрә соңга кала, әллә баянист ашыга».

6. Шакирова В.:

«Егетләр, кызлар янына кергәндә, сүзләрне сүлпәнрәк әйтәләр. Булат барлык егетләр һәм кызлар белән күрешмәде. Конфетны ыргытып кына тора. Кое янында таһарәт алу бер дә ярамый. Сәхнәдә кое бер артык нәрсә булды. Коега утырып сөйләшү бер дә килешми. 2 нче пәрдәдә яктылык мәсьәләсе хәл ителмәгән».

Ул елларда Әтнә халкы театрга шәһәр кешесеннән ешрак йөргән шул. Спектакльләрне дә тәмен белеп, ләззәтләнеп караганнар, кимчелекләрне дә профессиональ тәнкыйтьчеләрдән остарак «әләктереп алганнар». Гомумән, урыс әйтмешли, «грамотный зритель» булганнар. Менә шундый кырыс тамашачы фикере «наждагында» эшкәртелеп торган театр ничек балкымасын инде?!

30 нчы елларда Г.Камал, К.Тинчурин

Мөбарәк Хәсәнов

кебек корифейлар белән иҗади дуслыктан башланган элемтәләр ныгыганнан-ныгый бара. Коллектив драматурглар белән аралашып яши. Драматург Юныс Әминев белән элемтәләр аеруча тыгыз була. Ул эчтәлеге, декорациясе, уйнаучылар саны һәм бүтән яклардан бик уңай булган пьесаларын җибәреп тора, театрның шул еллардагы җитәкчесе Мөбарәк Сабиров белән хат алыша. Бер хатында драматург болай дип яза:

«...Сезнең уңышларыгызга мин чын күңелдән шат. Үзегезгә, Фазлыев, Садыйкова, Нәҗипова, Сибгатуллина, Кадыйров иптәшләргә, гомумән, бөтен коллективка минем кайнар сәламемне тапшырыгыз. Район газетасындагы рецензияне укып чыктым. Рецензия авторы, нигездә, уйнаучы иптәшләрнең үз рольләрен ничек башкаруларына тукталган.

Район газетасының драмколлективка шактый урын бирүе зур игътибарга лаек. Шулай да газета әсәрдәге кимчелекләргә дә берничә юл гына булса да багышласа, тагын да күңеллерәк булыр иде.

Аннан соң, Д.Андреевна ролен башкаручы иптәшнең сүлпәнлеген уйнаучы кимчелеге итеп кенә түгел, автор буларак минем үз кимчелегем итеп карау дөресрәк булмас идеме икән?!.

Ифрат Хисамовка миннән зур рәхмәт һәм күп сәлам... Зур мәшәкать санамасагыз, ноталарның нөсхәсен җибәрегезче. «Язгы җилкәй...»нең нотасын мин, Минзәләгә баргач, Сезгә җибәрермен. Кызыксынган иптәшләр карарлар.

Хатыгызда күрсәткән кимчелекләрнең (пьесага карата) кайберләрен, чыннан да, төзәтергә кирәк, ләкин, кызганычка каршы, хатыгызны соң алдым, ә «Гөлчәчәк» исә «Сов. әдәб.» №10 басылып чыга... Әгәр әсәргә тагын бер мәртәбә басылу бәхете бирелсә, Сезнең фикерләрне, һичшиксез, искә алачакмын.

Хәзер Минзәлә театрында «Тамырлар» исемле сатирик комедиям бара. Комедиягә теләгегез булса, хәбәр итәрсез. Җибәрергә тырышырмын. Көйләрен Аллаһияр Вәлиуллин язган...

Эшегездә уңышлар теләп, тирән ихтирам белән, һәрвакыт сезнең Юныс Әминев. 13 окт. 1958».

Ә менә Юныс Әминев, «Тамырлар» комедиясен Әтнәгә җибәреп, Мөбарәк агага тагын хат юллый:

«...Хатыгызга бик озак җавап бирмәдем, чөнки «Тамырлар»ның машинкадан чыккан нөсхәсе юк иде, ә коры хаттан Сезнең канәгать булмасыгызны белә идем.

«Гөлчәчәк» турында. Газетадагы тәнкыйть дөрес. Аның нигезендә яңадан төзәтеп эшләдем. Ни хәл итәсең, шулай егыла-егыла тәпи йөрергә өйрәнәсең инде...

«Тамырлар»ның финалы ике вариантта, теләгәнен сайлагыз: берсенә дә каршы түгел (әгәр куйсагыз).

Җәен укытучыларның белемен күтәрү институтына Казанга бер айга барам. Сезнең район культура йорты автономиядә иң яхшы исәптә, болай гади генә кызыксынып, бәлки, Әтнәгә үк барып чыгармын...»

Әдип ике хатында искә алган газета язмасы да архивта сакланган... ■

Татарстанның халык артисткасы Флюра апа Сөләймановaның татар халык җыры «Урманнарда йөрдем»не җырлавын әбием мөкиббән китеп тыңлый иде. Атна саен «стена радиосы»ннан яңгыраган ял концертлары минем балачагыма да эләкте бит. Җырның «Урманнарда йөрдем берьялгызым Баласын җуйган болан эзеннән» дигән җирендә әбием: «Бик авыр шул ул баланы җую», – дип куя һәм миңа, сабыйга, бик моңлы тавыш белән җырлаучы апа да, баласын югалтып, аны таба алмыйдыр кебек тоела иде. Җыр бит ярату, хыянәт турында, ләкин минем өчен ул балачагымнан «баласын җуйган болан» турында булып калды инде.

Флюра апа белән миңа 90 нчы елларда гастрольгә чыгу, аның тавышындагы күңелгә ятышлы йомшак бормаларны сәхнә артында да йотлыгып тыңлау насыйп булды. Аннан инде, Филармониядә эшли башлагач, мәшһүр җырчылар белән якыннан аралашу, бәйрәмнәр, вакыйгаларга бәйле даталар белән тәбрикләү, аларны якын кешеләрем, коллегаларым итеп ярату. Мин үзем моны бәхет дим. Шулай да ул!

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

«Радиода эшләгәндә, җырлавымны сорап, көн саен берничә хат килә иде. Ул елларда инде Филармониянең лекторий бүлеге белән авыл-шәһәрләргә концертлар куярга да чыга башладым. Бер программабыз Җәүдәт Фәйзи иҗатына багышланды. Кайда гына чыгыш ясамыйк, концерт тәмамлангач, залдан: «Флюра Сөләйманова «Кыр казлары»н җырласын әле», – дигән үтенечләр ява. Һәр концертта «Кыр казлары»н сорагач, Җәүдәт абый үпкәләгән. Көндәлегенә: «Әнвәр Бакиров кына композитор, мин композитор түгел икән», – дип язып куйган. Самими, бала күңелле шәхесләр белән эшләдек...»

Флюра Сөләйманова, Җәүдәт Фәйзи һәм Булат Балтанов Казан шәһәренең 94 нче урта мәктәбе укучылары белән. 1972 ел

Җәүдәт Фәйзи һәм Флюра Сөләйманова. 1967 ел

«Мин дүрт бала белән тол калган иргә кияүгә чыктым. Ирем Габделхак балаларга: «Әни дип әйтәсез», – дип, бик каты торса да, мин: «Әни бер генә була ул, ирексезләмик», – дидем. Вакыты җиткәч, мине якын кешеләре итеп кабул иткәч, балаларым үзләре үк, «әни», диделәр. Хәзер оныклар «дәү әни» дип эндәшәләр. Аларның шатлыгына сөенеп, хәсрәтләнсәләр – йөрәгемнән уздырып яшим. Ирем Габделхак, өлкән улым Марат вафат булды. Булатым, олы кызым Алсу, Маратымның игезәк сыңары Әлфия – барыбыз да бу хәлләрне бик авыр кичердек».

Флюра Сөләйманова ире Габделхак белән

Беренче рәттә (сулдан уңга): Р.Шакирова, Флюра Сөләйманова, Сәүбән Шәрифҗанов. Икенче рәттә: Хәй Мушинский, Ләлә Вахитова, Динә Сираҗетдинова, Усман Әлмиев.

«Ульяновск өлкәсендә Татарстанның халык артисты Усман ага Әлмиев җитәкләгән татар артистлары концерт бригадасында берничә ел эшләдем. Соңрак инде «Татарстан» радиосына эшкә урнаштым».

«Илһамият» клубы концерты

«Филармония – минем яшәү рәвешем». Бу хакта тулырак видеоязмада.

2017 елда Татар дәүләт филармониясенең 80 еллык юбилеена багышлап «Минем Филармониям» видео-циклын оештырган идем. Әлеге проектта катнашучы шәхесләр ул чакта үзләренең язмышында Филармониянең роле турында сөйләделәр һәм иҗади күчтәнәч бүләк иттеләр.

«Филармония – минем яшәү рәвешем, яшәвемнең мәгънәсе ул. Бераз сырхаулап китеп, зарлангандай итсәм дә, балаларым: «Терелер өчен сиңа бер концерт җитә инде», – дип шаярталар».

Флюра апа ул язмада шулай ди. Бүләк иткән җыры:

«Тормыш көзем җитте, ә шулай да
Алда әле гомер бар кебек...» –

дип тәмамлана.

Гомерегез озын булсын. Бик яратабыз Сезне, Флюра апа!

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Әллүки» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Әллүки

(Татар халык көе, Г.Тукай сүзләре)

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый,
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен,
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызылып-сызылып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлып тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, – диде, – «Әллүки!»

Мәшһүребез Г.Тукай 1909 елда «Милли моңнар» шигырен яза һәм шул ук елда аны «Әдәбият» исемле җыентыгында бастыра.

«Халык әдәбияты» лекциясендә ул бу шигырен «халык җырларына тәкълид уларак» (ягъни ияреп) язуын әйтә. Аны «сонгый җырулар» төркеменә кертә. «Бу

«соңгый җырулар» халыкның үз рухынча, үз формасынча, үз вәзене (ягъни үлчәме) белән язылгандыр. Шуңар күрә боларны «Зиләйлүк» вә «Әллүки» көйләренә туп-тугры җырлап була», – ди.

Күңелнең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек көй! Тукай әйткәнчә, зарлы, моңлы көй. Гүя татар тарихын, аның үткәндәге фаҗигале язмышын чагылдыра ул. Көйнең кайчан язылуы турында төгәл мәгълүмат юк. Әмма «Милли моңнар» шигыре басылып чыкканнан соң, бу көй Тукаебыз сүзләренә җырлана башлый.

«Милли моңнар» шигыренең язылу тарихы турында әдип Мөхәммәт Гали (1893-1952) болай ди: *«Көннәрнең берендә Тукай, «Болгар» номерларында үз бүлмәсендә утырганда, бик матур бер җыр ишетә. Ул вакытта бик сирәк җырланган көй булганлыктан, Тукай бүй көйнең нинди булганлыгын да тиз генә аңлап җитә алмый. Коридорга чыгып, ишеге ярык кына калдырып ачылган бер бүлмәгә килеп туктый һәм, аның ишек яңагына башын куеп, тирән уйларга калып, бүлмә эченнән килгән җырны тыңларга кереша. Ул бүлмә Сәгыйть Рәмиев бүлмәсе булып чыга. «Әллүки» көен җырлаучы кеше дә ул була. Башка вакытта Сәгыйть белән күбрәк шаярып сөйләшергә яраткан Тукай бик җитди кыяфәт белән аның бүлмәсенә керә дә:*

– Әйт, туган, нинди көй бу? Ул минем аяк буыннарыма китте, – ди.

Сәгыйть, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:

– Нигә, белмисеңмени, «Әллүки» ич! – ди.

Шуннан соң Тукай, үзенең «Милли моңнар» шигырен язып, аны Сәгыйтьтән «Әллүки» көенә җырлата һәм үзе дә аны шул көйгә яки «Зиләйлүк» көенә салып җырлап йөри».

«Әллүки»не иң беренче башкаручы 1937 елда Казанда барлыкка килгән Җыр һәм бию ансамбленең солисткасы Разия Тимерханова була. Совет чорында бу җыр Г.Сөләйманова, И.Шакиров һәм Ф.Кудашева башкаруында еш яңгырады. Бүген дә җырчыларыбыз З.Сәхәбиева, И.Газиев, В.Ганиева, Х.Гыйльфанов, Ә.Нургалиев, С.Мөхәммәтҗанова аны бик теләп, зур осталык белән башкара.



Г.Тукай, С.Рәмиев һәм Ф.Агиев. Казан, 1908 ел

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ГАФАР ҖАФЕР (1898-1938)

Укытучы-остаз. Кырымдагы Тау-Даир авылында мулла гаиләсендә туган.

Җаферны 1936 елда, «милләтче контрреволюционер» дигән ярлык тагып, зинданга ташлыйлар. Аны ике ел буена урта гасырлардагы вәхшиләр җәберләгән кебек җәзалыйлар. Аннан соң атып үтерәләр.

ГЫЙЗ-ӘЛ ГАБИД (1918-1955)

Татар шагыйре. Оренбург өлкәсенең Тоцк төбәгендәге Хөсәен авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туган.

Офицер буларак, ул гаскәрдә хезмәт итә һәм Норвегиягә кадәр барып җитә. Фашистларны җиңгәч, Ерак Көнчыгышта, Манчжуриядә, Төньяк Кореяда японнарга каршы сугыша. Бик күп җәрәхәтләр ала, шул яралардан ул 1955 елда 37 яшендә вафат була.

ГӘРӘЙ ШАМИЛ (1918-1946)

Татар язучысы. Казанда хезмәткәр гаиләсендә туган.

Мәскәү өчен барган сугышта катнаша, чолганышта калып, фашистларга әсирлеккә эләгә, аннан котылгач, 1946 елның 22 мартында Польшаның Гливице шәһәрендә әсирлектә булганнарны тикшерү лагеренда үлә.

ГОБӘЙДИ ДАВЫТ (1873-1919)

Татар шагыйре. Татарстанның Әгерҗе төбәгендәге Кыдырлы авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

1911 елда патша жандармериясе Иж-Буби мәдрәсәсен тар-мар китерә. Мөгаллимнәрне, шәкертләрне, шул исәптән Давыт Гобәйдине дә кулга алалар. Соңрак аны иреккә чыгаралар, ләкин күзәтү астында тоталар.

1919 елда авылга аклар басып керә, Совет яклыларның барысын да, шул исәптән Гобәйдине дә җәзалап үтерәләр.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ГАЯЗ МАНСУР (1917-1943)

Татар шагыйре. Мари АССРның Бәрәңге авылында туган.

1943 елның 19 ноябрендә Витебск өлкәсенең Усково авылы өчен барган каты сугышта Мансур Гаяз батырларча һәлак була.

ГОБӘЙДУЛЛИН ГАЗИЗ (1887-1938)

Татар тарихчысы, профессор, тарих фәннәре докторы. Казанда бай сәүдәгәр гаиләсендә туган.

1937 елда «халык дошманы» дип кулга алына. 1938 елда, «Өчлек суды» ясап, аны үлемгә хөкем итәләр. Хөкем карары шул көнне үк үтәлә. Кабересенең кайдалыгы билгеле түгел.

ГИРАЙБАЙ АМДИ (1901-1930)

Кырымтатар шагыйре. Укытучы һәм җәмәгать эшлеклесе. Кырымда Яңа Кала авылында мулла гаиләсендә туган. Төркиядә белем алган.

Татарларга каршы, «сәяси эш» кузгатып, 1928 елда Гирайбай кулга алына һәм 1930 елның 13 сентябрендә Мәскәүдә Бутырка зинданында атып үтерелә. Кабере билгесез.



ГЫЙЛЬМИ ЛӘБИБ (1906-1938)

Татар язучысы. Татарстанның Әлмәт төбәгендәге Иске Баграж авылында игенче гаиләсендә туган.

1937 елның 21 сентябрендә, ялган гаеп тагып, Ләбибне төрмәгә утырталар. Ул 1938 елның 9 маенда, 32 яшендә, атып үтерелә.

Текстны басмага ***Рабит Батулла*** *әзерләде.*

Безнең мирас №4 апрель 2021

Истә, һаман да истә!

Язучы
Сәрвәр Әдһәмованың
тууына 120 ел

Язучы, тәрҗемәче, 1945 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова 1901 елның 5 апрелендә элекке Оренбург губернасының (хәзерге Чиләбе өлкәсе) Троицк шәһәрендә туган.

Ул 1920-1923 нче елларда Томск университетының медицина факультетында укый. 1923 елда Казанга килә. Сәрвәр Әдһәмованың тәүге әсәре – «Авыл тормышыннан бер күренеш» пьесасы (ул 1924 елда аерым китап булып басылып чыга).

С.Әдһәмова 1938 елда нахакка репрессияләнә, 1940 елда аклана. Ире – язучы Кави Нәҗми (1901-1957), улы – радиофизик Тансык Нәҗметдинов (1927-2008).

Л.Толстойның «Балдан соң», «Кавказ әсире», Н.Тихоновның «Сугыш», М.Горькийның «Балачак», «Малайлыкта», «Минем университетларым», «Фома Гордеев», «Артомоновлар эше», Д.Дефоның «Робинзон Крузо», М.Әуэзовның «Абай» әсәрләре, А.П.Чеховның аерым хикәяләре С.Әдһәмова тәрҗемәсендә дөнья күрде. Ул – «Тормыш сынавы» дигән истәлекләр китабы авторы.

С.Әдһәмова 1978 елның 10 ноябрендә Казанда вафат булды.

Сынчы
Рада Нигъмәтуллинаның
тууына 90 ел

Скульптор, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1984), Татарстанның халык рәссамы (2002), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2007), РФнең атказанган рәссамы, СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971) Рада Хөсәен кызы Нигъмәтуллина 1931 елның 14 апрелендә Казанда туган.

Ул, Казандагы 80 нче (1934-1940 нчы елларда 1 нче) мәктәпне тәмамлагач, башта – Казан сәнгать училищесын (1954), аннары И.Е.Репин исемендәге Ленинград сәнгать, скульптура һәм архитектура институтын (1960) тәмамлый. Диплом эшен («Миләшкәй») «бишле»гә эшли. Остазлары – М.Анушкин, С.Ахун.

Р.Нигъмәтуллинаның кайбер хезмәтләре: «Уеннан уймак», «Беренче сыйныфлар», «Апуш», «Әллүки», «Сара Садыйкова», «Сөембикә» һ.б.

Р.Нигъмәтуллина 2019 елның 12 октябрендә Яшел Үзән районының Васильево бистәсендә вафат булды.

Шагыйрь
Рәшит Әхмәтҗановның
туына 80 ел



Күренекле шагыйрь, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), татар милли хәрәкәте активисты, 1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗанов 1941 елның 14 апрелендә Татарстанның Баулы районындагы Татар Кандызы авылында туган.

Шагыйрьнең «Хыялларым үзем белән» дигән тәүге җыентыгы 1965 елда дөнья күрә. 1957-1958 нче елларда ул Бөгелмәдә төзүчеләр әзерләү училищесында укый, аны тәмамлагач, нефть районнарында һәм Әлмәт шәһәрендәге төзү оешмаларында ташчы булып эшли. Р.Әхмәтҗанов 1961-1964 нче елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1969-1980 нче елларда ул – башта Татарстан АССР Мәдәният министрлыгында сәнгать эшләре буенча инспектор (1969-1974), аннары «Яшь ленинчы» һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында, соңыннан «Казан утлары»нда әдәби хезмәткәр вазыйфасын башкара.

Р.Әхмәтҗановның кайбер китаплары: «Ак канатлар» (1972), «Гомер чишмәсе» (1976), «Алмалы җәй» (1979), «Җан яктысы» (1980).

Ул 1995 елның 5 гыйнварында Казанда вафат булды.

Шагыйрь
Рәшит Гәрәйнең
туына 90 ел

Шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981), 1960 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Рәшит Гәрәй (Рәшит Гәрәй улы Гәрәев) Татарстанның Минзәлә районындагы Малтабар авылында туган.

1948-1950 нче елларда ул Минзәлә районының Иске Мәлкән һәм Чебенле җидееллык мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

Аның «Беренче хисләр» дигән тәүге җыентыгы 1952 елда дөнья күрә. Шуннан соң шагыйрьнең «Шинель җылысы», «Җырчы камышлар», «Җырлап яшәр чагыбыз», «Һаваларда йолдыз», «Рәхмәт сезгә», «Төнге учаклар», «Сиңа тартыла күңел», «Юлдашым булсаң иде», «Үзеңә чакыр мине», «Синдә калам», «Көнбагышлар чәчәктә» китаплары һ.б. әсәрләре басылып чыкты.

Р.Гәрәй 1999 елның 22 июнендә туган авылы Малтабарда вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Меңләгән кешенең әңгәмәдәше һәм сердәше

Фәрһад Бәхтияри

Рина Зарипова. 1990 нчы еллар башы. ***Евгений Канаев фотосы***

Яшь буынны тәрбияләүдә 1990 нчы елларда тиражы хәтта 300 мең данәгә җиткән «Татарстан яшьләре» газетасының роле гаять зур. Аларның яшәеше бу басма белән тыгыз бәйләнештә булган: күпме яшь шагыйрь, язучы, журналист – хәзер инде мәшһүр каләм осталары һәм остазлар – үзләренең иҗат юлын нәкъ менә «Татарстан яшьләре» аша тапкан. Ул яшь буынны тәрбияләгән дә, илһамландырган да. Язмам исә 1973-2002 нче елларда мәшһүр газетаның хатлар бүлеген җитәкләгән журналист Рина Зарипова (1941-2008) турында.

Тәкый һәм Рөстәм Зәкиевләр төзегән шәҗәрәгә мөрәҗәгать итсәк, Рина Зарипованың бабасы Шаһиарслан һәм аның дүрт буын бабалары Әҗәкүл һәм Иске Балтач авылларында указлы мулла вазыйфасын үтиләр. Инкыйлабтан соң, аларның нигезе таратылган: 1918 елның кышында бабасы вафат булса, 1930 елда – әбисе һәм 1936-1937 нче елларда әтисенең бертуганнары репрессия золымына дучар ителәләр. Рина Зарипова гаиләсенең Актаныш районы буенча туктаусыз күченеп йөрүе күбесенчә шуннан гыйбарәттер дә инде. Ата-аналар – ихлас коммунистлар, укытучылар. Сугыштан кайткач, фирка әһеле буларак, аталары Фәтхелбаян мәктәп

директоры итеп билгеләнә. Әмма әлеге бәхетле елларга кадәр җиде балалы ишле гаиләдә әтисез ачлы-туклы балачак та булган, соңгы сигезенче бала сугыштан соң туган. Моннан соң Рина Зарипова, бер яктан – шигырьләргә, хыялларга омтылуы, икенче яктан – ул хыялларның чынбарлыкка бәрелеп чәлпәрәмә килүе белән бәйле яшьлегенә аяк баса:

«Аһ, бу вакыт тиз дә үтә инде,
Уйлап торсаң, исең китәрлек;
Һәр үткәне истәлекләр тулы,
Гомерең буйларына җитәрлек.

Менә Идел. Аның яры буйлап
Яшь агачлар шаулап үсәләр;
Зәңгәр ефәк җәйгән күк йөзендә
Ак болытлар йөзеп үтәләр.

Әнә анда, моннан бик еракта
Көтү йөри хәтфә аланда.
Күптән үттем, бар да элеккечә,
Үзгәрмәгән берни һаман да.

*24.05.64. Метеор, Идел буйлап»**

Медицина институтына укырга керү хыялының тормышка ашмавы, Пермь фанер комбинатында ике ел сменалы йокысыз эш (1958-1960), Алабуга педагогия институты (1960-1965), Татар Сараланына (1964-1967), Кече Елгага (1967-1968), институт тәмамлагач, укытырга җибәрелү, Заһит Зарипов белән гаилә кору (1966), Казан шәһәрендәге китапханәдә эшләп алу (1968) һәм «Татарстан яшьләре» (1973-2002), – аның гомер юлын кыскача шулай билгеләп була.

1968 елның җәендә Зариповлар гаиләсе Казанга күченә. Рина Зарипованың язу теле шома булса да, язмалары бу вакыткача төрле газеталарда басылып килсә дә (укучы Ринаның беренче шигыре 1958 елның 25 июлендә дөнья күрә), Казан берәүгне дә колач җәеп көтеп тормый бит: рус-татар филологиясе факультетын тәмамлаучылар гаять күп, шуңа андый белгечләргә кытлык юк, өстәвенә, кулында бер яшьлек сабые… Хәтта китапханәгә дә зур авырлыклар белән генә эшкә алалар. Һәм ул анда ярты ел хезмәт куя. «Татарстан яшьләре»ндә эшләү чорына юл ачуда фамилиядәш журналист Хәмзә Зарипов ярдәм күрсәтә. Ринаның «Татарстан яшьләре» газетасына мәхәббәте, бер яктан, Татар Сараланы укучыларыннан күчкән булса, икенче яктан, иҗат дәрәҗәсенә күтәрелгән укытучы эшенә тартылуыннандыр, мөгаен. Ул – яшь буынны, ә яңа саф омтылышларга бай яшь буын аны тәрбияли. Бу карашка Рина Зарипова гомере буе тугры иде. 1970 нче еллардагы газета тегелмәләрен күзәтсәк, тәрҗемә мәкаләләренең гаять күп булуын күрербез. Рина Зарипова да башта – тәҗрибәле журналист Суфия Әхмәтованың ярдәмчесе, тәрҗемәче була, ә 1973 елдан, мөхәррир Җәүдәт Кәлимуллин фатихасы белән, хатлар бүлегенең җитәкчесе итеп билгеләнә.

Хатлар бүлеге ул – газета белән укучы арасындагы бәйләнешнең төп буыны. Газета укучысының мәхәббәтен яулауда 1965 елда Суфия Әхмәтова тарафыннан ачылган

* Рина Зарипова дәфтәреннән.

Алабуга педагогия институтын 1965 елда тәмамлаучыларның укытучылары белән очрашуы

«Сердәш» сәхифәсенең роле зур була. Моңа кадәр беркемгә дә сөйләмәгән серләрен укучы аның белән уртаклаша.

Рина Зарипова гомерен шушы газетага, төгәлрәге, аның укучыларына багышлады, дисәм, ялгышмамдыр, мөгаен. Аның, йокыларын калдырып, хатлар укып, мәкаләләр язуына, яшьрәк буын вәкиле булсам да, балачагымнан ук шаһит. Рина Зарипова сайлаган журналист һөнәре үз эченә шул ук укытучы, тәрбияче, психолог вазыйфаларын ала. Татар җәмгыятендә шундый журналистларның барлыкка килүе ул – заман таләбе. Бу уңайдан Рина Зарипованың үз сүзләре исемә төшә: *«Игелек-шәфкать дигәннән, халыкта борын-борыннан килгән матур традицияләрне, йолаларны югалтмаска иде безгә».*

1982 елда «Татарстан яшьләре»ндә бастырылган һәм шулардан сайлап алынган мәкаләләрнең кечкенә бер тупланмасы «Гаилә җылысы» исемле китап булып дөнья күрә. Төрле тормыш мизгелләрен тасвирлаган әлеге җыентыкны ачсак, ачы хакыйкать мисалларына тап булабыз. Кайвакытта ал да гөл булып тоелган хәл һич көтелмәгән дәвамын таба, шуннан соң бу вакыйга автор тарафыннан тирәнтен тикшерелеп, сәбәпләре ачыклана һәм хикмәтле бер йомгак белән тәмамлана. Аны Мөхәммәт Мәһдиев, Мәдинә Маликова кебек күренекле язучыларыбызның әсәрләредәй йотлыгып укырлык. Китапның керешендә, аның барлыкка килүенә төп сәбәп – укучы хатлары, дип искәртелсә дә, нигезендә, моннан тыш, автор тарафыннан өйрәнелгән фәнни әдәбият та, үтә дә бай шәхси кичерешләр дә ята. Хәлбуки, бу китап гыйльми телдә язылмаган, максаты да кешегә акыл өйрәтү түгел, ә гомумкешелек кыйммәтләрен ачу.

Рина Зарипованың тормыш юлында барысы да ал да гөл булган дип уйлау хакыйкатькә хилафлык китерү булыр иде. Аңа авыр кайгы-хәсрәтләр дә кичерергә туры килә: башта әнисе вафат була (1983), аннары авыру баласы туа. Соңгы вакыйга, әлбәттә, мөмкинлекләрне нык чикли, тик гаилә җылысы һәм бердәмлеге аңа эшен дәвам итү өчен мөмкинлек тудыра.

1970-1980 нче елларда Рина Зарипова еш кына командировкаларда була, аларның билгеләнүе һава торышына һәм шәхси хәленә карап тормый: 40 градуслы суыкларда да, көмәнле чакның соңгы көннәрендә дә аңа төрле алҗыткыч сәфәрләргә

Рина Зарипова (уртада), Рәшит Әхмәтҗанов (уңнан беренче)
«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә. 1980 нче еллар

чыгарга туры килә. Мәкаләләр килгән хатлар яки кеше сөйләгән буенча гына язылмый шул, күп очракта үз күзләре белән күреп кичерелә, бәя бирелә, бары тик шуннан соң гына укучыга җиткерелә.

Рина Зариповага 1995 елның 13 февралендә «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

2002 елның 1 октябрендә лаеклы ялга киткәч тә, ул үз һөнәренә тугры кала, укучы хатлары да килүдән туктамый. Аның мәкаләләре, «Татарстан яшьләре»ннән тыш, башка газета-журналларда да дөнья күрә: «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт», «Татар иле», «Шәһри Казан», «Заман», «Идел» һ.б. 2001 елның 17 маенда ул, «Хөрмәт һәм ихтирам» номинациясендә, «Бәллүр каләм» бәйгесенең җиңүчесе була.

Яман шеш табылу Рина Зарипованы 2003 елда операция өстәленә ятарга мәҗбүр итә. Әмма бу һәм 2007 елгы операцияләр әлеге авыруга каршы көчсез була. Соңгы көннәремдә урын өстенә калырга язмасын, дип тели иде Рина Зарипова. Һәм ахыргы сулышына кадәр үз акылында һәм аякларында булды ул.

Рина Зарипова 2008 елның 10 гыйнварында дөнья куйды.

Рина Зариповадан калган мирасны барласак, анда, меңләгән мәкаләдән тыш, «Гаилә җылысы» китабы (1982), «Җиде юл чатында» (1990), «Тәүбә» (1991) кебек җыентыкларга кергән дистәдән артык очерклар һәм тәрҗемәләр бар. Аларны күздән кичергәч, кеше гомеренә, эшчәнлеге һәм иҗатына дөрес бәһа бирүнең никадәр авыр һәм җаваплы икәнлеген аңлыйсың. Журналист хезмәтен китаплап, мәкаләләрдән төзелгән җыентыклап үлчәп булмый да. Китаплар, җыентыклар күңелдә озаграк «эри», алар үзләре, ихтыярсыздан, киләчәккә юнәлеш тота. Киләчәктә мәкаләләрнең заман таләпләренә туры килгәннәреннән яңа җыентыклар әзерләп, китапның кайсыдыр төсмерләрен кереш сүздә яңача яктыртып, аларга яңа басмаларда җан өреп була. Әмма журналистның төп максаты – җәмгыятьнең бүгенге хәятендә кайнау, аның белән бер дулкында тибрәнү һәм ахыр чиктә фикереңне тәфсилләп аңлатып, һәркемнең күңел түренә үтеп керерлек телдә аралашу... Гомерен меңләгән яшьләр көтеп алган «Татарстан яшьләре» газетасына һәм аның «Сердәш» сәхифәсенә, халкыбызга хезмәт итүгә багышлаган Рина Зарипова менә шундый асыл журналистлардан иде. ■

Безнең мирас №4 апрель 2021

Рәшит Ваһапов белән очрашулар

Филармония артистлары Шкаповка пионер лагеренда ял итүчеләр белән (Нәсимә Камалиева – икенче рәттә барабанчы егет артында, ак күлмәкле). 1957 ел

Нижгар якларында тумасам да, нәселебездә җырчылар булмаса да, Рәшит Ваһапов үзенә бертөрле якын миңа. Туганым, бик-бик яхшы танышым кебек. Бу исемне ишеткән саен, күңелемнән ниндидер җылы дулкын йөгерә. Кулыма каләм алып, балачак истәлекләремне язарга утырасым килә.

Минем әти-әнием укытучылар иде. Бер арба балалар белән үзебезнең Азнакай районында авылдан-авылга күчеп укытып йөрделәр. 1954 елда әтине, Урманайда завуч булып эшләгән җиреннән, Уразайга мәктәп директоры итеп күчерделәр. Рәшит абый белән беренче «очрашуым» шунда булды.

Әни башлангыч сыйныфларны укыта иде. Бер үк вакытта кич белән олыларны да укытырга йөрде. Мине дә үзе белән иярткәләде. Биш-алты апа бер өйгә дәрескә җыелалар иде. Дәрес беткәч, патефон куялар. Бөтен өйне тутырып, «Фирдәвескәй, кара күзкәй» агыла. Патефонны беренче күрүем дә, пластинкадан беренче тап-

кыр җыр тыңлавым да шунда булды. Могҗиза иде бу! Тылсым иде! Ул чакта әле мин (5 яшьлек бала) бу җырчының мәһшүр Рәшит Ваһапов икәнен белми идем. Ә тәэсире, тылсымы гомерлеккә калды.

Бик популяр булгандыр! Ваһапов репертуарыннан «Нурия» җырын да балачакта еш ишетә идем. Күрше кызы Фәрдәнә янына уйнарга кергәндә, аның абыйсы Фәрит (ул яңадан Казанда радиода эшләде): «Кичә дә кич килми калдың, Нурия, Килми калма бүген дә», – дип җырлый иде.

« **Юлсыз-транспортсыз чорда, башкаладан 350 чакрым (!) ераклыкта урнашкан районга килеп, балалар алдында Татарстанның танылган сәнгать осталары концерт куйган! Бушка!**

1957 елның июлендә язмыш мине Рәшит Ваһаповның үзе белән очраштырган! Тик ул чакта мин аның кем икәнен белмәгәнмен. Казаннан килгән җырчы абый дип кенә истә калган. Ул елны, беренче сыйныфны тәмамлагач, үзебезнең районның Шкаповка пионер лагеренда ял иттем. Безнең янга Казаннан бер төркем артистлар килде. Алар җырладылар, сөйләделәр, фокуслар күрсәттеләр, баянда уйнадылар. Азактан Шкаповканың данлыклы алма бакчасында истәлеккә карточкага төштек.

Еллар үткәч, бу артистларның кемнәр икәнен белү теләге артканнан-арта барды. Сораштыру, интернеттагы мәгълүматларны өйрәнү, тарихи фотоларны чагыштырып карау нәтиҗәсендә (бер мәктәптә укыган якташым, язучы Марсель Галиев ярдәм итте), бездә кунакта Филармония артистлары: җырчылар – Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәлахова, нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов, фокусчы Хәй Мушинский, баянчы Фәйзи Садыйков булган, ахрысы, дигән фикергә килдем. Бәлки, ялгышамдыр?.. Ә берсен барыбер дә белеп булмады…

Юлсыз-транспортсыз чорда, башкаладан 350 чакрым (!) ераклыкта урнашкан районга килеп, балалар алдында Татарстанның танылган сәнгать осталары концерт куйган! Бушка! Менә ул патриотизм, менә ул фидакярлек, менә ул балаларны сәнгать белән тәрбияләү!

2020 елда без ТАССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үттек. Бик күп вакыйгаларны, тарихи шәхесләрне искә төшердек. 64 ел элек төшерелгән һәм әлегә кадәр миндә кадерләп сакланучы бу фотосурәт, бәлки, Татар дәүләт филармониясе сәхифәләрен тулыландырырга ярдәм итәр, бәлки, Рәшит Ваһапов фестивален оештыручылар өчен кызыклы булыр.

Фестиваль дигәннән, милли җанлы Рифат Фәттахов җитәкчелегендәге команда шулкадәр яхшы эш башкара: чын талантларны ача! Лауреатлары безгә концерт белән килгән чакларда бармый калганым юк. Чын ләззәт алам. Ә инде телевизорда Филүс Каһиров күренсә, каршына ук килеп басып тыңлыйм. Үз улым кебек сөенәм, сокланам, горурланам. Рәшит Ваһапов белән тәүге очрашудагы кебек, күңелне җылы дулкын биләп ала…

Нәсимә Камалиева, *журналист,*
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре ■

Көлке куа килә...

Афзал Шамов (1901-1990)

Илһам кайчан килә?

«Болгар» мосафирханәсенең кырыгынчы бүлмәсендә өч шагыйрь сөйләшеп утыра: Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Зариф Бәшири.

Тукай Бәширине өнәп бетерми, аның тизрәк чыгып китүен тели. Кунак ителгән, сыйланган, сөйләшәсе сүз дә беткән, аңа бары, саубуллашып, рәхмәтләр әйтеп чыгып китәсе генә калган. Ә Зариф Бәшири чыгып китәргә җыенмый, такылдавын дәвам итә, әле бер темага, әле икенче темага күчә.

– Габдулла әфәнде, әйт әле, зинһар, сиңа илһам кайчан килә? – дип сорый ул, ниһаять.

Бөек шагыйрь аңа бераз көлемсерәп карап тора да сорау белән җавап бирә:

– Ә сиңа?

– Миңамы? Миңа төнлә, йокларга яткач, күзне йомгач килә.

– Ә-ә, сере менә нәрсәдә икән! – дип, җанланып, кычкырып җибәрә Тукай. – Әйтәм, шигыреңне укыган саен йокы килә. Шуңа икән!

Такылдавык җанның кирәкмәгән сүзләрен эче пошып тыңлап утырган Сәгыйть Рәмиев, моны ишетеп, кинәт шаркылдап көлә башлый, ә Зариф Бәшири, салып куйган галошын да киярга онытып, шундук йөгереп чыгып китә.

Илдус Гыйләҗев (1946-2018)

Төшсә шигырь бәясе

Тукай фәкыйрь булмаган ул,
Санын милләт күтәргән!
Затлы кунакханәләрдә
Күпме гомерен үткәргән.
Менә без ул – ыштансызлар –
Кагыйдәдән чыгарма:
Айлык пенсиям дә җитми
Бер кич кунып чыгарга...

Илдус Гыйләҗев
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Нәҗип Мадъяров
(1928-2002)

Сабыр иткән

Әхмәдиша яңа туган баласының аягын «юып» йөри икән. Әнә шундый әлҗе-мәлҗе вакытында ул хатыныннан:

– Бу балабызга нинди ат кушыйк икән, анасы? – дип сорый.

Иренең сәрхуш булуын искә алып, хатыны аңа:

– Сабыр ит, атасы, – дигән.

– Ярар алайса, – ди Әхмәдиша һәм баласына Сабир куштырып, туу турында таныклык алып кайта.

Тәлгат Нәҗмиев
(1950-2014)

Гаилә җанлы Роберт

Бер төркем Татарстан журналистлары Венгриядән кайтып киләбез. Самолетта комплекслы ризыклар бирәләр бит инде. Маҗарларның күз явын алырлык зиннәтле тартмаларында тартма эчендә тартма.

– Бушагач, моның тартмасын балаларга алырга ярыймы икән? – дип сорады радиотапшырулар редакторы Рәзин Нуруллин.

Әмма шагыйрь Роберт Миңнуллин (ул вакытта «Сабантуй» газетасының баш редакторы) барыбызга караганда да гаилә җанлырак булып чыкты. Олы дипломатын ачты да тартманы шунда «чумдырды». Һәм, ипле генә итеп:

– Исән-сау өйгә кайтып җиткәч, бөтен гаилә белән утырып ашыйбыз аны, – диде.

Илдар Кыямов
(1971)

Тукайны уйнаган иде...

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Нурания Җамали Биектау районының Олы Кавал авылында драматург Аманулла (Әмир Камалиев) сценариесы буенча «Кешечә яшик» дигән телевизион нәфис фильм төшерә. Камал театры актеры Илдус Әхмәтҗановның герое вафат булган эпизодны төшерәләр (дөресрәге, сценарий буенча ул үлгән булып кылана). Аны ничек кирәк шулай сузып, дөресләп салалар да камераларны, утны куя башлыйлар. Инде озак көйләгәч, иҗат төркеме төшерә башлый. Ләкин кичә төнлә каяндыр концерттан кайткан актер, көтә-көтә, изрәп йоклап киткән. Тәрәзәләрдән текәлеп карап торучы Кавал халкы вакыйганы кино төшерү барышы дип түгел, чынга алып тора икән. Кайбер хатыннар яшь түгеп елый ук башлаган:

– И, җаным, үлгәнмени? Әйбәт иде, Тукайны уйнаган иде, җаным!

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

МАРТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Яшел Үзән районының Кече Шырдан авылында бөек татар галиме һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тууына 196 ел тулу уңаеннан китапханә-музей ачылды һәм күренекле галимә Резеда Ганиева яшәгән йортка истәлек тактасы куелды.



● Балалар шагыйре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты, төбәк тарихын өйрәнүче Мөҗәһит Әхмәтҗановның Мөслим районындагы Түреш һәм Дусай авылларына нисбәтле «Авылдашлар» һәм «Данлы Дусай» дигән китаплары дөнья күрде.

● 3 мартта Татарстан Язучыларының чираттагы корылтаенда Татарстанның халык шагыйре, ТР Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла Язучылар берлегенең яңа рәисе итеп сайланды.

● 3 мартта «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Фирдәвес Зариф, Әнже Хөсәенова һәм Ленар Гобәйдуллин ТНВның «Башваткыч» тапшыруында көч сынашты.

● 4 мартта танылган язучы, 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Бөгелмә районы хакимиятенең һади Атласи исемендәге бүләге иясе (2001), Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2006), күренекле җәмәгать эшлеклесе, техник фәннәр докторы Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин вафат булды. Әдипнең җәсәде Эстәрлебаш авылы зиратында җирләнде.

● 12 мартта ТРның һәм РФнең халык артисты (1982, 2000), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1998) Нәҗибә Гыймаделислам кызы Ихсанова 83 яшендә вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде 15 мартта Яңа бистә зиратында – ире Туфан Габдулла улы Миңнуллин кабере янәшәсендә җирләнде.

● 15 мартта Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә мәшһүр шагыйребез Хәсән Туфанның (1900-1981) тууына 120 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә (режиссеры – Халисә Исмәгыйлева) булып узды.

● 18 мартта Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев «Казанские ведомости» газетасы баш редакторы Венера Якуповага һәм редакция хезмәткәрләренә, басманың 30 еллыгы уңаеннан, котлау юллады. «Компетентлы һәм иҗади командасы, шулай ук эчтәлеге кызыклы һәм материаллары объектив булмаса, басма уңыш казана алмас иде. Хәзерге вакытта «Казанские ведомости» – гаилә белән бергәләп укый торган газета», – диелә аның тәбрикнамәсендә.

● 19 мартта Казакъстан Республикасының Казандагы Генераль консулы Жанболат Мурзалин язучы һәм тәрҗемәче, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Лирон Хәмидуллинга, казакъ шагыйре Абайның 175 еллык юбилеен үткәрүдә актив катнашканы өчен, Казакъстан Мәдәният министрлыгының Рәхмәт хатын тапшырды.

● 20 мартта Түбән Новгородтагы Җәмигъ мәчетенең (халык аны «Тау башындагы мәчет» дип йөртә) ачылуына 106 ел тулды. Заманында ул, Ярминкә мәчетеннән кала, икенче иман йорты була.

● 21 мартта Тубыл шәһәренең яңартылган базар мәйданында Нәүрүз бәйрәме үтте. Бәйрәмне «Мирас» бию ансамбле «Яз җитте» дип исемләнгән хореографик композиция белән ачты.

● 22 мартта «Казан утлары» журналы Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучысы Хисаметдин Исмәгыйлевнең «Никах» китабын бастырып чыгарды. Китапның беренче нөсхәсен журналның баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйковка бүләк итте. ■

МИРАСВОРД



Назыйм ... (төрек шагыйре)

... Акъегет

Казып ясалган ныгытма, вал (иск.)

... Зөлкарнәй

Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романындагы герой

Чокып ясалган зур агач табак (диал.)

Диалект, җирле сөйләш (иск.)

Композитор ... Усманов

...-егет

Әбҗәлилов, Мәхмүтов

Борынгы Мисыр фиргавене

«Башсыз җайдак» романы авторы

Рәхим-шәфкать, мәрхәмәт

Индуслар Алласы

Алла тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салынган фикер, хәбәр

Гамманың беренче баскычы

Шамил ... (татар шагыйре)

Христианнарда кабул ителгән ел исәбе

Иркен (иск.)

Эре сырлы игәү

Юләр, акылсыз, томана

Кәрим Тинчурин драмасы

Наип ... (татар галиме, тәнкыйтьче)

Телсез (диал.)

Җир шарындагы иң биек тау

Николай Римский-Корсаков операсы

... Юзиев (әдәбият галиме, тәнкыйтьче)

Каз өмәсендә биеп-уйнап су буена төшү йоласы өчен киенгән кеше

«... һәм бәбиләр» драмасы (Туфан Миңнуллин)

Тау күркәсе

Беренче совет автомобиле

Морза

Туку станында шүрене йөртә торган җайланма

Александр Пушкин шигыре

Кызылком, Сахара, Гоби

Композитор ... Хәсәнов, шагыйрь ... Идиятуллин

Борынгы Римда бакыр тәңкә

Җәлилче ... Бохаров

... Минкина

Бусага (диал.)

Электр каршылыгы берәмлеге

Мисыр мифологиясендә кояш Алласы

3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: тәте, «Хәят», көре, мәрә, сага, әни, әнчек, Роом, киләп, «Ваем», әче, иләк, Шу, Камали, Әләзән, «Лара», Егор, Гыйләҗев, «Вий», Мөрәле, паж, әкә.

Өстән аска: Әркәшә, төмән, чулпы, әрә, чөке, терпе, «Золым», Кәлилә, өмә, әл, Наҗар, өрпәк, әпә, «Калевала», Хәсәнов, маг, иже, АН, Макаров, яугир, лари, Өмми.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / апрель

Сәйф Сараи. *Надия Фәхретдинова рәсеме*

700 ел элек (1321)

Бөек татар шагыйре Сәйф Сараи дөньяга килә.

660 ел элек (1361)

Аксак Тимер Мәвараэннәһердә тамыр җибәрергә керешә – Кашкадәрья вилаяте белән идарә итә башлый.

500 ел элек (1521)

Казанда Ширгали (Шәехгали) ханга каршы халык баш күтәрә. Ханны төшереп, аның урынына тәхеткә Сәедгәрәй (Сәхибгәрәй) утыра.

320 ел элек (1701)

Казанда беренче даруханә ачыла.

245 ел элек (1776)

Сәяхәтче-галим Ив.Ив.Георгиның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларның тасвирламасы» дип аталган җыентыгы басыла. Бу китапта татар милләте хакында да бай мәгълүмат бар.

210 ел элек (1811)

Күренекле мәгърифәтче, төрки телләр белгече Салихҗан Бикташ улы Кукляшев (1811-1864) дөньяга килә.

30 ел элек (1991)

15 апрельдә Татарстан Язучылар берлеге партия (КПСС) оешмасының гомуми җыелышы уздырыла. Анда партия тормышында килеп туган четерекле вазгыятькә кагылышлы мәсьәләләр тикшерелә, Татарстан Республикасы Президентын сайлау, Конституция проектын гомумхалык тикшерүенә чыгару мәсьәләсе дә күтәрелә.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Апрель 2021

И останется в мире слово моё...: Рашит Ахметзянов.

Историческое наследие: «Тукай и Сююмбике». Ляля Муртазина; «Разведка к вятским татарам». Миркасим Усманов; «Кто шил одежду для Тукая?». Халида Габидуллина; «Наследство Зайтуны Мавледовой в музеях». Гузель Тухватова; «Мои желания сбылись». Фатих Кутлу; «Тукай в Астрахани». Абдулла Дубин; «Фатима ханум». Гульмару Мырзагалиева.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Кутадгу билик – знание, несущее счастье». Фирдус Фатхелисламов; «Тукай на веки в сердцах людских». Индус Тагиров.

В глубинах памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Путешествие в Германию». Камиль Саттаров; «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Булачак композитор Марс Макаров (артта уртада) әнисе, туганнан туган абыйсы, апасы һәм сеңлесе Роза белән. 1961 ел (*«Җырлаганда... җылата иде». Ф.Арслан*)

• **Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә.** Габдерәхим Утыз-Имәни

• **Гадәти булмаган бер китапның тарихы.** Себастьян Цвиклински

• **Аллаһ колының варисы.** Әхтәм Зарипов

• **Фаил блокноты, Ишморат хаты...** Эльмира Шәрифуллина

• **Матбугат һәм туган тел.** Рүзәл Юсупов

• **Җырлаганда... җылата иде.** Филүсә Арслан

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Әдип авылы — фотоларда

Татар Кандызы авылы

Фотоларда шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның туган авылын һәм аның якыннарын күрәсез.

Туган йорт сүтелер алдыннан...

Шагыйрьнең әнисе Саҗидә, энесе Илдус һәм сеңлесе Сания

Кандыз буенда. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, ?, Мәгъсүм Латыйфуллин

Рәшит Әхмәтҗановның туган йортына истәлек тактасы куелганнан соң. Уңнан икенче – төп йортта яшәүче Ильяс Әхмәтҗанов. Татар Кандызы, 2005 ел

«КИҢ ЧУЛМАНГА – КОЯШ БЕЛӘН, АЙ-ЙОЛДЫЗЛАР БЕЛӘН ЯШЬТӘШ ЧУЛМАНГА – АШЫГЫП ТӨРЛЕ ЯКТАН СУЛАР АГА...»
НУРИХАН ФӘТТАХ

*Кама (Чулман) елгасының фотолары хаҗи **Абдулла Дубин** тупланмасыннан алынды.*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.